# ШУРА

№ 26
2019



## АПАНАЙ МӘЧЕТЕ

ДИНИ АЛЬМАНАХ
1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК

ҖОМГА ХОТБӘСЕ . . . . . . . . 5

ВӘГАЗЬЛӘР

Мәктәпкә барып уку – гыйлем алуның иң мөһим ысулы . . . . . 12
Нәфесне тыю . . . . . . . . 16
Өммәткә файдалы кеше булырга тырыш. . . . . . . . 22
Пәйгамбәребез галәйһиссәлам турында . . . . . . . . 25
Изге рабигыль-әүвәл ае мөбарәк булсын! . . . . . . . . 31
Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында . . . . . . . . 37
Нәфел намазларының өстенлеге. . . . . . . . 45
Башка милләт һәм дин кешеләренә хөрмәт һәм алар белән тату яшәү . . . . . . . . 50
Ни өчен Аллаһы Тәгалә кешеләрне байларга һәм фәкыйрьләргә бүлеп яраткан? . . . . . . . . 56
Диндә урта юлны табу һәм төрле фиркалардан ерак тору . . . . 61
Сәламәт гаилә – көчле җәмгыять . . . . . . . . 66
Туганнар һәм күршеләрнең хаклары . . . . . . . . 70
Исраф – харам гамәл . . . . . . . . 76

ФӘТВАЛАР

Без мәрхүм туганнарыбызга ничек ярдәм итә алабыз? . . . . . . 83
Миннән әманәт итеп тапшырылган акчаларны урладылар. Мин әҗәтле кеше булып саналаммы? . . . . . . . . 86
Берәр эш белән шөгыльләнгән вакытта Коръән уку рөхсәт ителәме? Бу Коръәнгә хөрмәт күрсәтмәү булмыймы? . . . . . . . 87

ҮРНӘК ЗАТЛАР

Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә бине Җәгъфәр Әл-Кудагый . . . . . . . . 90
Билял радыяллаһу ганһе – Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең мөәзине . . . . . . . . 93

ФӘН

Шәригать хөкемнәре . . . . . . . . 102
Ант итү . . . . . . . . 115

ТАРИХ

Кәгъбәтулла ачкычын саклаучы Госман бине Талхә тарихы . . 120
Финляндия халкына фин телендәге беренче Коръәнне бүләк иткән татар кешесе . . . . . . . . 123

МИРАС
Апанай мәчете тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Касыймия мәдрәсәсе (Күл буе, Галләмия, Апанай мәчете мәдрәсәләре) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
ТӘРБИЯ
Әдәпләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Ата-ананың бала хозурында булган хаклары бәяны . . . . . . . . . 141
Баланың ата хозурында булган хакы бәяны . . . . . . . . . . . . . 152
МӘҮЛИД ӘН-НӘБИ
Мәүлидүн-Нәби бәйрәме хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам – иң камил кеше . . 158
Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә карата булган әдәп 162
Мәүлид кичәсенең фәзыйләтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА
Дога – гыйбадәтнең җелеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Көн дә кирәкле догалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
НӘСЫЙХӘТ
Гыйлем алуның фазыйләтләре турында . . . . . . . . . . . . . . . 179
Олы гөнаһлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
ӘДӘБИ СӘХИФӘ
Күгәрчен оя корганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 199

**«ШУРА» дини альманах, №26**

*октябрь – декабрь 2019*
*сафәр – рабигыль-ахыр 1441*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Эдуард Димасов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 30.09.2019
Чыгу көне: 11.10.2019

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аятьсүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, басып, кычкырып түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ!۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ:

____________________________________۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

۞________________________________________

Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, кычкырып түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак киләсе сүзләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ

إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بارِكْ عَلى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَما بارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وارْضَ عَنِ الْخُلَفاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْباقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاتِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلاَمٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне кычкырып укый һәм хотбә тамам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, басып, кычкырып түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил- кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһү. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһү тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъдү: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһү. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ______________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________
______________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, кычкырып түбәндәге сүзләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галлләәми, кәмәә каалəллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә

вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мукыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне кычкырып укый һәм хотбә тамам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

# Вәгазьләр

*11 октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Мәктәпкә барып уку – гыйлем алуның иң мөһим ысулы

Галәмнәрне юктан бар итүче, безләргә Үзенең күп нигъмәтләрен биреп һәм безгә: «Әй, бәндәләрем, Миңа шөкер итегез – арттырып кайтарырмын», – дип мөрәҗәгать итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә данмактауларыбыз булса иде. Һәм шушы сынаулар белән тулы; ялгышу бик җиңел булган дөньяга пәйгамбәр итеп җибәрелгән Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифәләребез һәм догаларыбыз булса иде.

Аллаһы Тәгалә адәм баласына шундый зур нигъмәт биргән. Бу нигъмәт – акыл. адәм баласын һәм җеннәрне башка затлардан аерып тора торган  нигъмәт ул. Әмма, кызганычка, шушы нигъмәтне кешелек дөньясы үз дәверендә күп тапкырлар кулланмау сәбәпле, төрле бозык, начар юлларга кереп китә. Шул сәбәпле Аллаһы Тәгәлә бу дөньяга пәйгәмбәрләр җибәрә, ә инде соңгы пәйгәмбәр – Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнән соң башка пәйгәмбәрләр килмәячәк. Шунлыктан, Аллаһы Раббыбыз безгә галимнәрне җибәрә. Корьәни Кәримнең иң беренче иңгән аяте:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾

**«Укы. Барсын халык кылучы Раббың исеме белән укы!»**

«Галәкъ», 96: 1

Шушы аятьләр белән зур бер чор башланып китә. Гәрәпләр дөньядагы иң гыйлемле кешеләргә әйләнәләр. Тыйб (медицина), астро-

номия, математика, филология, мантыйк сыман фәннәр бик киң тарала. Мөселман халкы йөзләгән елга Ауропа илләрен узып китә. Элек-электән мәдрәсәләр, мәчетләр, галим вә галимәләрнең йортлары гыйлем үзәге булалар. Ислам дөньясы гыйлемне бик теләп һәм сыйфатлы рәвештә үзләштерә. Имам Әл-Газәли рахимәһуллаһи мантыйк фәненә нигез сала, Аристотельнең фәлсәфәсен ислам дине кысаларына туры китереп, мөселманнарга аңлата. Гыйлемгә бу кадәр омтылуның үз сәбәпләре бар, чөнки сәхабәләрнең күпчелеге зур галимнәр, алар Коръәнне һәм хәдисләрне бик яхшы белгәннәр. Пәйгәмбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Гыйлем алу – бишектән алып ләхеткә кадәр фарыз», – дигән хәдисе дә бар.

Мөселман дөньясында гыйлем алу бер кечкенә йортлардан башланган булса, вакытлар үтү белән, зур университетлар, мәдрәсәләр, дәүләт дәрәҗәсендәге уку йортларына кадәр үсеп җитә. Мәсәлән, Мисыр иленең Каһирә шәһәрендә урнашкан Әл-Әзһар уку йорты, Үзбәкстан җирлегендә урнашкан Бохара шәһәре мәдрәсәләренең даннары бөтен дөньяга таралган. Безнең җирлегебездә дә абруе белән дан казанган уку йортлары шактый.

Бүгенге көндә исә дөньяви мәктәпләр бар. Бездә бу дөньяви белемне теләгән һәркем алырга мөмкин. Әлбәттә, кайбер кешеләрдә: «Дөньяви белем кирәкми, дини белем кирәк», яисә «Дөньяви белем кирәк, дини белем белән ерак китеп булмый», – дигән фикер туарга мөмкин. Әмма бу ике фикер дә – ялгыш. Кеше һәрьяктан алга киткән булырга тиеш.

Дөньяви гыйлем дә кешегә күп вакыт кирәкле. Дөньяви гыйлем алмыйча кеше югары уку йортларына кереп табиб, укытучы, яки башка берәр кирәкле һөнәрле була алмый. Мәктәптә укыганда бала төрле фикердәге, төрле милләт һәм төрле дин тотучы бүтән яшьтәшләре белән аралаша. Анда ул дөньяның бер генә яклы булмавын, бер генә фикерле кешеләр юклыгын һәм күп карашлар булуын аңлый. Әле өстәвенә, бу мөселман

өммәтеннән булган балаларның шулай ук җәмгыятьтә башка кешеләр белән дә бергә укый, эшли, алга үсеш ала алуларын күрәләр. Шулай ук бала мәктәпкә барганда үзенә яңа дуслар таба, үз динендә булган балалар белән танышып китә. Мөселманнар укымышсыз дигән ялгыш фикерләр йөри, ә без моның болай түгел икәнлеген исбатлый алабыз.

Аллаһы Тәгалә безгә бөтен халык кылган мәхлүкъны буйсындырды, ә безгә фәкать шуннан файдаланырга кирәк. Безгә үзебезне шул мәктәпләрдә яхшы әхлаклы кешеләр икәнебезне күрсәтеп, динебезгә күркәм чакыру белән чакырырга мөмкинчелек бирелде. Бүген шундый вакыт, кешеләр сүзгә түгел, ә гамәлгә карыйлар, шунлыктан мөселманнарга җәмгыять тормышының бар үсешләрендә катнашып, үзебезнең зур өлешебезне кертеп, киләсе буыннарга үрнәк булып калырлык итеп тырышырга кирәк. Әгәр без шушы форсатны тиешле рәвештә куллансак, бөтен тирә-якка динебезнең матурлыгын күрсәтә алачакбыз. Аллаһы Тәгәлә барыбызга да хәерле гамәлләр насыйп кылсын!

Баланың бүгенге көндә мәктәпкә бармыйча өйдә генә укуы бик күп проблемалар тудыра, чөнки бала системалы белем алмый, үз яшьтәшләре белән укымый, димәк аның аралашу сәләте кими.

«Мин дини кеше», – дип әйтеп мәктәпкә бармау – уйланып әйтелгән сүз түгел. Гыйлемнең һәр ягын өйрәнергә тиешбез. Баланы өйгә килеп укыткан укытучының да квалификациясе билгесез. Без – бүгенге көндә дин өлкәсендә эшләүчеләр, гади намаз укучы кешеләр дә – бөтенебез мәктәптә укыдык. Аннары югары уку йортларына кереп, алар дини булмасалар да, монда бик күп тормыш тәҗрибәсе, файдалы гыйлемнәр алып чыктык. Кызганычка, теге яки бу мәсьәләгә бер төрле генә карыйбыз. Әмма шушы урында бик хаталанабыз, чөнки елдан-ел безнең дин галимнәребез дөнья һәм дин гыйлемен өйрәнгәннәр. Бүгенге җәмгыять бөтен нәрсәгә төпченеп, төрле гыйлем күзлегеннән карый. Мөселманнар да шушы кешеләргә динне рациональ рәвештә җиткерер өчен, төрле

дөньяви гыйлемнәр аша дәлилләр китерергә тиеш. Бөтен кеше дә интеллектуаль яктан бер дәрәҗәдә түгел. Кешеләр физик, математик, химик, журналистика, педагогика сәләтләренә ия булырга мөмкиннәр, ә мәктәптә укымыйча, уку йортына керми калган кеше бу сәләтләрен тормышка ашыра алмый кала. Ә сәләтең белән эшең бер үк булу – ул зур бәхет. Бала үскәч мондый мөмкинчелекне бирмәгән өчен ата-анасына үпкәләп яшәргә мөмкин. Без бирелгән һәр мөмкинлектән файдаланырга тиеш. Мәктәптә уку бушлай, төрле юнәлеш буенча укырга мөмкин. Яхшы итеп укып бетергәч, үзең теләгән уку йортында уку мөмкинчелеге бар. Аллаһы бөтен нигъмәтләрне кулланырга биргән, куллана белергә генә кирәк.

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмче,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*18 октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Нәфесне тыю

“Ачык әйткән сүзне һәм күңелләрдә яшерен булганын да Белүче” Аллаһы Тәгаләгә олуглауларыбыз һәм мактауларыбыз булсын! Шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәргә дә салаватларыбыз һәм сәламнәребез ирешсен. Хөрмәтле мөселман кардәшләрем! Аллаһы Тәгалә китабында кеше турында болай дип әйтте:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ فِي أَحْسَنِ تَقْوِيمٍ ﴿٤﴾ ثُمَّ رَدَدْنَاهُ أَسْفَلَ سَافِلِينَ ﴿٥﴾

**“Без кешене иң яхшы кыяфәттә яраттык. Соңыннан исә аны иң түбән дәрәҗәләргә төшерербез”.**

«Тин / Инҗир», 95:4-5

Әйе, Аллаһы Тәгалә безне иң яхшы кыяфәттә яратты, кеше булырга насыйп итте, ләкин әгәр дә без кеше булу нигъмәтенең кадерен белмәсәк, Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләргә кызыгып, нәфесебезне тыймасак, нәфес артыннан йөрсәк, үзебез түбәнлеккә омтылганыбыз өчен, Аллаһы Тәгалә безне иң түбән дәрәҗәләргә төшерер.

Кеше дигән барлык, кыскача әйткәндә, биш нәрсәдән яратылган. Беренчесе: туфрактан яратылган тәне; икенчесе – Аллаһы тарафыннан бирелгән җаны; өченчесе – төрле хисләр, фикерләр белән тулып торган йөрәге; дүртенчесе – яхшылык белән начарлыкны аерып бирә торган акылы; бишенчесе – канәгатьләнү эзләгән нәфесе.

Тәннең һәм җанның, йөрәкнең һәм акылның нәрсә икәнлеген һәрбер кеше бераз гына булса да аңлый, ләкин күп кеше, нәфеснең нәрсә

икәнен әйтеп җавап бирә алмый. Нәфес турында Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында болай дип әйтә:

وَلَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ وَنَعْلَمُ مَا تُوَسْوِسُ بِهِ نَفْسُهُ ۖ وَنَحْنُ أَقْرَبُ إِلَيْهِ مِنْ حَبْلِ الْوَرِيدِ ﴿١٦﴾

**“Без кешене яраттык һәм нәфесе нәрсәгә вәсвәсәләнеп торганын да беләбез. Без аңа җилкә тамырыннан да якынракбыз».**

«Каф», 50:16

Нәфес канәгатьләнүдән башка бер әйберне дә танымый һәм канәгатьләнүенә киртә булган бөтен нәрсәләргә дошманлык һәм кирелек күрсәтә. Нәфес йокыны, күп һәм тәмле ашауны ярата, эшсезлек һәм ялкаулык аның иң яраткан сыйфатлары булып санала. Ләкин, кайбер вакытта мактаныр һәм мактау сүзләрен ишетер өчен авырлыкларны да күтәрә ала.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем! Иң уңышлы юл – нәфесне тыю һәм аның белән көрәшү юлы булып санала. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бу хакта хәдисләре күп, шуларның кайберләрен ишетеп узыйк.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: “Нәфесен Аллаһы Тәгаләгә буйсындырырга тырышучы чын мәгънәсендә көрәшче булып санала”, – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам көрәштән кайткан сәхабәләрне шундый сүзләр белән каршы алган иде: “Кечкенә сугышны калдырып, зур сугышка хуш килдегез». Бу сүзләрне ишеткән сәхабәләре: “Зур сугыш нинди сугыш соң ул?” – дип сорадылар. Пәйгамбәребез җавап кайтарып: “Нәфес белән сугышу”, – дип әйтте.

“Ни өчен нәфес белән сугышу зур сугыш дип аталды”, – дигән сорауны акыллы кеше бирмәс дип уйлыйм, чөнки бу сорауның җавабы ачык. Җир йөзендә булган һәм була торган сугышларның бөтенесе дияр-

лек нәфесне тыя алмаудан килеп чыккан. Кешеләр дәрәҗәгә, малларына, байлыкларына һәм яшәгән җирләренә кызыгып бер-берсенең каннарын түккәннәр, һәм шуны да онытмаска кирәк: җәһәннәмгә керә торган кешеләрнең күбесе нәфесләренә хуҗа була алмаганнары өчен хәсрәт утына керәчәкләр.

Шуңа күрә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам безнең чын дошманныбызны аңлатып: “Сиңа иң күп дошманлык күрсәтә торган дошманың – ике күкрәк арасындагы нәфесең”, – дип әйтә. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бу сүзләрен бик еш кына онытып җибәрәбез һәм соңыннан үкенечле хәлләргә төшәбез.

Аллаһы Тәгалә нәфес артыннан иярүчеләрне Үзе үк адаштыруы хакында китабында да әйтеп уза:

أَفَرَأَيْتَ مَنِ اتَّخَذَ إِلَـٰهَهُ هَوَاهُ وَأَضَلَّهُ اللَّهُ عَلَىٰ عِلْمٍ وَخَتَمَ عَلَىٰ سَمْعِهِ
وَقَلْبِهِ وَجَعَلَ عَلَىٰ بَصَرِهِ غِشَاوَةً فَمَن يَهْدِيهِ مِن بَعْدِ اللَّهِ ۚ أَفَلَا
تَذَكَّرُونَ ﴿٢٣﴾ وَقَالُوا مَا هِيَ إِلَّا حَيَاتُنَا الدُّنْيَا نَمُوتُ وَنَحْيَا وَمَا يُهْلِكُنَا
إِلَّا الدَّهْرُ ۚ وَمَا لَهُم بِذَٰلِكَ مِنْ عِلْمٍ ۖ إِنْ هُمْ إِلَّا يَظُنُّونَ ﴿٢٤﴾

**“Нәфес теләкләрен Аллаһы урынына куеп, нәфсенә табынучыны күрдеңме? Аллаһы Тәгалә аны гыйлеме белән адаштырды. Ишетүен һәм йөрәген мөһерләде һәм күзләренә пәрдә куйды. Шушы хәлгә төшкәннән соң, Аллаһыдан башка кем аны туры юлга бастыра алсын? Әллә бер дә уйлап карамыйсызмы? (Ул нәфес теләкләренә табынучылар) әйтәләр: “Без дөньяда бер генә яшибез, үләбез, тереләбез һәм безне вакыт үтү генә үтерәчәк”.**

«Җасийә / Тезләнү», 45:23-24

Нәфес теләкләренә табынып яшәүчеләр турында Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер хәдисендә: Аллаһы Тәгалә каршысында Җир йөзендәге потка табынучы кешеләрдән иң җирәнгечләре – нәфес теләкләренә табынучылар”, – дип әйтә.

Давыд галәйһиссәламгә Аллаһы Тәгалә: «Әй Давыт, кардәшләреңә әйт: нәфес теләкләре артыннан йөрмәсеннәр һәм шуны белсеннәр: нәфес теләкләре белән тулган күңелләр Миннән пәрдәләедер”, – дип әйтә.

Нәфес хакында диндар булган галимнәребезнең сүзләрен дә ишетеп узыйк.

Әбү Габбас Әл-Мәвсили еш кына үзенең нәфесенә: “Әй, нәфесем, син падишаһ балалары белән бергә бер өстәлгә утырып ашамыйсың һәм Аллаһы Тәгаләгә күңелләрен биреп диндарлык итүчеләр белән дә гыйбадәт итмисең. Әйтерсең сине җәһәннәм белән җәннәт арасында бәйләп куйганнар. Әй, ояла белмәгән нәфесем, ялкаулыкка кол булудан үзеңне коткар”, – дип әйткән.

Яхъя бине Рази: “Нәфесеңә каршы аны тәрбияли торган кораллар белән көрәш һәм шуны бел, нәфес белән көрәшә торган дүрт корал бар. Беренчесе – аз ашау, икенчесе – аз йоклау, өченчесе – аз сөйләшү, дүртенчесе – кешедән күргән золымнарга сабыр булу”, – дип әйтә.

Әбү Яхъя Әл-Вәррак: “Нәфесен канәгатьләндерү юлында булган кеше, һичшиксез, күңеленә үкенү орлыклары чәчә һәм ул орлыклар тиздән үкенеч җимешләре булып өлгерәчәкләр”, – дип әйтә.

Яхъя бине Зәкәрия галәйһиссәлам көннәрнең берсендә Иблисне күрде. Иблис кулына чорнап ала торган арканнар, җепләр тоткан иде. Яхъя аннан: “Кулындагы җепләр белән нәрсә эшлисең?” – дип сорады. Иблис: “Кешене кызыктырып гөнаһка кертә торган җепләр ул”, – дип җавап кайтара. Яхъя галәйһиссәлам: “Бу җепләргә минем дә эләккәнем бармы?” – дип сорады. Иблис: “Әйе, бер мәртәбә эләктең, тук булганчы ашаган идең, шул төнне тирән йокы белән йокладың һәм намазга тора алмадың”, – дип

җавап кайтарды. Яхъя галәйһиссәлам тетрәнеп куйды һәм: “Аллаһы белән ант итәм: башка беркайчан да тук булганчы ашамаячакмын!” – дип әйтеп куйды. Иблис тә тетрәнеп куйды һәм: “Башка беркемгә дә яхшы киңәш бирмәячәкмен”, – дип әйтте.

Локман галәйһиссәлам үзенең улына киңәш биреп: “Күп йоклама һәм күп ашама. Күп йоклаучы һәм күп ашаучы Кыямәт көнне бернәрсәсез калыр”, – дип әйтә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам хәдисләрендә мөселманнарга күп ашамауны һәм йокламауны киңәш итә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: “Калебләрегезне, йөрәкләрегезне ачлык белән нурландырыгыз, нәфесләрегезгә каршы сусау белән сугышыгыз. Җәннәт ишеген ач тору белән шакып торыгыз. Ач тору һәм сусау – Аллаһы Тәгаләгә иң сөекле гамәлләрдән булып санала”, – дип әйткән.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, ишетеп узган бу аятьләрнең, хәдисләрнең һәм галимнәрнең сүзләре хак һәм дөрес икәнен аңлар өчен күп акыл кирәкми, дип уйлыйм.

Аллаһы Тәгалә безгә акыл дигән бүләкне күтәреп йөрер өчен генә бирмәде. Акыл нәфесне тәрбияләр һәм нәфеснең ялгышларын аңлатыр очен бирелде. Нәфес ул сабый балага охшаш: күп вакытта начарның начар икәнлеген аңламый, ялтыраган һәрбер әйберне алтын дип уйлый һәм ялгыша. Әгәр дә нәфеснең һәрбер теләген үти башласак, иң соңында ул безнең башыбызга менеп утырачак һәм кеше көлкесенә калдырып, дөньяда һәм Ахирәттә безне хур итәчәк.

Аллаһы Тәгалә Гайсә галәйһиссәламгә: “Әй Мәрьям улы Гайсә! Иң беренче үзеңнең нәфесеңне вәгазьлә (тәрбиялә). Нәфесеңне вәгазьләгәннән соң башка кешеләрне вәгазьлә. Әгәр дә шулай эшләмәсәң, Миннән оял”, – дип әйткән.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, әгәр дә дөньяда һәм Ахирәттә уңышка ирешергә телибез икән, нәфесебезне тәрбиялик, Аллаһы Тәгалә

тыйган әйберләрдән тыелыйк, кушканнарын үтик һәм шулай булуыбыз белән нәфескә кол булудан үзебезне коткарыйк. Аллаһы Тәгалә тәүфыйктан аермасын.

*Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин,*

*“Шамил” мәчете имам-хатыйбы*

*25 октябрь вәгазе,*

*Сәфәр аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Өммәткә файдалы кеше булырга тырыш

Бу дөньяда кеше җәмгыятьтән башка, бер-берсе белән аралашмыйча, бер-берсенә ярдәм итмичә яши алмый. Кешенең табигате шундый: без бер-беребезгә мохтаҗ. Кешеләргә файда китерим, бу җәмгыятьтә үз эземне калдырыйм, дип ихластан тырышучылар да бар. Шулай ук кешеләрнең яхшылыгыннан файдаланып, үзе бу кешелек дөньясына һичнинди файда китермичә яшәүчеләр дә бихисап. Әмма динебез безгә файда китерүче кешеләрдән булырга куша. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дигән: «Сезнең хәерлеләрегез – кешеләргә күбрәк файда китерүчеләрегез»[1].

Әлеге хәдис безне җәмгыятькә файда китерүче кешеләрдән булырга чакыра. Уйлап карасаң, кешеләргә файда китерү юллары бик күп төрле. Мөмкинчелегең бар икән, әҗәтле кардәшләребезнең әҗәтләрен капла, фәкыйрь-мескеннәргә садакалар бир, мәчет-мәдрәсәләр төзелешенә үз өлешеңне керт, кайгыга баткан кешенең күңелен күр – болар барысы да мөселманнарга файда китерү булып бара. Һәм мондый изгелекләрне саный башласаң, алар бихисап. Яраткан Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәхабәләренә кешеләргә файда китерү юлларын төрле мисаллар ярдәмендә күрсәтеп калдырган һәм файда китерүне садака әҗере белән тиңләгән. Биредә Әбү Һөрайрадан килгән бер хәдисне искә алыйк: Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам болай дигән:

1 Әт-Табәрани риваяте.

«Кеше үзенең тәнендәге һәр буын өчен, кояш чыккан һәр көнне садака бирергә тиеш. Ике бәхәсләшкән кешене дуслаштыруы– садака (ягъни садака биргән кебек әҗер-савап аладыр), кешегә хайван өстенә менгәндә яки аның кирәк-ярагын куярга булышуы – садака, яхшы сүз – садака, намазга юнәлгән һәр адым – садака, кешеләргә зарарлы нәрсәне юлдан алып кую да – садакадыр»[1].

Карагыз, кардәшләрем, һәркем үти алырлык җиңел генә гамәлләр; кешеләргә файда китерү авыр эш түгел икән бит, әмма бу гамәлләрнең әҗере садака биргән кебек була. Кардәшеңә хәерле сүз әйтүең, аңа яхшы киңәш бирүең дә садака була, аңа китергән файдаң хөрмәтенә хәерле кешеләр төркеменнән буласың, садака биргән кебек әҗер-савап аласың. Кызганычка, кешенең табигатенә ялкаулык та хас шул: еш кына әлеге изгелекләрне эшләргә ирендерә.

Һәрберебез уйлансын иде: безнең бу өммәткә нинди файда китергәнебез бар соң? Милләтебез, динебез алга китсен, дип нинди файдалы гамәлләр кылабыз? Өммәтебезгә файда китерүче кеше булып яшибезме яки калганнарның изгелеген өмет итеп кенә ятабызмы?

Һәр мөселман үз өстенә өммәтебезне алга җибәрү бурычын алып, кечкенә генә файдалар китереп яшәсә дә, динебез дә, милләтебез дә күпкә алга китәр иде. Көн саен йоклар алдыннан үзебезгә сорау бирик: мин бүген җәмгыятькә нинди файда китердем, берәр кардәшемә ярдәмем тидеме, динем, милләтемне алга җибәрер өчен нинди өлеш керттем? Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә: «Сезнең берәрегез кардәшенә файда китерә алса, эшләсен!» – дигән.[2]

Әйтик, бер җирлектә мөселманнар мәчет-мәдрәсәгә мохтаҗ ди. Кайбер кардәшләребез, минем мәчет-мәдрәсә төзү мөмкинчелегем юк инде, бай кардәшләребез төзер әле, дип уйлап куяр. Әмма әлеге хәдисләр белән

---

1 Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

вәгазьләнеп, һәрбер кардәшебез аз гына булса да файдам тисен әле, дип бу эшкә үз өлешен кертсә (хәтта ул әз генә сумма булса да), Аллаһы Тәгалә теләсә, безнең мәчет-мәдрәсәләребез тиз арада төзелер иде. Кызганыч, без, байлар бар, шулар төзер әле дип уйлыйбыз. Әлбәттә, алар төзерләр, һичшиксез. Әмма син шушы хаҗәт вакытында нинди файда китергән буласың? Безнең халыкта тамчыдан күл җыела, диләр. Үземнең өлешемне кертим, миннән дә файда булсын, дип һәрберебез динебезне алга җибәрә торган төрле проектларга үз өлешләребезне кертсәк, бу гамәлләр бәрәкәтле булыр иде, кардәшләрем. Аллаһы Раббыбыз һәрбарчабызга да тәүфыйк-һидаять биреп, безне өммәткә файда китерүче мөселманнардан итсә иде. Һәр көнебезне кечкенә генә булса да файдалы эшләр, хәерле гамәлләр кылып яшәргә насыйп әйләсен иде. Әлеге вәгаземне Аллаһының сүзләре белән тәмамлыйм. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай ди:

لَّا خَيْرَ فِي كَثِيرٍ مِّن نَّجْوَاهُمْ إِلَّا مَنْ أَمَرَ بِصَدَقَةٍ أَوْ مَعْرُوفٍ أَوْ إِصْلَاحٍ بَيْنَ النَّاسِ
ۚ وَمَن يَفْعَلْ ذَٰلِكَ ابْتِغَاءَ مَرْضَاتِ اللَّهِ فَسَوْفَ نُؤْتِيهِ أَجْرًا عَظِيمًا ﴿١١٤﴾

**«Кешеләрнең нәфесләре теләгәнчә үзара күп сөйләшүләрендә хәер-файда юктыр, мәгәр берәү мохтаҗларга, Аллаһы юлына садака бирергә кешеләрне өндәсә, яки яман эшләрдән тыеп, яхшы эшләргә өндәсә, яки кешеләр арасын төзәтергә, яхшыртырга өндәсә, әнә шул кешенең сүзләрендә хәер һәм файда бардыр. Әйтелгән бу хәерле эшләрне бер мөэмин Аллаһы ризалыгын өмет итеп эшләсә, без аңа тиздән олы әҗерне, ягъни җәннәт нигъмәтләрен бирербез».**

«Нисә / Хатыннар», 4:114

*Раил хәзрәт Фәйзрахманов,*

*Балык Бистәсе районы,*

*Тәберде Чаллы авылы мәчете мөгаллиме*

*1 ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Пәйгамбәребез галәйһиссәлам турында

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, шунда булган барча мәхлүкатне тәрбия кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә чиксез мактауларыбыз, хәмде-сәналәребез, бөтен галәмгә рәхмәт өчен җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребез түреннән чыккан салават шәрифләребез ирешсә иде. Бүгенге җомга көнен олуглап мәчетебезгә җыелган мөхтәрам газиз дин кардәшләребез һәр барчабызга да Аллаһының сәламе, рәхмәте вә бәракәте ирешсен. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Бүгенге вәгазебездә ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәлам турында сөйләрбез.

Иманның бер шарты булып – пәйгамбәрләргә инану тора. Пәйгамбәр – ул Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәрен, әмерләрен, хәбәрләрен, тыюларын Аллаһының колларына тапшыру өчен, Аллаһы Тәгалә белән Аның коллары арасында арадашчы сыйфатында җибәрелгән һәм әхлакның барлык гүзәллекләренә ия булган зат. Пәйгамбәрләр кешеләрне Аллаһыга ширек кылу, потларга табыну кебек төрле адашулардан коткарып, кешеләрне дөнья һәм Ахирәт бәхетенә ирештерү өчен җибәрелгәннәр. Кешеләр үз акыллары белән туры юлны таба алмаганга, Аллаһы Тәгалә аларга пәйгамбәрләр җибәргән. Иң беренче кеше һәм тәүге пәйгамбәр – Адәм галәйһиссәлам.

Безнең Пәйгамбәребезнең биш сыйфаты аны бүтән пәйгамбәрләрдән аерып тора: Беренчесе: бөтен пәйгамбәрләрдән

фазыйләтлерәк (өстенрәк); икенчесе: ул барлык кешелеккә һәм җеннәргә җибәрелгән; өченчесе: «Хатәмүл-әнбия», ягъни пәйгамбәрләрнең иң соңгысы. Аннан соң бүтән пәйгамбәр килмәячәк; дүртенчесе: ул барча галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән; бишенчесе: аның шәригате Кыяматкә кадәр дәвам итәчәк.

Пәйгамбәребезнең нәсел-нәсәпләре: Пәйгамбәребезнең үзеннән алып, хәзрәти Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселенә тоташкан Гадьнәнгә кадәр булган нәсел чылбыры: хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәлам, Габдулла, Габделмотталиб, Һәшим, Габдеманәф, Кусай, Киләб, Мүррә, Кәгаб, Ләәй, Галиб, Фихер, Мәлик, Нәдер, Кинан, Хөзәймә, Мөдрикә, Ильяс, Мөдәр, Низар, Мәгад, Гадьнән. Пәйгамбәребезнең әнисе ягыннан нәсел чылбыры: хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәлам, Әминә, Вәһеб, Габдеманәф, Зөһрә, Киләб.

Пәйгамбәрләрнең соңгысы буларак җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер кешелек өчен генә түгел, барча галәмнәргә Аллаһының бер рәхмәте булып килде. Дөнья һәм Ахирәт мәслихәтләрендә һәм котылу юлын күрсәтүдә акылының чиге булмаган зат, кешеләрнең җитешсезлекләрен бетерү өчен мәхлүкъләр белән Аллаһы Тәгалә арасында арадашчы буларак җибәрелгән пәйгамбәрләрнең иң бөеге, иң югары булганы – безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам. Аңа кадәр Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешелеккә җибәрелгән пәйгамбәрләрнең кайберләре аерым бер кавемгә (халыкка), кайберләре аерым бер мәмләкәткә (илгә) генә җибәрелгән булса, ул галәйһиссәлам бөтен кешелеккә, барча яратылган җан ияләренә, шулай ук унсигез мең галәмгә Аллаһының рәхмәте буларак җибәрелгән.

Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм әфәндебез Мәккә-и Мөкәррәмәдә, милади буенча 571 нче елда, рабигыль-әүвәл аеның 12 нче кичәсенең таң вакытында дөньяга килде. Аның бу бәхетле тууы белән бөтен кешелек галәме кояш нуры чәчә башлагандай булды. Ке-

шелек күкләрен каплаган караңгылык һәм афәт болытлары таралып, кешелек сафлана һәм нурлана башлады. Пәйгамбәрләрнең соңгы бөҗрасы булган Пәйгамбәребез кырык яшенә җитеп, пәйгамбәрлек һәм шәригать иңдерелгәнче үк үзендә гадәттән тыш изгелек билгеләрен күрсәтте. «Аллаһы ничек кушкан булса, шулай тугрылыклы бул!» – дигән Аллаһы әмеренә тулысынча ияргәнгә, бөтен тормышында дөреслек һәм тугрылыкның тере мисалы булды. Ул төрле күрсәтүдән һәм ялганнан ерак иде. Кеше кешене хөрмәт итмәгән, кеше кешегә ышанмаган бер дәвердә аңа һәркем ышанды, аны хөрмәт итте. Бәхәсле мәсьәләләрдә аның сүзенә һәм хөкеменә бердәм риза булырлар иде. Хәтта аның пәйгамбәрлегенә ышанмаган дошманнары да, аның дөреслек һәм тугрылык белән яшәвен, ялган белән килешмәвен кабул итәләр иде. Анда булган тиңсез әхлак һәм югары дәрәҗәне раслап, аны «Мөхәммәд Әмин» – «ышанычлы Мөхәммәд» дип атадылар. Чыннан да, дөньяга, дөньяның бозыклык белән тулган бер дәверендә рәхмәт булып килгән Расүлебез кешеләр табына торган потларны тар-мар итеп, галәмне иман һәм Ислам нуры белән караңгылыктан коткарып, кешелеккә дөнья һәм Ахирәт бәхете ачкычларын бүләк итеп, чын мәдәният юлларын күрсәтеп калдырган. Менә бүген тарихны юлсыз рәвештә өйрәтүче кайбер кешеләр төркеме, аның бөек дәрәҗәсен, әхлагын, кешелекне чыннан да коткаручы икәнлеген танырга мәҗбүр булдылар. Аның тарихка тәэсире һәм рухи көче алдында хәйран калуларын яшерә алмадылар. Бөек ислам галиме Мөхәммәд Әсәд тарафыннан тәрҗемә ителгән бер әсәрдә мәшһүр инглиз фәлсәфәчесе Томас Карлейл: «Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм икейөзлелектән бөтенләй азат булганлыктан, мин аны яратам. Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне бәяләрлек бер үлчәү дә юк. Ул үлчәнмәслек дәрәҗәдә авыр һәм бөек», – дип әйткән. Мөселман булмаса да, инсафлы кешеләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә шулкадәр хәйран калып, хөрмәт күрсәткәч, аның өммәтенә аны никадәр яратып, никадәр хөрмәт

итәргә тиешле булуын уйларга кирәк. Пәйгамбәребез дөньяга килгәндә, аңа кадәр килгән пәйгамбәрләр китергән шәригать хөкемнәреннән берни дә калмаган иде. Хаклык һәм хөкем безнең Пәйгамбәребезгә калды. Шуңа күрә, Пәйгамбәребез бервакыт хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһенең кулында Тәурат битләрен күреп, моңа ризасызлыгын белдереп: «Сез дә яһүдиләр һәм насаралар кебек минем пәйгамбәрлегемнән, миңа индерелгән Коръәннән шикләнәсезме? Аллаһы белән ант итәм, үзенә Тәурат иңдерелгән Муса пәйгамбәр галәйһиссәлам хәзер яшәгән булса, Миңа иярүдән башка һичбер юл сайламас иде», – дип аңлатып биргән. Шуның өчен Кыяматкә кадәр пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәламнең абруе һәм хөкеме генә өстен булачак. Пәйгамбәребезне яхшылап белик! Бу галәмдәме яки моннан соңгы галәмнәрдәме, бөтен мәхлүкъларга Аллаһының рәхмәте итеп җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яхшылап белү, аңлау һәм аңа чын өммәт булу белән генә шәрәфле, изгелекле һәм яхшы кеше булырга мөмкин. Пәйгамбәребезне белмәгән, танымаган, сөймәгән кеше дөнья тормышында да, Ахирәт тормышында да шәрәфле зат була алмас.

Пәйгамбәребезнең исеме Мөхәммәд галәйһиссәлам, әтисенең исеме Габдулла, әнисенең исеме Әминә. Ана карынында җиде айлык булганда, әтисе вафат булган. Ул милади буенча 571 елда, һиҗри буенча рабигыльәүвәлнең уникенче числосында, милади буенча апрель аеның егерменче дүшәмбе көненең таңында Мәккәдә туды. Туганда ул һичбер балага охшамый иде. Расүллек нуры күзне камаштырды. Аның тууы белән кешелеккә яңа бер бәхетле дәвер ачылды. Ул дүрт яшенә кадәр сөт әнисе Хәлимәгә тапшырылды. Соңыннан үз гаиләсенә кайтарылды. Алты яшендә әнисе Әминә вафат булды. Дәү әтисе Габделмотталиб аны үз гаиләсенә алды. Әмма әнисе вафат булып ике ел үткәч, аңа сигез яшь булганда, дәү әтисе дә вафат булды. Ул агасы Әбү Талиб янында калды. Пәйгамбәребезнең балалык һәм яшьлек вакытлары, буйдаклык һәм гаиләле чаклары, бөтен

тормышы һичкемгә насыйп булмаган өстенлек һәм камиллек белән үтте. Егерме биш яшендә Хәдичә анабызга өйләнде. Һичбер вакыт потларга табынмады. Балачактан ук аларны яратмый иде. Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәлам дине буенча Аллаһыга гыйбадәт кыла иде. Вакыт-вакыт Мәккә янындагы Хира тавына барып, Аллаһының кодрәте һәм бөеклеге турында уйлап, дога һәм зикердә булды. Көннәрдән бер көнне Хира мәгарәсенә кереп, дога һәм зикер кылганда Аллаһының әмере белән Җәбраил галәйһиссәлам пәйгамбәрлек вазифасын белдерергә килде. Кешелекнең коткаручысы, Аллаһының сөеклесе хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә: «Укы!» – диде. Пәйгамбәребез: «Нәрсәне укыйм соң?» – дигәч, Җәбраил галәйһиссәлам: «Укы!» – дип кабатлады. Хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәлам дә үз җавабын кабатлады. Аннан соң Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәребезне тотып мөбарәк күкрәген кысты. Шулай Пәйгамбәребезгә мәгънәви эшчәнлек рухы бирелде. Пәйгамбәребез бөек бер могҗиза белән кинәт укый башлады. Җәбраил галәйһиссәлам өченче тапкыр: «Укы»,– дип әйтте һәм шушы аятьләрне укыды:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾ خَلَقَ الْإِنسَانَ مِنْ عَلَقٍ ﴿٢﴾ اقْرَأْ وَرَبُّكَ الْأَكْرَمُ ﴿٣﴾ الَّذِي عَلَّمَ بِالْقَلَمِ ﴿٤﴾ عَلَّمَ الْإِنسَانَ مَا لَمْ يَعْلَمْ ﴿٥﴾

**«Әй Мөхәммәд, һәрнәрсәне бар кылучы Раббың исеме белән Коръәнне укы! Ул кешене оешкан каннан бар кылды. Укы, синең Раббың – Аллаһы бик хөрмәтле вә юмарт. Ул – Аллаһы каләм белән язуны өйрәтте. Кешегә белмәгән нәрсәләрен өйрәтте».**

«Галәк», 96:1-5

Шулай итеп хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек вазифасы бирелде. Коръәни Кәрим егерме өч ел эчендә тулысынча иңдерелде.

Пәйгамбәребез унөч ел дәвамында Мәккә халкын дингә өндәде.

Ул зур мәшәкатьләр һәм газаплар күрде. Һәрнәрсәгә сабыр итеп, Аллаһының барлыгын һәм берлеген белдерергә тырышты. Шуннан соң Мәдинә Мөнәвәрәгә һиҗрәт кылды (күчеп китте). Ун ел анда расүллек (илчелек) вазифасын башкарды. Кешеләрне кешелеккә өйрәтте, мәдәнияткә өндәде. Караңгы күңелләрне Ислам нуры белән нурландырды. Шулай итеп вазифасын тәмамлады. Алтмыш өч яшендә мәңгелек йортка күчте. Кешелек галәменә юл күрсәтүче буларак Коръән Кәримне һәм Үзенең сөннәтен васыять итеп калдырды. Мактау сиңа, сәлам сиңа, әй Аллаһының илчесе! Сине чыннан да галәмнәр Раббысы Үзе белгән һәм мактаган. Син рахмәтән лил-галәмин (ягъни барча галәмнәргә рәхмәт булып килдең). Син кешеләрнең һәм җеннәрнең пәйгамбәре. Син Аллаһы Тәгаләнең «Ләү ләәкә ләү ләәк, ләмәә халәктүл-әфләәк» (ягъни Син булмасаң, бер нәрсәне дә бар кылмас идем) – дип әйтелгән заты. Син Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

*Илһам хәзрәт Миннегалиев,*

*Мамадыш районы имам-мөхтәсибе*

*8 ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Изге рабигыль-әүвәл ае мөбарәк булсын!

Изге рабигыль-әүвәл (мәүлид) ае башланды. «Мәүлид» сүзе туу дип тәрҗемә ителә. Мәүлид көне – рабигыль-әүвәл аеның уникенче көне. Ул көнне пәйгәмбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган. Аның бу дөньяга килүе – Аллаһының олуг бүләге. Рабигыль-әүвәл аенда мөселманнар күркәм мәҗлесләрдә җыелып, Пәйгәмбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең яшәү рәвеше, әхлагы турындагы аять-хәдисләрне укыйлар, салаватлар әйтәләр, догалар кылалар.

Кайс бине Махрам радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Мин һәм Аллаһының Расүле галәйһиссәлам Фил елында тудык»[1]. Бу хәдистә әйтелгәнчә, Пәйгәмбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Фил елында туган. Гарәпләрдә тарихи чорларны елның бөек вакыйгалары белән билгеләү гадәте булган, шундыйларның иң мәшһүре – филләр белән бәйле булган вакыйга. Аның кыскача тарихы түбәндәгедән гыйбарәт.

Хәбәшестан Йәмән илен яулап алганнан соң, Хәбәши патшасы Йәмәннең хәлифәсе итеп Әбраһә Әл-Әшрамә дигән кешене билгеләгән. Әбраһә барлык хәбәшиләр кебек нәсрани (христиан) динендә булган. Ул Сана шәһәрендә бер зиннәтле чиркәү төзеткән һәм аны Калийс дип атаган, гарәпләрне Кәгъбәтуллага түгел, ә шул чиркәүгә хаҗ кылырга мәҗбүр итәргә тырышкан. Бу эш уңышсыз булганлыктан, Әбраһә үз максатына көч кулланып ирешергә карар кылган. Ул Кәгъбәтулланы җимереп, барлык кешеләрне үз чиркәвенә юнәлдерергә теләгән. Моның өчен зур гаскәр җыйган һәм сугыш өчен кирәк

[1] Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

булган барлык әйберләрне әзерләгән. Әбраһә гарәпләрнең күңелләренә курку салыр өчен, күпсанлы филләр белән Мәккә тарафына юнәлгән. Юлда бернинди киртәләр очрамагач, ул Мәккәгә Таиф шәһәре ягыннан якынайган һәм үз гаскәре белән Мугаммис дигән җирдә туктаган. Шуннан соң Әбраһә Мәккәгә юлчабарын җибәргән һәм аңа шәһәрнең аксакалын алып киләргә кушкан. Юлчабар аның сүзен үтәгән һәм Кораеш кабиләсенең аксакалын – Габделмотталибны алып кайткан. Аксакал озын буйлы, зур гәүдәле һәм тәэсирле кыяфәткә ия булган.

Әбраһә аны күргәч, сокланган һәм үз тәхетеннән торып Габделмотталиб янына килгән. Келәмгә утырып, тәрҗемәчесенә:

– Миннән нәрсә теләгәнен сора, – дигән.

Габделмотталиб:

– Синең сугышчыларың минем ике йөз дөямне урлап киттеләр, аларны миңа кайтар, – дигән.

Шунда Әбраһә тәрҗемәчесенә болай дип әйтергә кушкан: «Мин кыяфәтеңне күреп сокланган идем, ләкин сүзләреңне ишеткәч, сиңа карата фикерем үзгәрде. Мин динегезнең мөбарәк йортын – Кәгъбәтулланы җимерергә килдем, ә син ике йөз дөяңне сорыйсың». Габделмотталиб: «Мин – дөяләрнең хуҗасы, ә Кәгъбәтулланың үз Хуҗасы бар. Ул аны Үзе саклаячак», – дип җавап биргән.

Аңа дөяләрен кайтарганнар. Мәккәгә әйләнеп кайтканнан соң, Габделмотталиб барлык кешеләргә дә тауларга китәргә әмер биргән, үзе берничә кеше белән Кәгъбәтулла янына килгән һәм капкасының боҗраларын тотып дога кылганнар, Аллаһыдан ярдәм сораганнар.

Әбраһә үзенең гаскәрен һәм филләрен җыеп, Кәгъбәтулланы җимерү нияте белән юлга чыккан. Кинәт ниндидер сәбәп аркасында филләр җиргә яткан һәм торырга теләмәгәннәр. Кире тарафка алар бик теләп барган, әмма Кәгъбәтуллага борганда атларга теләмәгәннәр.

Көтмәгәндә, Аллаһының ихтыяры белән, төркем-төркем кошлар очып килеп, дошманнарга ташлар ыргыта башлаганнар. Таш эләккән һәр сугышчы шунда ук һәлак булган. Гаскәр тулысынча тар-мар ителгән, ә Әбраһәнең тәне тарала башлаган. Аны Сангә шәһәренә алып кайтканнар, ул шунда җан биргән.

Нәкъ менә шул елны Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм анасының карынында була. Әлеге вакыйга Әбраһә гаскәренең җиңелүенә сәбәп була. Бу – Пәйгәмбәребезнең бөек шәхес булуына ишарәли.

Әлеге вакыйга турында Аллаһы Тәгалә «Фил» исемле сүрә иңдерә.

أَلَمْ تَرَ كَيْفَ فَعَلَ رَبُّكَ بِأَصْحَابِ الْفِيلِ ﴿١﴾ أَلَمْ يَجْعَلْ كَيْدَهُمْ فِي تَضْلِيلٍ ﴿٢﴾ وَأَرْسَلَ عَلَيْهِمْ طَيْرًا أَبَابِيلَ ﴿٣﴾ تَرْمِيهِم بِحِجَارَةٍ مِّن سِجِّيلٍ ﴿٤﴾ فَجَعَلَهُمْ كَعَصْفٍ مَّأْكُولٍ ﴿٥﴾

**«Әй, Мөхәммәд галәйһиссәлам, күрмәдеңме, синең Раббың фил ияләренә нинди җәза биргәнен? (Мөхәммәд галәйһиссәлам туган елны Йәмән вәлисе Әбраһә, хаҗ кылуны Мәккәдән туктатып, үзенең шәһәренә күчерү өчен Кәгъбәтулланы җимереп юк итәм, дип филле гәскәр белән Мәккәгә килде. Ләкин теләгенә ирешә алмады, Аллаһы аларның өсләренә таш яудырып һәлак итте). Әллә Раббың аларның мәкерләрен батыл кылып, тырышуларын бушка чыгарды түгелме? Вә һәлак итмәк өчен алар өстенә төркем-төркем кошлар җибәрде. Кошлар аларны коелган таш белән атарлар. Аларны тапталган, чәйнәлгән салам кеби кылды».**

«Фил», 105

Дошман тар-мар ителгәннән соң, Аллаһының чиксез рәхмәте һәм рөхсәте белән, бөтен дөньяда изге нур балкыды. Бу нур – сөекле

пәйгамберебез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тууы иде.

Әминә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне тапканда башка хатыннарда була торган бернинди авырлыклар сизми, ләкин ул изге төшләр күрә. «Дөреслектә, син үзеңдә бу өммәтнең бөек кешесен йөртәсең. Аңа Мөхәммәд дип исем бирерсең», – кебек хәбәрләр бирелә аларда. Шундый төшләрне Пәйгәмбәребез галәйһиссәламнең бабасы Габделмотталиб та күрә.

Аллаһы Тәгалә фил гаскәрен һәлак иткәннән соң илле көн узгач, Әминә бөтен галәмнәргә сөенеч, шатлык һәм бәхет китерүче изге, нурлы бала таба. Әлеге бөек көн рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көне була. Бу мөбарәк көнне кешеләр күп кенә гадәти булмаган вакыйгаларга шаһит булалар.

Сыннар, потлар урыннарыннан кузгала, ә кайберләре сәҗдә кыла, чөнки аларны җимерәчәк кеше дөньяга килә.

Мәккәдән чыккан нур Шам (Сүрия) сарайларын нурландыра, чөнки бөтен дөнья буенча иман нурын таратучы кеше туа.

Хишам бине Урва сүзләре буенча, бу көнне бер яһүди – Мәккә сәүдәгәре – кораешлеләр утырган урынга килә һәм: «Әй кораешлеләр, бүген сездә бер бала тумадымы?» – дип сорый. Алар: «Белмибез», – дип җавап бирә. Яһүди: «Аллаһу әкбәр! Белмәсәгез, белегез. Мин әйткән сүзләрне истә калдырыгыз. Бүген бу өммәтнең пәйгамбәре дөньяга килде. Аның ике калак сөяге арасында бер билге бар», – дип әйтә.

Хәссән бине Сабит радыяллаһу ганһе сөйләгән: «Миңа җиде-сигез яшь иде. Мин күргән һәм ишеткән нәрсәләрне аңлый идем. Бер көнне иртә белән Йәсрибтә (хәзерге Мәдинә шәһәре) бер яһүди кычкырып: «Дөреслектә, бүген Әхмәд (пәйгамбәребезнең икенче исеме) исемле йолдыз балкыды, ул бүген төнлә туачак», – дип әйтте.

Мәхзүм бине Хани Әл-Мәхзүми сөйләве буенча, пәйгамбәребез галәйһиссәлам туган төнне фарсылар патшасы Хәсрәүнең биләмәләре

тетрәнә, унике балконы җимерелә. Утка табынучыларның мең еллар дәвамында өзлексез янган утлары сүнә.

Аллаһының Расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган елда яңгыр күп ява: игеннәр, җиләк-җимешләр башка елларга караганда күпкә уңдырышлырак була.

Ошбу сүзләр кемгәдер сәер булып тоелырга мөмкин, ләкин бу – хаклык. Бу вакыйгалар төрле тарихчылар тарафыннан өйрәнелгән. Алар барысы да боларның бернинди арттырусыз булганлыгын раслый. Әлеге вакыйгалар Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең киләчәктә бөек шәхес булачагын күрсәтә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бабасы Габделмотталиб, оныгының тууын белгәч, бик сөенә, тизрәк аны күрергә ашыга. Онызыгын кулына алып үбә, аннары аны саклык белән изге Кәгъбәтулла янына алып килә. Габделмотталиб Аллаһыга шөкер итә, онызы өчен дога кыла, аннары аңа Мөхәммәд дип исем куша.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәгалә безгә иң хәерле, иң гүзәл, вә нурлы пәйгамбәр – Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтеннән булырга насыйп итте. Раббыбыз Аллаһы бу турыда Коръәни-Кәримдә болай дип әйтә:

كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّـهِ

**«Ий сез Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәте, дөньяга чыгарылган өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз, Аллаһыга хак ышану илә ышандыгыз, кешеләрне хәерле эшләргә, изге гамәлләргә өнди белү белән өндәдегез һәм бозык, зарарлы эшләрдән тыя белеп тыйдыгыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110

Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә: «Сез хәерле өммәт булдыгыз», – ди. Монда сүз сәхабәләр турында бара, чөнки алар чын мәгънәсендә Пәйгамбәребез галәйһиссәллам өйрәткәнчә яшәде, алар аңа ихластан иярде, аннан үрнәк алды. Безгә хәерле өммәт булыр өчен сәхабәләр кебек изге гамәл-гыйбадәтләр кылып яшәргә, һәр урында һәм һәрвакытта да Аллаһыга һәм Аның Расүле Мөхәммәд галәйһиссәлламгә итагатьле булырга, үзебезне һәм башкаларны изгелеккә өндәргә һәм явызлыктан тыярга тырышу тиешле», – диде.

Барчабызга да сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтләрен үтәп яшәргә насыйп булса иде!

*Эмир хәзрәт Миңнемуллин,*
*Арча районы мөхтәсибе*

*15 ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында

Ике гаеттән олуграк булган изге җомга бәйрәмебез барчабызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә иминлек, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсен!

Ислам динебез биш баганадан тора. Аның беренче баганасы – иман китерү. Ул болай яңгырый:

أَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ

«Әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһ».

Мәгънәсе: «Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк. Шулай ук гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Мөхәммәд галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең колы һәм бәндәләргә дин өйрәтер өчен җибәрелгән илчесе».

Аллаһы Раббуль Гыйззә изге китабы Коръәни-Кәримендә болай дип әйтә:

لَقَدْ مَنَّ اللَّهُ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ إِذْ بَعَثَ فِيهِمْ رَسُولًا مِّنْ أَنفُسِهِمْ يَتْلُو عَلَيْهِمْ آيَاتِهِ وَيُزَكِّيهِمْ وَيُعَلِّمُهُمُ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَإِن كَانُوا مِن قَبْلُ لَفِي ضَلَالٍ مُّبِينٍ ﴿١٦٤﴾

**«Аллаһы мөэминнәргә үзләреннән пәйгамбәр күндереп зур нигъмәтләр бирде, пәйгамбәр мөэминнәргә Аллаһының аятьләрен укыр, аларны мөшриклектән, бидгать гамәлләрдән вә башка нәҗесләрдән пакьләр, дәхи Коръәнне һәм шәригать хөкемнәрен өйрәтер, гәрчә алар Коръән иңмәс борын ачык адашуда булсалар да».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:164

Бу елны истә калдыру
Әлбәттә кирәк инде.
Биш йөз җитмеш беренче ел
Фил елы булып килде[1].

Мөхәммәд дигән бик күркәм
Исемне алды малай.
Йөзе нурлы, үзе нурлы
Елау да бик юк алай.

Рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көне – дүшәмбе көнендә Мәккә шәһәрендә Габдулла белән Әминә яшәгән йортта нурлы бала туа. Бабасы Габделмоталлиб онытының тууын белгәч бик сөенә. Тизрәк аны күрергә ашыга. Оныгын кулына алып, сөенеп үбә. Аннары аны саклык белән изге Кәгъбәтулла янына алып килә. Бабасы Аллаһыга шөкраналар әйтеп, оныгы өчен догалар кыла. Һәм аңа Мөхәммәд дип исем куша.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә иң хәерле, иң гүзәл, иң хөрмәтле үрнәк пәйгамбәр – Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтеннән булырга насыйп итте. Аллаһы Раббыбыз бу турыда Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

1 571 нче елның апрель ае 12нче көн дүшәмбедә, таң вакытында.

كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ ۗ وَلَوْ آمَنَ أَهْلُ الْكِتَابِ لَكَانَ خَيْرًا لَّهُم ۚ مِّنْهُمُ الْمُؤْمِنُونَ وَأَكْثَرُهُمُ الْفَاسِقُونَ ﴿١١٠﴾

**«Ий сез Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәте, дөньяга чыгарылган өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз, Аллаһыга хак ышану илә ышандыгыз, кешеләрне хәерле эшләргә, изге гамәлләргә өнди белү белән өндәдегез һәм бозык, зарарлы эшләрдән тыя белеп тыйдыгыз. Китап әһелләре иман китереп, Коръән белән гамәл кылсалар, әлбәттә, алар өчен хәерле булыр иде. Алардан Коръән белән гамәл кылучы мөэминнәр бар, ләкин аларның күбрәге – фасыйклардыр».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110

Һәрберебез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәламнең тормышын үрнәк итеп алырга тырышабыз. Расүлебез галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә: «Мин күркәм әхлакны камилләштерү өчен җибәрелдем»[1], – дип әйткән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм авырлыгын да, җиңеллеген дә, сөенечен дә, кайгысын да сабырлык һәм шөкер итү белән үткәрә белә торган үрнәк шәхес. Аллаһы Тәгалә Коръәндә Мөхәммәд галәйһиссәламне мактап болай дип әйткән:

وَإِنَّكَ لَعَلَىٰ خُلُقٍ عَظِيمٍ ﴿٤﴾

**«Дөреслектә, син югары әхлак иясе»**.

«Нун», 68:4

1 Имам Әхмәд бине Хәнбәлнең Мөснәденнән.

Ул игелекле, итагатьле, шәфкатьле, миһербанлы, тыйнак була. Бу сыйфатлар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмдә иң камил дәрәҗәдә иде.

Матур да ул, батыр да ул
Гаделлек тә җитәрлек.
Сабырлык та мул үзендә
Чынлап та ис китәрлек.

Сыннарны сөйми, табынмый
Бер сынның да үзенә.
Бары тик колак саладыр
Бер Аллаһының сүзенә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм туганчы атасы Габдулла дөньядан киткән була. Ә анасы Әминә малайга алты яшь булганда вафат була.

И кайгы, нигә бик иртә
Ишеккәйне шакыдың?
Ятрәбкә барган җирендә
Үлеп калды әниең.[1]

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә һәрбер адәм баласын сыный. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бер хәдисендә: «Мөселманның хәле гаҗәптер, чөнки аның һәрбер гамәле хәерледер. Әгәр дә аңа шатлык килсә, ул Раббысына шөкраналар әйтер. Әгәр дә бер авырлык килсә – сабыр итәр», – дип бәян ителә.

Әйе, мөхтәрәм җәмәгатем, мөселманнар тормышында Аллаһы тәкъдире белән төрле-төрле хәлләр булып тора. Менә безнең өчен үрнәк

---

[1] Аны Әбвада күмәләр.

булган Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышындагы гыйбрәтле риваятен искә алыйк.

Саубуллашу хаҗы узып, берничә ай үткәч, Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә: «Бәкыйгъ каберлегенә барып, вафат булган, шәһит булып киткән мөселманнарга дога кылырга», – дигән Аллаһы Тәгаләнең әмере килде. Һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Әбү-Мувәйһибә дигән сәхабәне үзе белән алып, Бәкыйгъ каберстанына барды, һәм шунда Әбү-Мувәйһибәгә: «Аллаһы Тәгалә миңа шунда җәсәдләре, тәннәре булучы мөселманнарга дога вә истигъфар кылырга әмер итте. Һәм дә ике әйберне ихтыяр кылды. Беренчесе, җир йөзендә булган барлык хәерлекләрнең ачкычы, ягъни шул байлыкларның хуҗасы булып җирдә калу. Һәм икенчесе, җәннәт ачкычы бирелеп, Аллаһы Раббың белән очрашу», – дип хәбәр бирде. Әбү-Мувәйһибә: «Йә Расүлуллаһ, син безнең белән калуны сайлагансыңдыр бит?» – дигәч, «Юк, Бөек Затым белән очрашуны ихтыяр кылдым», – диде.

Каберстаннан кайтуга Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә башы авыртканы турында әйткән иде. Ләкин Расүлебез галәйһиссәлам: «Юк Гайшә, минем башым синекенә караганда катырак авырта», – диде. Шул вакыттан Пәйгамбәребезнең авыруы башланды һәм ул үлем сырхавы иде. Сәхабәләр: «Йә Расүлуллаһ, пәйгамбәрләр дә үлем авыруы белән авырыйлармы, аларга да шулай бик кыен буламы?» – дип сорагач, «Әй сөекле сәхабәләрем! Сезнең бер кеше авыртканы, безгә ике кеше авыртуы булып төшә», – дип хәбәр итте. Хәле авырайгач, кешеләргә имам булып торуны Әбү Бәкер Әс-Сиддыйк радыяллаһу ганһегә әмер итте. Шул вакыттан Пәйгамбәрез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тугры дусты намазлар алып бара башлады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәле авырайганнан-авырая барды. Ул җиде коеның суын алып килеп өстенә сибүләрен теләде. Шул җиде коеның суын алып килеп өстенә сибеп тордылар. Шулай иткәч, хәле яхшырган кебек булды.

Аның өе мәчет белән янәшә тору сәбәпле, минбәргә чыга алды һәм мөселманнарга мөрәҗәгать итеп хотбә сөйләде: «И кешеләр, сез дөнья малы белән кызыгып китәрсез, мал җыюда ярышырсыз, дип куркам. Һәм иң яманы: Аллаһыга ширек катарсыз, дип борчылам. Миннән соң һәм бу буыннан соң киләчәк мөселманнарга, Кыямәт көненә кадәр яшәячәк мөселман кардәшләребезгә миннән сәлам әйтегез! Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ», – диде.

Аллаһының Расүле дога кылып, Аллаһының сәламен безгә теләде. Вафат булыр вакыты җиткәч тә шушы хәерле өммәтен искә алды.

Бервакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кызы Фатыйма радыяллаһу ганһәне үз янына чакырды. Колагына ике сер әйтте. Фатыйма радыяллаһу ганһә беренчесен ишеткәч елады, ә икенчесеннән соң елмайды. Шуннан соң Гайшә радыяллаһу ганһә Фатыйма радыяллаһу ганһәдән: «И Фатыйма, сиңа Расүлебез нинди сер әйтте?» – дип сорады. Ул: «Сер әйтелми», – дип җавап бирде. Ләкин Пәйгамбәребез вафат булганнан соң серне хәбәр итте: «Беренче сере: Расүлебез һәр ел саен Җәбраил галәйһиссәлам каршына утырып, Коръәнне укып чыга иде. Ләкин бу елны Рамазан аенда Коръәнне ике мәртәбә хәтем кылды. Коръәндә хата китмәсен, кешеләргә дөрес барып җитсен өчен, Җәбраил галәйһиссәлам каршына утырып укып чыкты. Моны белгәч, Фатыйма радыяллаһу ганһә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең соңгы вакытлары булганын аңлап елады. Икенче сере: «Ий Фатыйма, син бу өммәт хатыннарының (иманлы хатын-кызларның) иң хөрмәтле кешесе булуың белән риза түгелме әллә?» – дип сорау биргәч, Фатыйма радыяллаһу ганһә елмайды.

Өйдә утырганда Гайшә радыяллаһу ганһә нидер сизенгән кебек булды. «Әллә Җәбраил галәйһиссәлам килдеме?» – дип сорады. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Юк, бу үлем фәрештәсе – Газраил галәйһиссәлам килде. Ишек төбендә минем рөхсәтемне көтеп тора», – дип җавап кайтарды.

Пәйгамбәрләргә Аллаһы Тәгалә шундый өстенлек бирде: Газраил галәйһиссәлам рухларын үзләренең рөхсәте белән генә ала торган булды. Шуннан соң Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйтте: «Туктап тор, мин дустым Җәбраил белән киңәшләшеп алыйм», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам исә: «Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы сине сагынды һәм Ул сине көтә», – дип хәбәр итте. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үлем фәрештәсенә үзенең җанын алырга рөхсәт итте.

Ул вакытта Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе өйдә юк иде. Әйләнеп кайтканда, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм җан тәслим кылган иде инде. Гомәр радыяллаһу ганһе: «Валлаһи, Расүлебез үлмәде! Әгәр арагыздан берәрегез: «Мөхәммәд үлде», – дисә, кылычым белән башын өзәм», – дип, кылычын әзерләп куйды. Моннан соң Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе минбәргә чыгып хотбә сөйләде: «Әгәр дә берәрегез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә гыйбадәт кыла торган булсагыз, белегез, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үлде. Әгәр дә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кыла торган булсагыз, белегез, хакыйкатьтә – Аллаһы Терек, Ул беркайчан да үлми!» – дигән сүзләрне әйтте.

Шуннан соң Гомәр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең вафатына ышанды.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үлеме якынлашканда, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе аннан: «Йә Расүлем, җеназа намазын ничек укырбыз?» – дип сорагач, Аллаһының Илчесе: «Әгәр мине госелләндереп кәфенгә киендерсәгез, бер сәгатькә калдырыгыз, чөнки иң беренче миңа җеназа намазын Җәбраил галәйһиссәлам, аннан соң Микаил галәйһиссәлам, аннан соң Исрафил галәйһиссәлам, аннан соң үлем фәрештәсе – Газраил галәйһиссәлам һәм аның гаскәре, аннан соң калган фәрештәләр, аннан соң төркем-төркем булып сез укыячаксыз, ин шә Аллаһ!» – диде.

Шулай итеп, дөньяда бу җиргә аяк баскан иң хәерле, Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә каршында иң хөрмәтле, Кыямәт көнендә үзенең өммәте өчен шәфәгать кылучы зат булган, пәйгамбәрләрнең имамы булган Нәбиуллаһ, Расүлуллаһ, Хәбибуллаһ – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, вафат булды.

Сырхау килде, хушлашты ул
Фатыйма кызы белән.
Сөекле Гайшә хатыны
Һәм дә бик күпләр белән.

Зур рәхмәтләр сиңа Аллаһым
Биргәнгә Расүлеңне.
Нурлы йөзле мөселманнар
Барлык илдә күренде.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарга ике әйберне калдырды. Ул: Аллаһының китабы – Коръәни Кәрим һәм үзенең сөннәте – Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы, аның кылган гамәлләре, әйткән сүзләре.

Вәгаземнең ахырын Расүлебез галәйһиссәламнең хәдисе белән тәмамлыйк: «Бер-берегезгә бүләкләр бирешегез, чөнки бүләкләр арагыздагы мәхәббәтне арттырыр һәм күкрәгегездәге керләрне чыгарыр».

Аллаһы Тәгалә безгә барчабызга да Расүлебез галәйһиссәламгә охшарга насыйп әйләсен. Аллаһы Раббыбыз кылган гамәлләребез өчен әҗер-саваплар насыйп итсә иде. Бәндәчелек белән эшләгән гөнаһ, хата-кимчелелекләребезне ярлыкап, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәфәгатьләренә ирешсәк иде. Җәннәтләрдә очрашырга насыйп итсен иде.

*Фәнис хәзрәт Низамов,*
*Аксубай районы, Яңа Дума авылы имам-хатыйбы*

*22 ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Нәфел намазларының өстенлеге

Барлык мактау, хәмед вә сәналәр дөньяларны барлыкка китерүче, барчабызны да һәрдаим нигъмәтләндереп торучы, һәр гамәлебезне белүче вә аның өчен гадел рәвештә хөкем итәчәк, Үз рәхмәтенә ирешүчеләрне мәңгелек җәннәткә һәм бозыкларны җәһәннәмгә кертәчәк Бөек Зат – Аллаһыга булсын!

Соңгы пәйгамбәр итеп иңдерелгән, дөньяга Раббыбызның сүзләрен вә шәригатен тараткан, җәннәт ишеген беренче булып ачачак вә үзенең өммәтен – безләрне беренчеләрдән булып анда алып керәчәк Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлар булсын!

Барчаларыбызга да Аллаһы Тәгаләнең сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булса иде!

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән безнең өчен бик көчле кодси хәдис китерелә: «Аллаһы Тәгалә болай ди: «Әүлияләремә каршы чыкканнарга мин дошманлык игълан итәм! Колым Миңа якынаям, дип эшли ала торган иң саваплы гамәл – Миннән аңа фарыз итеп йөкләнгәннәредер. Вә нәфел гамәлләрен үтәп, ул Миңа шулчаклы якынаер ки, хәтта сөекле колыма әйләнер. Әгәр дә сөеклемә әйләнсә, Мин аның колагы белән тыңлаучы булырмын, вә аның күзе белән күрүче булырмын, вә аның кулы белән тотучы булырмын, вә аның аяклары белән йөрүче булырмын. Әгәр ул Миннән берәр нәрсә сораса, һичшиксез бирермен. Әгәр Миңа сыенса, һичшиксез, аны саклармын. Вә үлемне теләмәгән мөэминнең җанын

алганда икеләнгән шикелле, Мин бервакытта да алай нык икеләнгәнем юктыр»[1].

Әлеге хәдистә Аллаһы Тәгалә үзенең сөекле коллары хакында хәбәр итә. Бу бөек дәрәҗәгә ирешкән кешенең урыны чыннан да бик зурдыр. Шуңа күрә Раббыбыз аларга «каршы чыга күрмәгез» ди. Югыйсә, Аллаһы Тәгаләнең ачуына юлыгырга мөмкинбез.

Шуннан соң Раббыбыз әлеге дәрәҗәгә ирештерә торган юлларны тасвирлый. Аларның иң саваплысы фарызларны үтәү. Икенчесе – нәфел гамәлләргә бик игътибарлы булудыр. Әгәр кеше әлеге юнәлештә ихласлык белән тырышлык күрсәтсә, Аллаһы Тәгаләнең сөекле колына әйләнәчәк. Шулвакытта аның барлык догалары тормышка ашыр, дошманнары бер зарар да китерә алмас. Күзләре вә колаклары начарлыктан ерак, эшләре уңышлы, юллары имин булыр. Кешеләр гомер буе эзләп йөри торган бәхет шул түгелме?!

Мөселман буларак әлеге бәхет юлында без инде фарызларын үти башладык. Аллаһы Тәгалә кабуллардан гына кылсын! Беребезне дә әлеге юлдан тайпылдыра күрмәсен! Ул теләгән кеше генә хаклыкны аңлый, вә Ул теләмәгән кешене беркем дә туры юлга бастыра алмый. Димәк безнең дини булуыбыз бары тик Раббыбызның безгә күрсәткән мәрхәмәте вә олуг бүләгедер!

Шуңа күрә Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

إِنَّكَ لَا تَهْدِي مَنْ أَحْبَبْتَ وَلَٰكِنَّ اللَّهَ يَهْدِي مَن يَشَاءُ ۚ وَهُوَ أَعْلَمُ بِالْمُهْتَدِينَ ﴿٥٦﴾

**«Дөреслектә, син яраткан кешеңне туры юлга күндерә алмассың. Бары тик Аллаһы гына теләгән бәндәсен күндерәдер».**

«Касас / Хикәя», 28:56

---

[1] Имам Бохари 6502, имам Бәйһакый 690 хәдисләр җыентыгыннан.

Ләкин Аллаһыга якынаю юлларының икенчесен – нәфел гамәлләрне үтәргә без ашыкмыйбыз. Югыйсә, бу гамәлләр безнең дәрәҗәбезне күтәрер, Аллаһы Тәгаләгә тагы да якынайтыр иде. Бәлки күбебез аның нинди кыйммәтле икәнен аңлап бетермибездер?! Шуңа күрә түбәндәге хәдисләргә игътибар итеп карыйк әле.

Нәфел гыйбадәтләренең иң зурысы – намаз. Шуңа күрә пәйгамбәребез күп вакытын намазда үткәрә торган булган һәм сәхабәләр дә аның үрнәген үз тормышларында кулланганнар. Шулай бер көнне Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Рабига бине Кәгъб Әл-Әсләмийгә болай дигән: «Үзеңне күп сәҗдә кылып бает!» Ягъни сәҗдә кылып, үзеңнен Ахирәттәге урыныңның дәрәҗәсен күтәр, дигәнне аңлата.

Сәҗдәнең дәрәҗәсен аңлата торган тагын бер хәдис:

«Үз Раббысына кешенең иң якын халәте сәҗдәдәдер, шуңа күрә ул вакытта күбрәк дога кылыгыз»[1].

Димәк, нәфел намазлары Раббыбыз каршындагы дәрәҗәбезне күтәрергә иң зур сәбәптер. Кызганыч, күп мөселманнар аңа битараф кала! Югыйсә, аларны башкару безгә авыр түгел һәм вакытны да күп алмый. Шуңа да аларны укый башласак иде!

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм нәфел намазларын бер дә калдырмаска тырышкан. Иң яратып укый торганнарының берсе – төнге намаз иде. Озак басып торудан хәтта аяк үкчәләре яргаланган. «Ник алай үзеңне җәфалыйсың?» дигән сорауга җавабы да бик кыска булган: «Әллә мин рәхмәтле кол булырга тиеш түгелме?!» Аллаһы Тәгалә тәһәҗҗөд намазы хакында хәтта Коръәндә дә әйтә:

تَتَجَافَىٰ جُنُوبُهُمْ عَنِ الْمَضَاجِعِ يَدْعُونَ رَبَّهُمْ خَوْفًا وَطَمَعًا وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنفِقُونَ ﴿١٦﴾

---

[1] Имам Мөслим 482, имам Әбү Давыд 875, имам Нәсаи 2/226 хәдисләр җыентыгыннан.

**«Раббыларына курку вә өмет белән ялварыр өчен алар тәннәрен йокы урыннарыннан кубаралар...»**

«Сәҗдә», 32:16

Бу хакта Гайшә радыяллаһу ганһә дә: «Төнге намазларыгызны калдырмагыз, чөнки Аллаһының Илчесе аларны калдырмый иде. Авырса яисә хәле булмаса, утырып булса да укый иде» – дип әйтә торган булган.

Әлеге вакытта Раббыбыз барлык догаларны кабул итә вә гөнаһларны ярлыкый. Шуңа күрә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәһәҗҗөд намазына зур игътибар биргән.

Нәфел намазларының тагын бик саваплысы – доха намазы. Кояш чыгып, сөңге микъдарына күтәрелеп зәвәл вакыты җиткәнчегә хәтле укыла торган намаз. Бу хакта хәдистә болай дип китерелә:

«Һәр иртә белән һәрберегезнең буыннары садака бирергә тиешледер. Һәр тәсбих (сөбеханәллаһ) садакадыр. Һәр тәхмид (әлхәмдүлилләһ) садакадыр. Һәр тәһлил (ләә иләәһә илләллааһ) садакадыр. Һәр тәкбир (Аллаһу әкбәр) садакадыр. Яхшылыкка өндәү садакадыр. Яманлыктан тыю садакадыр. Вә барлык шушы гамәлләрне ике рәкәгать доха намазы алмаштырадыр»[1].

Тәһарәт алганнан соң укыла торган намазның дәрәҗәсе дә бик зур. Шулай, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Билял радыяллаһу ганһенең тавышын җәннәттә ишеттем, дип хәбәр итте. Сәбәбен сораганнан соң Билял радыяллаһу ганһе «Тәһарәт алган саен мин намаз укыймын», – диде.

Берәр төрле зур эшне башкару яисә башкармау турында икеләнгәндә истихарә намазын укырга була. Аны укыгач, гадәттә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә эшнең хәерлесен сорап дога белән ялвара торган булган.

---

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Шулай ук әүвәбин намазы да бик саваплы булып исәпләнә. Бу хакта Әт-Табәрани җыентыгында түбәндәге хәдис китерелә:

«Кем дә кем ахшам намазыннан соң алты рәкәгать нәфел намазы укыса, гөнаһлары, диңгез күбеге кебек күп булса да, ярлыканыр».

Аннан тыш кояш яисә ай тотылганда, зур шатлык яисә кайгы килгәндә укыла торган намазлар да бар.

Гомумән нәфел намазларының төре бик күп, ләкин мәгънәсе бер: Раббыңа якынаю, аның сөекле колына әйләнү. Димәк, моңа кадәр без битараф булган әлеге намазларны торгызсак, һичшиксез, дәрәҗәбез күтәрелә торган булыр. Аллаһы Тәгалә барыбызга да тәүфыйк вә һидаять бирсен!

*Булат хәзрәт Раупов,*

*Лениногорск шәһәренең «Ихлас» мәчете имамы*

*29 ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Башка милләт һәм дин кешеләренә хөрмәт һәм алар белән тату яшәү

Барча мактаулар, хәмде-сәналар Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә. Аның хак хәбибе, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә дә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгаләнең безне төрле милләт, дин вәкилләре итеп яратуының хикмәте бар. Боларны аңлаган ихлас мөселман кешесе беркайчанда башка милләт, дин кешеләренә начар мөгамәләдә булмый.

Кешеләрнең үзара дус-тату яшәүләренең мөһимлеге хакында Коръәни Кәримнең күп аятьләре бәян итә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا يَسْخَرْ قَوْمٌ مِّن قَوْمٍ عَسَىٰ أَن يَكُونُوا خَيْرًا مِّنْهُمْ وَلَا نِسَاءٌ مِّن نِّسَاءٍ عَسَىٰ أَن يَكُنَّ خَيْرًا مِّنْهُنَّ ۖ وَلَا تَلْمِزُوا أَنفُسَكُمْ وَلَا تَنَابَزُوا بِالْأَلْقَابِ ۖ بِئْسَ الِاسْمُ الْفُسُوقُ بَعْدَ الْإِيمَانِ ۚ وَمَن لَّمْ يَتُبْ فَأُولَٰئِكَ هُمُ الظَّالِمُونَ ﴿١١﴾

**«Ий мөэминнәр, бер кавем икенче бер кавемне кимсетмәсен, ул кимсетелгән кавемнең кимсетә торган кавемнән яхшырак булуы ихтималдыр, шулай ук хатыннар икенче хатыннарны кимсетмәсеннәр, кимсетелгән хатын кимсетүче хатыннан яхшырак булуы ихтималдыр, вә дин кардәшләрегезне гаепләп кимсетмәгез, вә бер-берегезгә яман исемнәр илә дәшмәгез,**

**мөэмин булганнан соң, фасыйк исеме ни яман исемдер. Бу эшне эшләүчеләр тәүбә итеп төзәлмәсәләр, алар залимнәрдер».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:11

Аллаһы Тәгалә кешеләрне үзара ызгышып, талашып яшәсеннәр өчен яратмады. Ул адәм балаларының бер-берләрен рәнҗетеп, кан коеп яшәүләрен теләми. Кызганычка, кешеләр бер дә юктан тавыш чыгарып, уртак тел таба алмыйча, үзара талашып яши бирә. Үзләренең шәхси мәнфәгатьләрен, ихтыяҗларын кайгыртканнары аркасында башкаларның хокукларын бозучылар күп. Нәтиҗәдә, үзен генә хаклы дип яшәүчеләр башкалар белән конфликтлы хәлләргә тарый. Мондый очракларга мәсьәләне зурга җибәрмичә генә хәл итә белү яхшы, әлбәттә. Шуңа да бәхәсләр аркасында кешеләр арасында фетнә чыгудан сак булсак иде. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اجْتَنِبُوا كَثِيرًا مِّنَ الظَّنِّ إِنَّ بَعْضَ الظَّنِّ إِثْمٌ ۖ وَلَا تَجَسَّسُوا وَلَا يَغْتَب بَّعْضُكُم بَعْضًا ۚ أَيُحِبُّ أَحَدُكُمْ أَن يَأْكُلَ لَحْمَ أَخِيهِ مَيْتًا فَكَرِهْتُمُوهُ ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ ۚ إِنَّ اللَّهَ تَوَّابٌ رَّحِيمٌ ﴿١٢﴾

**«Ий мөэминнәр, күп гөманнан**[1] **сакланыгыз, тәхкыйк, бәгъзе**[2] **гөманда гөнаһ бардыр. Вә кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, кеше гаебен эзләмәгез вә бәгъзегез бәгъзегезне гайбәт кылмасын! Әллә сезнең берәрегез үлгән кардәшенең итен ашауны сөярме? Сез, әлбәттә, аны мәкруһ күрдегез, гайбәт сөйләүне дә шулай мәкруһ күрегез! Аллаһыдан куркыгыз, гайбәт эшләреннән тәүбә итегез! Шиксез, Аллаһы тәүбә итеп төзәлгән кешеләрне гафу итүче вә рәхимледер».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:12

---

1 Уй-фикерләрдән (ред.).

2 Кайбер (ред.).

Кызганычка, күп санлы һәм көчлерәк халыклар икенчеләрне түбәнсетергә дә ярый, дип саныйлар. Кешедәге бу халәт аның нәфесе азганнан килә. Ул үзен башкалардан яхшырак, дип уйлый башлый. Мондый ялгышлык адашканлык аркасында, без барыбыз да Аллаһының мәхлүкълары икәнен, һәрберебезнең дә җир йөзендә яшәргә хакыбыз барлыгын онытабыз, шуның белән гөнаһка төшәбез. Менә шушы гамәлләрдән сак булсак иде, мөхтәрәм дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

وَلَا تَمْشِ فِي الْأَرْضِ مَرَحًا ۖ إِنَّكَ لَن تَخْرِقَ الْأَرْضَ وَلَن تَبْلُغَ الْجِبَالَ طُولًا ﴿٣٧﴾

**«Җир өстендә зураеп күкрәк киереп йөрмә, чөнки син никадәр зурайсаң да җирне ертырга хәлеңнән килмәс һәм никадәр зурайсаң да таулар хәтле зурая алмассың!»**, – дип әйтә.

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:37

Үзара фетнәләр чыгу турында сүз кузгалткач, шәйтанның да үз эшен башкаруын онытмасак иде. Ул безгә, тегеләр башка милләт, дин, этнос, раса кешесе, сез аларга караганда өстенрәк дип, пышылдап шик-шөбһә тудырып тора.

إِنَّمَا يُرِيدُ الشَّيْطَانُ أَن يُوقِعَ بَيْنَكُمُ الْعَدَاوَةَ وَالْبَغْضَاءَ فِي الْخَمْرِ وَالْمَيْسِرِ
وَيَصُدَّكُمْ عَن ذِكْرِ اللَّهِ وَعَنِ الصَّلَاةِ ۖ فَهَلْ أَنتُم مُّنتَهُونَ ﴿٩١﴾

**«Хәмер эчүегез һәм отыш уеннары уйнавыгыз белән, әлбәттә, шәйтан арагызда дошманлыкны һәм бер-берегезгә һөҗүм иттерә торган ачуны булдырырга тели вә Коръән вәгазеннән, намаз укудан сезне тыярга тели, шулай булгач, ул шәйтан эше булган – нәҗесләрдән тыеласызмы? Әллә тыелмыйсызмы? Әлбәттә тыелыгыз!»**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:91

Тәкәбберлек, үзеңне башкалардан яхшырак дип санау аркасында кылынган гөнаһларның тәэсире башкаларга да күчә. Ягъни бу гөнаһы белән ул бүтәннәрне дә гөнаһка тарта. Иблис мәлгунь тәкәбберлеге белән Адәм галәйһиссәлам алдында сәҗдә кылмады, шул гамәле белән Аллаһының ачуына төште, адәм затына дошман булды. Әле моның белән генә бетми, ул Аллаһы Тәгаләнең Адәм галәйһиссәламне зурлаганына, аны яратканына ачуы килеп, хөсетлек илә атабыз Адәм галәйһиссәлам белән анабыз Хәвва радыяллаһу ганһәне ялгыш юлдан яздырырга план кора. Ялган һәм мәкер юлы белән Аллаһы Тәгаләнең тыйган җимешен ашата.

Фикерләүчеләр өчен бу кыйссада гыйбрәтле дәрес һәм нәсыйхәт бар. Эзлеклелек буенча карасак, күп кенә гөнаһларның башында тәкәбберлек, көнчелек һәм үч ята. Шушы начар сыйфатлар белән чолганып алган кеше башкаларга зыян сала, Аллаһы Тәгаләнең тыйганнарыннан тыелмыйча, гөнаһка керә. Моның белән үзен дә, башкаларны да һәлакәткә алып бара. адәм баласы бары бер гамәле белән генә үзен Аллаһының ачуыннан саклап калырга мөмкин: ул ихластан хатаңны танып, тәүбәгә килү. Шул рәвешле, атабыз Адәм галәйһиссәлам дә вакытында үзенең гаебен танып, Аллаһыдан гафу сорый, һәм мәрхәмәтенә, гафу итүенә лаек була. Һичшиксез, Аллаһы Тәгалә гаепләрен танып, гафу сораучыларны кичерә. Моның турында Ул Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَإِنِّي لَغَفَّارٌ لِّمَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ صَالِحًا ثُمَّ اهْتَدَىٰ ﴿٨٢﴾

**«Тәүбә итеп, иман китергән вә Коръән юлы белән изге гамәлләр кылган, соңра туры юлга күнелеп, үлгәнче хак юлда таза торган кешеләрне Мин, әлбәттә, ярлыкаучымын».**

«Та Һа», 20:82

Аңлавыбызча, бүгенге көн проблемаларының нигезендә берәүләрнең үзләрен икенчеләрдән яхшырак дип тоюы, тәкәбберләнү, көнләшү кебек сыйфатлар ята. Тәкәбберлек, үз чиратында,

көчлерәкләрнең көчсезләрне түбәнсетүенә, хокукларын бозуга китерә. Тарихка күз салсак, сугышлар, конфликтлар ике якның уртак тел таба алмаулары, юл куя белмәүләре аркасында килеп чыкты. Ә үзләрен башкалардан өстенрәк дип күрүчеләр, һәрвакыт хаклы дип уйлаучылар беркайчан да юл куя белми, башкалар белән дус-тату мөнәсәбәттә яшәргә омтылмый. Тәкәббер кешеләрнең үзләренә дә җиңел түгел, чөнки тәкәбберлек дигән «корт» кешене эчтән кимерә, аның бу дөньясын да агулый, теге дөнья бәхетеннән дә мәхрүм итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тузан бөртеге кадәрле генә тәкәбберлеге булса да, ул кеше җәннәткә керми», – дип әйткән.

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«Ий кешеләр, Без сезләрне ир вә хатын итеп халык кылдык, вә сездән тармаклар вә кабиләләр кылдык бер-берегезне таныр өчен, тәхкыйк сезнең Аллаһы хозурында хөрмәтлерәгегез – Аллаһыдан куркып, гөнаһлардан сакланучыгыздыр, Аллаһы белүче вә һәр эшегездән хәбәрдар».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Бу аятьтән күренгәнчә, без барыбыз да Аллаһы Тәгалә каршында тигез. Беребезнең дә башкаларны хурлап, кимсетеп яшәргә хакыбыз юк. Аллаһы Тәгалә байлыгыбызга, дәрәҗәбезгә, матурлыгыбызга түгел, ә тәкъвалыгыбызга карый. Аның алдында иң хөрмәтлебез дә гөнаһлардан ерак булганыбыз, Аллаһыдан куркып, тыйганнарыннан тыелып, кушканнарын үтәп яшәргә тырышучыбыз.

Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә тынычлык, иминлек биреп, белгәннәребез белән гамәл кылырга, ишеткәннәребез белән вәгазьләнергә һәм булган кимчелекләребезне бетереп, камиллеккә ирешергә насыйп итсә иде.

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*6 декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Ни өчен Аллаһы Тәгалә кешеләрне байларга һәм фәкыйрьләргә бүлеп яраткан?

Безне иман, ислам, Коръән нигъмәтләре белән нурландырган, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтеннән кылган, җирләрне вә күкләрне юктан бар иткән, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә олуг мактауларыбыз, хәмед-сәналәребез булса иде, шулай ук йөрәк түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барып ирешсә иде.

Адәм баласы гомер буена мул яшәү, байлык туплау, дәрәҗәле кеше булу турында хыяллана. Шул максатына ирешү өчен көн-төн тырыша, алны-ялны белми көч куя. Шуңа күпме омтылып та, теләгәненә ирешә алмаучылар арабызда шактый. Бактың исә, без кызыга торган һәм без ирешә алмый торган байлык, чынлыкта, Аллаһының саклавы нәтиҗәсе икән.

Без бер генә мизгелгә дә бу кыска вакытлы дөньяның адәм балалары өчен зур сынау урыны икәнен онытмаска тиешбез. Аллаһы Тәгалә үзенең бәндәләренә мал бирер, әмма кайберләре ярлы булырлар. Аллаһы Тәгалә һәркемгә нәрсәнең хәерле икәнен иң яхшы белүче. Байлык белән дәрәҗә дә кемгәдер сынау буларак бирелергә мөмкин. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм байлык белән дә, ярлылык белән дә сыналган. Акчасы, малы булган вакытта масаймаган, кешеләрне мыскыл итмәгән, киресенчә, байлыгын садакага сарыф иткән, халыкка файда китергән. Ә инде акчасы беткән вакытларында сабыр иткән. Ислам дине һәммәбезне дә менә шулай ике яклы булырга өйрәтә: байлыгың

булганда якыннарыңны, мохтаҗларны, кардәшләреңне онытмаска, гаиләңә сарыф итәргә, әгәр дә малың юк икән – сабыр итәргә һәм тырышып эшләргә боера. Кеше үзе тырышса гына, Аллаһы Раббыбыз аңа ярдәм итәчәк. Пәйгамбәребез холкындагы кешене Ислам дине иң яхшы холыклы, хәерле кеше дип атый. Моннан тыш, без кешенең белем, тәҗрибә һәм хезмәтенең байлыкка ирешүдәге кирәкле сәбәпләре булуын да онытмаска тиеш. Әмма байлыкка ирешү өчен бу сыйфатлар җитәрлек түгел. Беренчедән, мөселман кардәшләрем, ризыкка бәйле мәсьәләне исәпкә алырга кирәк. Мул тормышта яшәргә теләгән һәр кеше барлык кирәкле гамәлләрне эшләргә, ә шуннан соң Аллаһы Тәгаләнең биргән ризыгы белән канәгатьләнергә тиеш. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә биргән байлыкның һәм ярлылыкның сынау икәнен аңларга тиешбез. Коръәндә болай диелгән:

إِنَّمَا أَمْوَالُكُمْ وَأَوْلَادُكُمْ فِتْنَةٌ ۚ وَاللَّهُ عِندَهُ أَجْرٌ عَظِيمٌ ﴿١٥﴾

> **«Сезнең малларыгыз һәм балаларыгыз сезнең өчен фәкать фетнә. Әмма Аллаһы юлында булганнарга Аллаһы хозурында олуг әҗерләр бар».**

«Тәгабүн / Алдану», 64:15

Байлыкка ия булу әле бәхетле булу дигәнне аңлатмый. Дөньяда бай булып та, бәхетсез яшәүчеләр, үз-үзләренә кул салучылар да аз түгел.

Шунысын да аңларга кирәк: хәерчелек турыдан-туры бәхеткә илтә торган юл түгел. Тормышта хәерчелек аркасында өметләрен өзгән кешеләр күп очрый. Моннан күренгәнчә, үзенә күрә байлык та, хәерчелек тә бәхетнең төп сәбәпләре булып тормый. Эчке тынычлыкны канәгатьләндермичә, кешенең бәхете барыбер үзгәреп торачак, ул бөтен дөньяга хуҗа булса да, чын бәхеткә ирешә алмый.

Чыннан да, тормышта канәгать булу өчен, кеше тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән югарырак булган кешеләргә түгел, ә түбәндәгеләргә ка-

рарга тиеш. Күпчелек очракта кешеләр үзләренә Аллаһы Тәгалә биргән тиңсез байлык турында хәбәрдар түгел. Мәсәлән, күзләре күрми торган кеше беркайчан да өй кысанлыгыннан зарланмый. Ул күзләрем күрсә иде, дип хыялланып яши. Ачлык елында адәм балалары берсе дә алтын-көмеш турында түгел, ә ризык турында уйлый иде. Димәк, ярлылык һәм байлык тормышта беренче урында тормый. Пәйгамбәребез үзенең бер риваятендә болай дип әйткән: «Сезнең белән чагыштырганда күп бирелгән кешеләргә түгел, ә аз бирелгән кешеләргә карагыз»[1]. Икенче хәдистә: «Ий кешеләр! Чын байлык мал-мөлкәт түгел, ә киң күңеллелек», – диелгән[2]. Шуның белән Аллаһының Расүле чын байлыкны ачык бәян итә.

Канәгать булу сыйфаты булмаса, кеше байлык белән беркайчан да туена алмый. Ә эчке дөньясы бай булган кешенең ашарына булса – риза булыр. Чөнки ул рухи яктан бай.

Аллаһы Тәгалә ни өчен барлык колларын бай итмәгән? Чөнки барысы да җитәкче булса, кем җитәкләячәк һәм кем эшләячәк? Шул сәбәпле, кемдер җитәкче, кемдер гади хезмәткәр булырга тиеш. Болар барысы да Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнгән канун нигезендә тормышка ашырыла. Шуңа күрә кемдер бай, ә кемдер ярлы.

Әгәр бай кеше байлыгын изге максатларга сарыф итсә: Аллаһыга шөкер итеп, мохтаҗларга ярдәм итә һәм тормыш юлын изге гамәлләр белән бизи икән – мондый байлык яхшылык булып тора. Әгәр байлыгыннан зәкятләрен түләмәсә, мохтаҗларга ярдәм итмәсә, әлбәттә бу байлык бәхет китермәячәк. Коръәни Кәримдә болай диелгән:

وَالَّذِينَ فِي أَمْوَالِهِمْ حَقٌّ مَّعْلُومٌ ﴿٢٤﴾ لِّلسَّائِلِ وَالْمَحْرُومِ ﴿٢٥﴾

---

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

2 Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

**«Вә аларның малларында бер билгеле булган өлеш бардыр. Сораучы мохтаҗлар өчен вә сорамаучы мохтаҗлар өчен, ягъни аларга малларыннан тиешле өлешне бирерләр».**

«Мәгариҗ / Дәрәҗә», 70:24-25

Шулай ук «Әл-Бәкара» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

ٱلَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِٱلْغَيْبِ وَيُقِيمُونَ ٱلصَّلَوٰةَ وَمِمَّا رَزَقْنَٰهُمْ يُنفِقُونَ ﴿٣﴾

**«Ул тәкъва мөэминнәр күрмичә күргән кеби Аллаһыга ышаналар. Һәм йөкләтелгән намазларын вакытында укыйлар, һәм Без ризыкландырган нәрсәләрдән фәкыйрь мөселманнарга өлеш бирәләр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:3

Фәкыйрь кеше дә шулай ук кара икмәкне бәяли торган мөэмин булса, язмышы өчен риза булып яшәсә, бу аның өчен файда гына булачак.

Габдулла бине Гамредән риваять кылына. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Кешеләр Кыямәт көнендә җыелгач, алардан, бу өммәтнең фәкыйрьләре кайда, дип сорарлар. Алар торып басырлар һәм алардан, нинди гамәлләр кылдыгыз, дип соралыр. Алар: «Ий, Раббыбыз, Син безне сынадың һәм без сабыр иттек, Син байлыкны һәм солтанлыкны башкаларга бирдең», – дип җавап бирерләр. Һәм бу кешеләр җәннәткә башкалардан иртәрәк керер. Хисапның катысы дөньялыкта байлыгы һәм хакимлеге булган кешеләргә калыр», – дип әйтте.

Әйе, байлык һәм ярлылык кешеләрне Аллаһы Тәгалә тарафыннан сынау коралы булып тора. Безгә адәм балаларына, бу тормыш сынауларын лаеклы үтәргә насыйп булсын. Бер хәдистә әйтелгәнчә, «Аллаһы Тәгалә сезнең сурәтегезгә түгел, ә калебегезгә, гамәлләрегезгә карар». Тәннең

зәкяте – ураза, байлыкныкы исә – садака. Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәтләреннән тиешенчә, Раббыбыз бездән риза булырлык итеп файдаланыйк, мохтаҗларга ярдәмләшеп яшик, мөселман кардәшләрем. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

*Ирек хәзрәт Сәләхиев,*
*Әлки районы имам-мөхтәсибе*

*13 декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Диндә урта юлны табу һәм төрле фиркалардан ерак тору

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъде: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Һәм дә салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде.

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, без даими рәвештә Аллаһы Тәгаләгә хәмед-саналәребезне әйтәбез. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, Аның сөекле илчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребезне җиткерәбез.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, без биш вакыт намазның һәр рәкәгатендә Раббыбыздан сорыйбыз:

اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ ﴿٦﴾

**«Безне туры юлга күндер».**

«Фәтихә / Ачучы», 1:6

Туры юл – нәрсә ул? Ул – Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм юлы. Ул үзенең гамәлләре белән безгә хак юлны күрсәткән. Шуңа күрә без Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенә иярергә тиешбез. Безгә шул юлны күрсәтүче, аңлатучылар кем? Безнең галимнәребез.

Динебездә дүрт мәзһәб бар. Бу җирлектә яшәүче халыклар, шул исәптән, татарларның борынгы бабалары һәм аларның дәвамчылары

буларак без дә инде 1100 ел диярлек Хәнәфи мәзһәбе буенча барабыз. Бу – безнең туры юлыбыз. Әйтик, Кавказ халыклары нигездә Шәфигый мәзһәбенә иярә. Кайберләре – мәлики, хәнбәли мәзһәбләрендә. Шушы дүрт мәзһәб әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать төшенчәсен һәм шул хак юлны тәшкил итә. Без яшәгән җирлектә күпчелек шушы дүрт мәзһәбнең кайсын сайлаган – шуңа ияреpгә тиешбез. Чөнки теге яисә бу халыкның нәкъ шушы юнәлешкә тукталуы бүген генә булмаган һәм бер көндә генә хәл ителмәгән. Бүген бер мәсьәләне – хәнәфидән, икенчесен – шәфигыйдан алабыз икән, яисә мәзһәбләрне бөтенләй инкяр итәбез икән – димәк, Ислам динен үз мәнфәгатьләребезгә яраклаштырмакчы булабыз, тәкәбберлек кылабыз.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә шәйтан турында нәрсә ди?

فَسَجَدَ الْمَلَائِكَةُ كُلُّهُمْ أَجْمَعُونَ ﴿٧٣﴾ إِلَّا إِبْلِيسَ اسْتَكْبَرَ وَكَانَ مِنَ الْكَافِرِينَ ﴿٧٤﴾ قَالَ يَا إِبْلِيسُ مَا مَنَعَكَ أَن تَسْجُدَ لِمَا خَلَقْتُ بِيَدَيَّ ۖ أَسْتَكْبَرْتَ أَمْ كُنتَ مِنَ الْعَالِينَ ﴿٧٥﴾ قَالَ أَنَا خَيْرٌ مِّنْهُ ۖ خَلَقْتَنِي مِن نَّارٍ وَخَلَقْتَهُ مِن طِينٍ ﴿٧٦﴾

**«Фәрештәләрнең, барчасы берьюлы сәҗдә кылдылар. Мәгәр иблис сәҗдә кылмады. Тәкәбберләнде һәм кяферләрдән булды. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Ий иблис, Мин Үз кодрәтем белән яраткан Адәмгә сәҗдә кылудан сине нәрсә тыйды? Тәкәбберләндеңме? Яки бөекләрдән булдыңмы?» Иблис әйтте: «Мин Адәмнән хәерлерәкмен, чөнки мине уттан яраттың, Адәмне исә балчыктан яраттың».**

«Сад», 38:73-76

Бу кыйссаны һәрберебез белергә һәм аңларга тиеш. Башка фәрештәләр, Раббыларының боерыгына буйсынып, Адәм галәйһиссәламгә

сәҗдә кылды. Бер шәйтан гына баш тартты. «Мин уттан яратылган, ул – балчыктан», – дип әйтте. Тәкәбберлек кылды. Шуның аркасында ләгънәт кылынды һәм җәһәннәм әһеле булды. Әмма Аллаһы Тәгаләдән җәзасын Кыяматкә кадәр кичектерергә сорады. Һәм ул Ахырзаманга кадәр адәм балаларын адаштырып торачак, үзе белән бергә аларны да мәңгелек утка кертергә тырышачак.

Шәйтан мин-минлек юллары, иҗтимагый фикерләр, сәяси хәрәкәтләрне кулланып, аларны дингә кертергә тырыша. Шуның аркасында төрле фиркалар чыга. Алар Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм вафатыннан соң ук була. Аларның кулыннан хәтта исән чагында ук җәннәт вәгъдә ителгән хәлифәләр – Гомәр һәм Гали радыяллаһу ганһүмәләр һәлак була.

Без фикеһ мәсьәләсендә хәнәфиләр булсак, гакыйдәдә – Матуриди мәзһәбенә иярәбез. Имам Матуриди яшәгән чорда да, үзләре мөселман була торып, бөтенләй Ислам динендә булмаган, ят әйберләр сөйләүчеләр, шул рәвешле дингә үзгәреш кертергә теләүчеләр, фетнә чыгаручылар табыла. Имам Матуриди Коръән һәм сөннәткә ияреп, шуларга каршы хезмәтләр язып, аларга каршы сүз әйтә, хаклыкны аңлатырга тырыша.

Адашкан бәндәләр тарафыннан булдырылган төрле агымнар, секта тарафдарлары, белепме, йә үзләре ялгышыпмы – шуны хак дин, дип күрсәтмәкче була. Имеш, алар Коръәнгә, сөннәткә таяна. Ә без, шушы җирлектә 11 гасыр Хәнәфи мәзһәбендә яшәгәннәр, ялгыш юл белән барабыз. Онытмыйк, җәмәгать: Әбү Хәнифә – ул табигыйн. Әйе, ул сәхабә түгел. Ягъни Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үз күзләре белән күрмәгән. Әмма Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бер чорда яшәгән, аның белән бергә утырган, сорауларын бирә алган сәхабәләр белән очрашкан, алар белән аралашкан.

Бүген безгә: «Сез сөннәттән ерагайдыгыз!» – дип яла ягалар икән, шул гаепләүчедән сорыйк әле: «Ә сез хәдисләрне кайдан укыйсыз?» Мәсәлән,

имам Бохари китабыннан, яисә имам Мөслим дип җавап бирер. Күпчелек очракта ул гарәпчә белмәс, хәдисләрне туган теленә тәрҗемәдә генә укыган булыр. Ул бит хәдисләрне турыдан-туры Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән алмый. Имам Бохари хезмәте аша өйрәнә. Ягъни шулай ук галимнең фикерләренә таяна.

«Коръән буенча яшибез, дисез. Үзегез гарәп телен белмисез. Ничек аңладыгыз Коръәнне?» – дип сорыйк. «Тәфсирдән», – дип җавап кайтарыр. Әмма тәфсир ул – кеше сүзе. Аллаһы Тәгаләнең сүзе бер генә – ул гарәп телендә иңгән Коръәни Кәрим.

Безне диннән ерагаюда гаепләгән кешеләргә шушы сорауларны бирсәк, алар ачулана башлый. Нигә? Чөнки үзләре Коръән һәм сөннәт буенча яшәми. Ислам динен үз мәнфәгатьләренә җайлаштырган бәндәләрнең фикеренә таяна. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бернинди дә адашкан фирка тарафдары булмаган. Ул безгә хак динне күрсәткән. Һәм без Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенә тугры булырга тиеш.

Шәйтан ничек саташтыра? Имеш, хәнәфи мәзһәбенә дәлилләре юк. Сәхабәләр белән бер чорда яшәгән галимнең дәлилләре юк! Табигыйннәр, табиге-табигыйннәр вафат булганнан соң берничә гасырдан соң гына туган адашкан бәндәләрнеке бар! Ә Имам Әгъзамның, әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать галимнәре остазының дәлилләре юк. Бүген фетнә чыгарырга тырыша торган кайсы гына мәсьәләне алма, Хәнәфи мәзһәбендә ныклы дәлилләр бар. Мәзһәб беркайчан да дәлилсез булмый. Гади генә мәсьәлә. Намазны башка түбәтәй киеп уку. Безгә бүген нәрсә дияләр? Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм чалма киеп укыган. Хак! Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәр намазын чалма киеп укыган. Ә без түбәтәй дә кия алмыйбыз. Яланбаш укыйбыз. Әмма бит Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм беркайчан да яланбаш на-

маз укымаган. Шуны белә торып, яланбаш намаз уку пәйгамбәр сөннәтенә иярү буламы?

Безнең таркалуыбыз кемгә кирәк? Шәйтанга. Ул безне тарката. Ул безне җәһәннәмгә алып бара. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

«Мөселман өммәте бер тән кебектер, берәр әгъзасы авыртса, бөтен тән яна башлый», – дигән икән, шәйтан киресенчә эшләргә тырыша. Шәйтан бит ул бер кешене саташтыру белән генә туктамый. «Бу мәхәлләдә шушы бәндәне юлдан яздырыйм да – шул җитәр», – дип фикерләми ул. Аның максаты – бөтен мәхәлләне тар-мар китерү. Фетнә чыгару. Аның яшәешенең бердәнбер мәгънәсе – бөтен мөселман өммәтен бер-берсенә каршы чыгару. Бөтен өммәт талашсын, бер-берсе белән дус булмасын. Ул яман чир сыман. Мөселманнар – ул бер тән. Шушы тәннең кайсы гына әгъзасына эләкмәсен – бу чир бөтен тән буенча таралырга тырышачак. Мөселман мөселманга кардәш, дус һәм туган. Бер генә туганыбызның да җәһәннәмгә эләгүен теләмибез бит. Шуңа күрә бер җепкә ныклап ябышуыбыз, бердәм булуыбыз мөһим. Бу гамәлебез безгә вәсвәсәгә бирелмәс, шәйтанга юл ачмас һәм өммәтебез көчле булсын өчен кирәк.

«Йә Раббым, безне туры юлга күндер», дип әйтәбез. Догаларыбызда шуны күбрәк сорыйк. Үзебезне, балаларыбызны, туганнарыбызны, иңгә-иң торып намаз укыган кардәшләребезне хак юлдан алып бар, йә Раббым, дип ялварыйк. Бер-беребезгә хәерлесен телик. Хак юлдан тайпылмыйк. Бер-беребезне Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен яратыйк. Дин-Исламыбызны саклыйк. Бердәм булыйк.

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*20 декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Сәламәт гаилә – көчле җәмгыять

Аллаһы Тәгалә гаделлек белән бу дөньяда Үзенең кануннарын, кагыйдәләрен билгеләгән: адәм баласы Раббысының кушканнрын үтәп, тормышын гыйбадәт белән бәйли икән, ул Ахирәттә һәм дөньяда уңышка ирешә, бәхетле була. Әгәр дә Аллаһының әмерләрен үтәмәсә, тыйганнарыннан тыелмаса, ул Ахирәттә генә түгел, ә дөньяда ук бәхетсезлеккә, хурлыкка дучар була. Дөнья вә Ахирәттә кешене түбән һәм хур итә торган әйберләрнең берсе – эчкечелек.

Аллаһы Тәгалә һәртөрле исерткеч, акылны томалый торган әйберләрне түбәндәге аять белән тыйды:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنَّمَا الْخَمْرُ وَالْمَيْسِرُ وَالْأَنصَابُ وَالْأَزْلَامُ رِجْسٌ مِّنْ عَمَلِ الشَّيْطَانِ فَاجْتَنِبُوهُ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٩٠﴾ إِنَّمَا يُرِيدُ الشَّيْطَانُ أَن يُوقِعَ بَيْنَكُمُ الْعَدَاوَةَ وَالْبَغْضَاءَ فِي الْخَمْرِ وَالْمَيْسِرِ وَيَصُدَّكُمْ عَن ذِكْرِ اللَّهِ وَعَنِ الصَّلَاةِ ۖ فَهَلْ أَنتُم مُّنتَهُونَ ﴿٩١﴾

**«Ий мөэминнәр! Исертә торган эчемлекләр һәммәсе дә, отыш уеннары һәртөрлесе дә, сыннарга гыйбадәт итү – Аллаһыдан башка мәхлүкъларга табыну эшләре, шулай ук ырымлану – багучылык эшләре харамдыр, шәйтан эшләреннән булган пычрак эшләрдер, һәлак булудан котылмаклыгыгыз өчен бу нәҗес эшләрдән ерак булыгыз! Саклансагыз, шаять котылырсыз – өстенлек табарсыз. Хәмер эчүегез һәм отыш уеннары уйнавыгыз белән, әлбәттә, шәйтан арагызда дошманлыкны һәм бер-берегезгә һөҗүм иттерә торган ачуны**

**булдырырга тели вә Коръән вәгазеннән, намаз укудан сезне тыярга тели, шулай булгач, ул шәйтан эше булган – нәҗесләрдән тыеласызмы? Әллә тыелмыйсызмы? Әлбәттә тыелыгыз!»**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:90-91

Хәмер сүзенең мәгънәсе – исерткеч һәм каплау. Кием тәнне каплаган кебек хәмер кешенең акылын томалый. Димәк, «хәмер» сүзе исерткеч эчемлекләрнең һәр төрен – аракы, сыра, һ.б., шулай ук тәмәке, наркотикларны үз эченә ала.

Пәйгамбәребез саллалаһу гәләйһи вә сәлләм әйткән: «Исертә торган һәрнәрсә – хәмер. Исертә торган һәрнәрсә – харам!»[1]

«Күп микъдары исерткән нәрсәнең аз микъдары да харам»[2].

«Аллаһы нәрсәнедер тыйса, шуны сатудан килгән акчаны да харам кыла»[3].

Димәк, аракы сатып акча эшләгән кеше харам акча хуҗасы була. Ул Аллаһы Тәгаләнең ләгънәте астында йөри. Кызганыч, ләкин әлеге авыру халкыбыз арасында киң таралган һәм юл фаҗигаларының, гаиләләр таркалуның, урлашу, зина, кеше үтерү кебек зур гөнаһларның төп сәбәбе булып тора.

Имам Ән-Нәсаи бер риваять тапшыра: «Хәмердән ерак торыгыз, ул бөтен әшәке нәрсәләрнең башы! Сездән алда яшәгән кешеләр арасында тырышып гыйбадәт кылган бер ир булган. Аны бер азгын хатын гөнаһка этәрергә уйлаган да, ярдәмче хатыны аша үзенең янына нәрсәгәдер шаһитлык кылырга чакырып алган. Теге ир кеше килгәч, ярдәмче ишекләрне ябып матур хуҗабикәсе, сабый бала һәм хәмер торган бүлмәгә алып барган. Матур азгын хатын иргә: «Сайла: йә минем белән якынлык кыласың, йә шушы хәмерне эчәсең, йә шушы сабый баланы үтерәсең!» –

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әхмәд бине Хәнбәл, имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имам Әхмәд бине Хәнбәл, имам Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

дигән. Теге ир-ат: «Миңа хәмерне эчер», – дигән. Хатын аңа эчергән, теге ир тагын сораган. Ахыр чиктә, ир исергәч хатын белән зина кылган, баланы үтереп чыгып качкан. Хәмердән ерак булыгыз! Аллаһы белән ант итәм – иман белән эчкечелек очрашса, аларның берсе икенчесен һичшиксез этеп чыгарыр».

Ничек итеп әлеге авыруны җиңәргә соң? Бу бәладән котылу юллары динебездә бар. Һәрбер мөселман үз гаиләсендә, эшендә тән сәламәтлеген генә түгел, ә иң мөһиме рухи сәламәтлекне дә кайгыртырга тиеш! Иманыбыз һәм аңа бәйле әйберләр (намаз, ураза кебек) сәламәт булса, икенчесенә ирешү күпкә җиңелрәк.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ عَلَيْهَا مَلَائِكَةٌ غِلَاظٌ شِدَادٌ لَّا يَعْصُونَ اللَّهَ مَا أَمَرَهُمْ وَيَفْعَلُونَ مَا يُؤْمَرُونَ ﴿٦﴾

**«Әй иман китерүчеләр, үзегезне һәм гаиләләрегезне җәһәннәм утыннан саклагыз!»**

«Тәхрим / Тыю», 66:6

Аятьне аңлатып, Ибне Габбас әйтте: «Аллаһыга итагать итеп гамәл кылыгыз, гөнаһ кылудан сакланыгыз – тәкъва булыгыз, гаилә әһелләрен Раббыгызны зикер кылырга өндәгез – шулай булса, Аллаһы сезне уттан коткарыр!»

Дәххәк һәм Мукатил исемле галимнәр әйтте: «Гаиләсенә дини гыйлемне җиткерү, Аллаһы фарыз кылган һәм харам кылган әйберләрне аңлату – мөселманның бурычы булып тора».

Сәламәт гаиләнең төп даруы – намаз! Аллаһы Раббыбыз әйтә:

إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ ۗ وَلَذِكْرُ اللَّهِ أَكْبَرُ ۗ وَاللَّهُ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ﴿٤٥﴾

**«Тәхкыйк, намаз фәхештән вә ярамас эшләрдән тыяр».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:45

Шул сәбәпле, кечкенәдән балаларны намазга өйрәтү безнең бурычыбыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә балаларны җиде яшьтән намазга бастырырга өндәгән, әгәр дә ун яшьтә намазны кылмасалар – кисәткән.

Һәрбер мөселман ир-ат үз хатынына, балаларына карата игътибарлы булырга тиеш. Балалар яки оныкларның кем белән аралашуына, кайда йөрүенә, дини вә дөньяви гыйлемне нинди дәрәҗәдә үзләштерүенә салкын карау ярамас. Гыйбадәтләр үтәлешендә, шикледән-гөнаһлыдан ерак булуда гаилә әһелләренең бер-берсенә ярдәмләшүе бик мөһим.

Мөхтәрәм җәмәгать! Гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге иминлек, сәламәтлеккә бергәләп тырышлык күрсәткәндә генә җиңеллек белән ирешеп була! Чөнки, Тирмизи, Әхмәт риваятендә Пәйгамбәребезнең түбәндәге сүзләре китерелә: «Шәйтан ялгыз кеше белән була, ә кешеләр икәү булганда ул алардан ераграк тора».

*Рәмзил хәзрәт Садыйков,*

*Минзәлә районы имам-мөхтәсибе*

*27 декабрь вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Туганнар һәм күршеләрнең хаклары

Ислам дине кешене һәрьяктан кайгырткан дин. Ул кешене Раббысы, үз-үзе һәм башка кешеләр белән үзеңне дөрес тотарга өйрәтте. Безне чолгап алган кешеләрнең кем булуына карамастан, аларның безнең алда нинди дә булса хаклары бар. Без аларның шушы хакларын тиешенчә үтәмәсәк, Аллаһы Тәгалә алдында җавап тотарбыз.

Мөхтәрәм җәмәгать, безнең өстебездә аеруча хаклары булган ике төркем кешеләр: туганнарыбыз һәм күршеләребез бар.

Ата-анадан кала безгә якын кешеләр – кан кардәшләребез, туганнарыбыз. Без аларны Аллаһы ризалыгы өчен яратырга тиешбез. Туганнар белән араны өзү Исламда зур гөнаһ санала.

Коръәннең күпсанлы аятьләре Исламда туганлык мөнәсәбәтләренең иң югары урында булуына басым ясый, кешеләрне туганлык җепләрен тиешенчә сакларга өнди һәм аларның хокукларын бозуны шелтәли. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُم مِّن نَّفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالْأَرْحَامَ ۚ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا ﴿١﴾

**«Аллаһы Тәгаләдән куркыгыз, сез бит бер-берегездән Аның исеме белән сорыйсыз, туганлык мөнәсәбәтләре өзелүдән куркыгыз».**

«Нисә / Хатыннар», 4:1

Икенче аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

فَهَلْ عَسَيْتُمْ إِن تَوَلَّيْتُمْ أَن تُفْسِدُوا فِي الْأَرْضِ وَتُقَطِّعُوا أَرْحَامَكُمْ ﴿٢٢﴾
أُولَٰئِكَ الَّذِينَ لَعَنَهُمُ اللَّهُ فَأَصَمَّهُمْ وَأَعْمَىٰ أَبْصَارَهُمْ ﴿٢٣﴾

**«Әгәр сез иманнан кире кайтсагыз, җирдә бозыклык таратырсыз һәм туганлык бәйләнешләрен өзәрсез. Болар – Аллаһы ләгънәтләгән кешеләр. Ул аларны саңгырау итте һәм күзләрен сукырайтты».**

«Кыйтал / Мөхәммәд», 47: 22-23

Туганлык эше – бөек эш, шуңа да Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның хакында бик күп хәдисләр әйтеп калдырды. Бер хәдистә шулай дип боерды: «Кем Аллаһыга һәм Кыямәт көненә ышана, шул туганлык хакын үтәсен»[1].

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кем ризыгының киңәюен, гомеренең озын булуын теләсә – туганлык җепләрен сакласын»[2]. Шулай итеп, туганнар белән аралашу кешенең байлыгын арттыра, гомерен озынайта һәм тормышын бәхетле итә.

Бер яктан, туганлык хакын үтәү изге гамәл икән, икенче яктан аны кайгыртмау – зур гөнаһларның берсе. Туганнары белән аралашырга теләмәгән кеше хакында берничә хәдискә тукталып китик. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Җәннәткә туганлык җепләрен өзүче кермәс»[3] .

1 Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Икенче бер хәдистә:

«Өч кеше җәннәткә кермәячәк: хәмергә салышкан, туганлык җепләрен өзгән һәм сихерчегә ышанган», – дип әйтелгән[1].

Шулай ук тагын бер хәдистә болай дип әйтелә: «Адәм баласының эшләре һәр атна кич – җомга алдындагы кич көнне Аллаһыга күрсәтелә. Туганлык җепләрен өзгән кешенең гамәлләре кабул булмый»[2].

Шуны да әйтергә кирәк: туганлык хакын үтәр өчен туганнарыңнан күргән явызлыкларны гафу итеп, аларга изгелек белән кайтару мөһим. Халкыбызның мәкален кулланып, «таш белән атканга аш белән атарга», кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

«Туганлык мөнәсәбәтләрен кадерләп саклаучы түгел, ә үзенә карата туганлык мөнәсәбәтләрен өзгән туганнары белән һаман да туганнарча яшәргә омтылучы кеше хакыйкый туганлык җепләрен саклаучы була»[3]. Шуңа күрә чын мөселман – аның белән араларын өзеп, аңа карата рәхимсез һәм начар мөнәсәбәттә булсалар да, туганлык җепләрен сакларга тырыша!

Мөхтәрәм җәмәгать, өстебездә аеруча хаклары булган икенче төркем – ул безнең күршеләр. Бу дөньяда кеше ялгыз яшәми, ә кемгәдер күрше була. Күршесе кем булуына карамастан, мөселман кешесе аның белән яхшы мөгамәләдә булырга тиеш, чөнки бу җәгыятьнең имин, нык һәм тыныч булуы шарты. Коръәндә һәм хәдисләрдә күршелек хакында бик еш әйтелә.

Мәсәлән:

وَاعْبُدُوا اللَّـهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ
وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ وَابْنِ

[1] Имам Әхмәд бине Хәнбәл хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Әхмәд бине Хәнбәл хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَن كَانَ مُخْتَالًا فَخُورًا ﴿٣٦﴾

**«Аллаһыга ихлас гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиндәш кылмагыз, аннары ата-анага изгелек итегез һәм якын туганнарга, ятимнәргә, мескеннәргә, кардәш булган күршеләргә һәм кардәш булмаган күршеләргә, яныңдагы дустыңа, юлчыга һәм хезмәтче колларыгызга изгелек итегез. Хакыйкатьтә, тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһы, әлбәттә, сөйми!»**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Күргәнебезчә, бу аятьтә иң бөек нәрсә булган тәүхид – кешеләргә карата булган изгелек белән бергә искә алына һәм шул кешеләр арасында күрше дә бар.

Бер хәдисендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дусты Җәбраил фәрештә турында болай дигән:

«Миңа Җәбраил күрше хакында шулкадәр күп киңәшләр бирде, хәтта мин күршегә мирас хакы да билгеләнер дип уйладым»[1].

Ягъни, күршегә шул кадәр яхшы мөгамәләдә булырга кирәк ки, ул үзен синең якын туганың кебек хис итәргә тиеш. Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарга:

«Кем Аллаһыга һәм Кыямәт көненә ышана, шул күршесен хөрмәт итсен», – дигән[2].

Кызганычка, хәзерге көндә күп мөселманнар күрше хакын аңлап бетерми һәм иң якын күршеләре белән дошманлашып яши. Бу дөнья ва-

1 Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

кытлыча гына, җәмәгать. Йорт мәшәкатьләренә кагылышлы мәсьәләләр: тавыклар, казлар, бал кортлары, савыт-саба, ярты метр җир аркасында күршегез белән арагызны бозмагыз. Күршегез сезгә карата хакын тулысынча үтәмәсә дә, сез аның явызлыгына изгелек белән кайтарыгыз. Күршегә карата булган мөгамәлә беренче чиратта аңа түгел, сезнең үзегезгә кирәк. Моның турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Күршеләрнең Аллаһы алдында иң яхшысы – үз күршесенә карата иң яхшы булганы»[1], – дип өйрәтте.

Күрше хакын кайгыртмаган кеше зур гөнаһ кыла һәм үзен Аллаһы Тәгаләнең җәзасына дучар итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә көндез уразалар тотып, төннәрен нәфел намазлары укыган, ләкин күршеләрен теле белән рәнҗеткән хатын турында әйткәч, ул аның хакында:

«Ул утка эләгәчәк!»[2] – дигән, Аллаһы сакласын!

Беркөн Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы белән ант итәм, иманга килмәс» – дип, өч тапкыр кабатлаган. Моны ишеткәч, сәхабәләр аптырап: «Кем, әй Аллаһының Илчесе?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Явызлыгыннан күршесе имин булмаган кеше» – дип җавап кайтарган[3].

Хак мөселман үзенең туганнарына яисә мөселман күршесенә генә яхшылык эшләп калмый, ә мөселман булмаган күршесен дә кире какмый. Габдулла бине Гамернең яһүди күршесе булган. Габдулланың гаиләсе сарык суйган вакытта, ул: «Безнең яһүди күршегә дә ит бирдегезме?» – дип сорый торган булган.

---

1 Имам Тирмизи һәм имам Әхмәд бине Хәнбәл хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Бохари һәм имам Әхмәд бине Хәнбәл хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Аллаһы Тәгалә безгә динебезне яхшы өйрәнеп, туганнарыбызга һәм күршеләребезгә чын мөселман буларак яхшы мөгамәләдә яшәргә насыйп итсен!

*Хәлим хәзрәт Шәмсетдинов,*

*Алабуга имам-мөхтәсибе*

*3 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Исраф – харам гамәл

Барчаларыбызны да юктан бар кылып, безне билгеле бер вакытка кадәр шушы сынау дөньясына урнаштырган, тирә-ягыбызда булган һәрнәрсәне безгә хезмәткә тапшырган, безгә күрү өчен күз, ишетү өчен колак, уйлау, фикерләү өчен аң-белем биргән, безгә нигъмәтләрнең иң хәерлесен – иман, ислам, Коръән, намаз, гыйбадәт нигъмәтләре насыйп иткән, барча мәхлүкъларын Кыямәт көнендә Үз каршына китереп бастыручы, һәркайсына хисап кылып гадел хөкем итүче, кемнедер җәннәтле, ә кемнедер җәһәннәмле итүче, бердәнбер гыйбадәткә лаек булган Зат – Аллаһыга мең-мең шөкерләребез, мактау-олуглауларыбыз булсын.

Безгә шушы хак динебезне өйрәткән, җәннәт юлы белән сөендергән, җәһәннәм юлы белән кисәткән, үзенең кылган һәрбер эше: әдәп-әхлагы, үзенең тормыш рәвеше белән һәркемгә үрнәк булган, безнең өчен газиз әткәй-әнкәйләребездән, әби-бабайларыбыздан, кадерле бала-онykларыбыздан һәм үз-үзебездән дә якын булган сөекле пәйгамбәребезгә – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, Кыямәт көнендә, ин шә Аллаһ, шәфәгатьчебезгә күңел түрләребездән чыккан хәер-догаларыбыз, Аллаһының сәламе һәм салаваты булсын!

Газиз кардәшләрем! Иң беренче чиратта үземне, аннан соң сезне тәкъвалыкка чакырам. Аллаһының әмерләрен үтәгез, тыйганнарыннан ерак торыгыз! Һәм белегез: адәм баласының бу дөньядагы бәхете дә һәм Кыямәттә Аллаһының рәхмәте белән җәннәткә кертүе дә – аның бу дөньяда булганда тәкъвалыгына бәйле. Аллаһының әмерләрен ничек үтәде?! Аллаһының харамнарыннан ничек тыелды?! адәм баласының

дөньядагы һәм Ахирәттәге иминлеге шулардан тора. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә әйтте:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلَا تَمُوتُنَّ إِلَّا وَأَنتُم مُّسْلِمُونَ ﴿١٠٢﴾

**«Әй иман китергән бәндәләр, Аллаһы Тәгаләгә тиешле дәрәҗәдә тәкъва булыгыз! Һәм мөселманлыгыгызны төзәтмәгән хәлдә Аллаһы каршына кайтудан сак булыгыз!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:102

Мин тәкъва, дип уйлап кына, тәкъва булып булмый. Аллаһының әмерен җиренә җиткереп үтә, харамнарыннан тыелып яшә.

Аллаһы Тәгалә дөньядагы бөтен нәрсәләрне катгый бер үлчәү белән яраткан, биредә бернәрсәнең дә артыгы яки киме юк. Ислам шәригате дә кешеләргә үзләре өчен яратылган нәрсәләреннән акыл һәм чама белән файдалану юлларын күрсәтеп биргән. Ул күрсәтмәләрне үтәп яшәсәк – һидаятьне тапкан булабыз. Киресен эшлибез икән, ул вакытта исраф дип атала торган халәткә дучар булабыз.

Нәрсә соң ул исраф? Исраф ул – Аллаһы Тәгалә тарафыннан безгә бирелгән нигъмәтләрне файдасыз эшкә сарыф кылу, әрәм итү дигән сүз. Аллаһы Тәгалә исраф кылучыны сөймәс. Исраф дигәндә, саранлык дигән сыйфатны да искә алып була. Исраф та, саранлык та Ислам динендә харам санала. Аларның урталыгы икътисад дип атала, ягъни үзеңә бирелгән нигъмәтләрне дөрес һәм акыллы рәвештә файдалану.

Ислам дине бөтен эштә урталыкны, чама белүне хуплый. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَالَّذِينَ إِذَا أَنفَقُوا لَمْ يُسْرِفُوا وَلَمْ يَقْتُرُوا وَكَانَ بَيْنَ ذَٰلِكَ قَوَامًا ﴿٦٧﴾

**«Вә алар мохтаҗга мал бирсәләр, исраф итмәсләр вә тарлык та кылмаслар, исраф белән тарлык арасында гадел торырлар».**

«Фуркан / Аеручы», 25:67

Димәк, мөселман малын исраф та кылмас, саран да булмас. Исраф нинди гамәлләрдә чагылыш таба соң? Мәсәлән, кием өстенә кием алу, әҗәткә кереп купшы туйлар, юбилейлар уздыру, чамасыз зур йортлар салу, вакытында уңышны җыймау, терлекне ашатмау, киемне саклап тотмау, тукланганнан соң да ашау, тәһарәт-госел алганда суны артык куллану һ.б. исраф була. Без еш кына кием-салымыбыз күп булса да, кияргә кием юк, дибез. Кеше ниндидер шаукымга бирелеп, һич кирәкмәгән әйбер алып куярга һәм ул әйбер еллар буе файдаланмыйча ятарга мөмкин.

Иң кадерле нәрсә булган – икмәкне сарыф итүне генә алыйк. Россиядә халык санын алу буенча килгән соңгы мәгълүматларга караганда, 146 370 979 кеше яши. Әгәр һәр кеше көнгә 1 грамм икмәкне әрәм итсә дә, елга 53 425 тонна икмәк исраф була дигән сүз. Күзаллау өчен, бу алтмышар тонна икмәк төягән, шуның кадәр үк вагон таккан унбиш состав булып чыга. Моңа икмәкне үстерү, пешерү, сату, кулланылган техника, хезмәт хакы чыгымнарын да өстәсәң – шактый күп саннар килеп чыга. Бу уңайдан динебезнең бөеклеген, хикмәтен күрәбез. Ислам безне икмәкнең валчыгын да исраф кылмаска өйрәтә. Кызганычка, икмәк сарыфы кеше башына бер грамм гына түгел, ипине тулысы белән чүплек савытына салучылар да бар. Менә шушы хәлләрне кисәтеп Коръәндә болай диелә:

إِنَّ الْمُبَذِّرِينَ كَانُوا إِخْوَانَ الشَّيَاطِينِ ۖ وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِرَبِّهِ كَفُورًا ﴿٢٧﴾

**«Тиешсез урынга малны исраф итүчеләр, әлбәттә, шәйтан кардәшләредер, шәйтан Раббысына кяфер булды».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:27

Исраф турында сөйләгәндә вакыт, сәламәтлек тә кадерле төшенчәләр икәнен онытмасак иде.

Исраф – мал, ризык, суга гына түгел, вакыт һәм сәламәтлеккә дә кагыла. Болар – кабат кайтарып алып булмый торган нигъмәтләр. Гәбделҗаббар Кандалый да: «Якутлар табыладыр вакыт белән, вакытлар табылмыйлар якут белән», – дип язган. Уйланырга сәбәп бар: гомерләребез заяга узмыймы? Кеше гомеренең кыйммәте, яшәгән еллары саны белән түгел, эшгамәле белән үлчәнә. Егерме сигез яшендә бакыйлыкка күчкән Тукаебыз мирасын алыйк. Юкса, илле-җитмеш ел гомер яшәп тә, гомерләрен заяга, мәгънәсезгә уздырган кешеләр дә бар. Шуңа күрә һәрберебез үзалдына: үзебезне, балаларыбызны, оныкларыбызны, өммәтебез, милләтебез үсешенә багышлыйбызмы, дип уйланырга тиеш. Һәр кеше шәхес буларак яхшы якка үзгәрергә омтылса, җәмгыять тә күпкә камилләшер иде. Безгә бирелгән гомер үтә дә чикле, аны ваемсыз, файдасыз үткәрү акыллылык күрсәткече түгел. Аллаһы Тәгалә искиткеч гадел – тәүлек озынлыгы һәрберебез өчен төп-төгәл 24 сәгать. Соңгы вакытта финанс, бизнес өлкәсендә тайм-менеджмент дигән төшенчә киң кулланылышта. Тайм-менеджмент – вакыт белән идарә итү фәне дигән сүз. Тик вакыт белән адәм баласы идарә итә алмый, ә менә үзенә бирелгән вакытны нәтиҗәле куллана ала. Әлеге фән нәкъ менә шуның юлларын, тәртибен аңлата.

Күз алдына китерик: бер банк һәркөн сезнең исемгә 86400 сумга исәп-хисап счеты ача, ди. Көне буе сез бу сумманы теләгәнчә куллана аласыз, ә көн тәмамланганда бу хисап счеты ябыла. Икенче көнне шул ук суммага счет яңадан ачыла. Әлбәттә, адәм баласы бу сумманы тиененә хәтле тотып бетерергә тырышыр иде. Ә бит мондый счет һәркөн, һәрберебезгә ачык. 86400 сум – ул бер тәүлек эчендәге 86400 секунд. Шушы бирелгән мөмкинлектән файдаланып калабыз икән, без уңышка ирешәбез, юк икән, вакыт банкындагы счетыбыз яначак – без банкротка чыгабыз.

Коръәннең «Гасыр» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә **«Заман белән ант итәм»**, – ди. Ә ул, белгәнебезчә, иң бөек, иң мөһим нәрсәләр белән генә ант итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Ике нигъмәт бар, әмма кешеләрнең күбесе аларның кыйммәтен аңламыйча кала. Беренчесе – саулык, икенчесе – вакыт», – диде.

Шулай итеп, вакытны юкка уздырган кеше аны исраф итеп, гөнаһ эшләгән булып чыга.

يَا بَنِي آدَمَ خُذُوا زِينَتَكُمْ عِندَ كُلِّ مَسْجِدٍ وَكُلُوا وَاشْرَبُوا وَلَا تُسْرِفُوا ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ ﴿٣١﴾

**«Әй, адәм балалары! Ашагыз, эчегез, ләкин исраф итмәгез, чөнки Аллаһы исраф кылучыны сөймәс».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:31

Җир-суларыбызны саклыйк!

Тагын бер зур, хәтәр исраф турында әйтми китә алмыйм. Аллаһы Тәгалә кешегә Җирне, андагы бар нәрсәне аңа файдалану өчен әманәт итеп биргән. Әмма адәми зат сәнәгать-җитештерү, эшкәртү өлкәсендә шул дәрәҗәгә җитте ки, һавага, суга, җиргә чыгарган көнкүреш һәм промышленность калдыклары бүген аның үзенең үк яшәешен куркыныч астына куя башлады. Кызганычка, кеше әманәтне сакларга кирәклеген онытты. Ул бүген Җиргә карата исраф кыла. Әмма аңа Җир йөзендәге барча җан иясен, үсемлекләрне кырып бетерүгә рөхсәт бирелмәде! Аллаһы Тәгаләнең безгә яшәү өчен бушлай биргән нигъмәтләреннән кирәгенчә генә, чама белеп файдалану тиеш иде. Табигать байлыкларын уйсыз, гамьсез исраф итүнең масштаблары кот очарлык. «Кызыл китап»ны мин җиребезгә карата кылына торган җинаятьләрне гаепләү акты, кире кагып булмый торган дәлиле дип саныйм. Әле анда пычранган сулыклар исемлеге кермәгән. Алары өчен аерым китап ачарга мөмкин. Коръән әйтүенчә,

Ахирәт көнендә Җир, кешенең үзенә китергән авырлыклары турында сөйлиячәк.

Сүземне галим Ибраһим Әдһәмнең бик гыйбрәтле сүзләрен китереп тәмамлыйм.

– Базарда әйбер кыйммәтләнсә, минем файдага, – дип әйтә ул.

– Ул ничек алай була? – дип сорыйлар аннан.

– Товар кыйммәтләнгәндә мин аңа күпмедер вакыт игътибар итмим. Шулай итеп, ул әйбергә аның очсыз вакытындагы бәһане дә түләмәгән булып чыгам, ягъни мин отышта калам, – дип җавап кайтара ул.

«Әй Раббыбыз, безнең гөнаһларыбызны ярлыка һәм эшебездә исраф кылуыбызны һәм чиктән чыгуыбызны кичер! Ий Раббыбыз, барчабызга да Син биргән җир-суларыбыз, вакытыбыз, сәламәтлегебезнең, безгә биргән нигъмәтләреңнең кадерен, чамасын белеп кулланырга, шулар ярдәмендә файдалы, изге гамәлләр кылып, иманлы-исламлы булып яшәргә насыйп итсәң иде.

*Алмаз-Габделкәрим хәзрәт Гыйззәтуллин,*

*Әгерҗе имам-мөхтәсибе*

# Фәтвалар

# Без мәрхүм туганнарыбызга ничек ярдәм итә алабыз?

**Сорау: Минем бабам гүр иясе булды. Мин аңа хәзер ничек ярдәм итә алам? Садака, Коръән һәм намаз уку, ураза тоту кебек изге гамәлләремне бүләк итеп аның исеменә ирештерә аламмы?**

**Җавап:** Хәнәфи мәзһәбе галимнәре кешегә мондый хокук бирелгәнлеге турында ачыктан-ачык бәян итте. Кайсы гына гамәлне алсак та: намаз, ураза, хаҗ, садака, салават, тәсбих һәм шуңа охшаш изгелекләр – без аларны башка берәүгә багышлый алабыз. «Раддел-Мөхтәр» (1 том, 666 нчы бит) китабында болай дип язылган:

صَرَّحَ عُلَمَاؤُنَا فِي بَابِ الْحَجِّ عَنِ الْغَيْرِ بِأَنَّ لِلْإِنْسَانِ أَنْ يَجْعَلَ ثَوَابَ عَمَلِهِ لِغَيْرِهِ صَلوةً أَوْ صَوْمًا أَوْ صَدَقَةً أَوْ غَيْرَهاَ، كَذَا فِي «الْهِدَايَةِ». بَلْ فِي زَكَوةِ «التَّتَارْخَانِيَّةِ» عَنِ «الْمُحِيطِ»: الْأَفْضَلُ لِمَنْ يَتَصَدَّقُ نَفْلًا أَنْ يَنْوِيَ لِجَمِيعِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ لِأَنَّهَا تَصِلُ إِلَيْهِمْ وَ لَا يَنْقُصُ مِنْ أَجْرِهِ شَيْءٌ اه. هُوَ مَذْهَبُ أَهْلِ السُّنَّةِ وَ الْجَمَاعَةِ، لَكِنْ اسْتَثْنَي مَالِكٌ وَ الشَّافِعِيُّ الْعِبَادَاتِ الْبَدَنِيَّةَ الْمَحْضَةَ كَالصَّلَوةِ وَالتِّلَاوَةِ فَلَا يَصِلُ ثَوَابُهَا إِلَي الْمَيِّتِ عِنْدَهُمَا، بِخِلَافِ غَيْرِهَا كَالصَّدَقَةِ وَالْحَجِّ . وَخَالَفَ الْمُعْتَزِلَةُ فِي الْكُلِّ، وَتَمَامُهُ فِي فَتْحِ الْقَدِيرِ الخ... (رد المحتار: ١\٦٦٦)

«Хәнәфи мәзһәбе галимнәре дөрес әйткәннәр: кылган хаҗ гамәлеңнең әҗерен башка кешегә бүләк итәргә ярый. Ул намаз, ураза, садака яки башка берәр гамәл булса да шул рәвешле эш кылырга мөмкин. Моның хакында «Әл-Һидәя» китабында да искә алына. Әмма

«Әт-Татархания» китабының «Зәкят» бүлегендә болай диелгән: «Нәфел-садакасын бирүче моны барлык мөселман ирләре һәм хатын-кызлары исеменнән башкарырга тиеш. Садаканың савабы ияләренә барып җитә һәм аның әҗере бер дә кимеми».

Бу әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгатьнең фикере, әмма имам Мәлик һәм имам Шәфигый моннан намаз һәм Коръән укуны аерып алды. Алар, садака һәм хаҗ гамәлләреннән аермалы буларак, намаз һәм Коръән укуның әҗере мәрхүмнәргә бармый, дип әйтә.

Шулай ук «Раддел-Мөхтәр» (2 том, 27 нче бит) китабында мондый фикер дә китерелә:

وَرَوَي الدَّارَقُطْنِيُّ: « أَنَّ رَجُلًا سَأَلَهُ عَلَيْهِ الصَّلَاةُ وَالسَّلَامُ فَقَالَ: كَانَ لِي أَبَوَانِ أَبَرُّهُمَا حَالَ حَيَاتِهِمَا، فَكَيْفَ لِي بِبِرِّهِمَا بَعْدَ مَوْتِهِمَا؟ فَقَالَ: إِنَّ مِنَ الْبِرِّ بَعْدَ الْمَوْتِ أَنْ تُصَلِّيَ لَهُمَا مَعَ صَلَاتِكَ وَأَنْ تَصُومَ لَهُمَا مَعَ صَوْمِكَ «. وَرُوِيَ أَيْضًا عَنْ عَلِيٍّ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ قَالَ: مَنْ مَرَّ عَلَي الْمَقَابِرِ وَقَرَأَ « قُلْ هُوَ اللهُ أَحَدٌ « اِحْدَي عَشَرَةَ مَرَّةً ثُمَّ وَهَبَ أَجْرَهَا لِلْأَمْوَاتِ أُعْطِيَ مِنَ الْأَجْرِ بِعَدَدِ الْأَمْوَاتِ. وَعَنْ أَنَسٍ قَالَ: يَا رَسُولَ اللهِ، إِنَّا نَتَصَدَّقُ عَنْ مَوْتَانَا وَنَحُجُّ عَنْهُمْ وَنَدْعُو لَهُمْ فَهَلْ يَصِلُ ذَلِكَ لَهُمْ؟ قَالَ: نَعَمْ، إِنَّهُ لَيَصِلُ إِلَيْهِمْ، وَإِنَّهُمْ لَيَفْرَحُونَ بِهِ كَمَا يَفْرَحُ أَحَدُكُمْ بِالطَّبَقِ إِذَا أُهْدِيَ لَهُ». (رواه أبو حفص العبكري). (رد المحتار: باب الحج عن الغير: ٢/٢٧.

«Әд-Дәракутни бер ир-атның Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә мондый сорау биргәнен хәбәр итә: «Минем әти-әнием бар иде һәм мин исән вакытларында аларга яхшы мөнәсәбәттә булдым. Алар

гүр ияләре булганнан соң мин аларга ничек ярдәм итә алам?» – дип сораган. Моңа җавап итеп Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үзеңнең намазың белән берлектә алар өчен намаз укы һәм үзеңнең уразаңны тоткан вакытта алар өчен дә ураза тот. Дөреслектә, болар хәзер син алар өчен эшли алган хәерле гамәл булып тора», – дип әйтә».

Гали радыяллаһу ганһенең түбәндәге сүзләре билгеле: «Әгәр кем дә булса мөселман зираты янынан үткәндә ун тапкыр «Ихлас» сүрәсен укып, аны мәрхүмнәргә багышласа, үзенә дә шул зираттагы гүр ияләре саны кадәр савап ирешәчәк».

Әнәс радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Йә, Расүлуллаһ без мәрхүмнәребез исеменнән садака бирәбез, хаҗ кылабыз, алар өчен дога кылабыз. Бу гамәлләребез аларга барып ирешәчәкме?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әйе, болар барысы да аларга барып ирешә һәм сез үзегезгә бирелгән бер тәлинкә күчтәнәчкә куанган кебек, мәрхүмнәр дә алар өчен кылган бу гамәлләрегез өчен бик шатланачак»[1], – дип җавап кайтарган.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*ТР мөфтие*

[1] Хәдисне хәбәр итүче: Әбү Хәфес Әл-Әкбари.

# Миннән әманәт итеп тапшырылган акчаларны урладылар. Мин әҗәтле кеше булып саналаммы?

**Сорау: Минем 80 яшьлек кайнанам үлемтеккә дип җыйган акчаларын югалтудан куркып, безгә сакларга тапшырды. Әмма без эштә вакытта фатирыбызның ишекләрен ватып кереп, йортыбыздагы кайбер мал-мөлкәтне һәм шул исәптән әнинең җыйган акчаларын урлап чыгып киттеләр. Тиз арада моның кадәр акчаны җыеп, иясенә тапшыру безнең көчебездән килмәячәк, чөнки безнең гаилә өчен әлеге акча күләме аз түгел. Мин хәзер әҗәтле кеше булып саналаммы икән, дип борчылам.**

**Җавап:** Шәригать буенча кешегә нәрсә дә булса әманәт итеп тапшырылса, ул аны сакларга һәм вакыты җиткәч иясенә тапшырырга бурычлы. «Мөхтәсар әл-Кудури» китабының «Әл-Вәдига» (әманәт итеп тапшырылган мал-мөлкәт) бүлегендә болай дип язылган:

الْوَدِيعَةُ أَمَانَةٌ فِي يَدِ الْمُودَعِ، إِذَا هَلَكَتْ فِي يَدِهِ لَمْ يَضْمَنْهَا. (مختصر القدوري: كتاب الوديعة)

Ягъни, «Әл-Вәдига» – ул берәр кешегә саклар өчен әманәт итеп тапшырылган әйбер. Әгәр тапшырылган мал-мөлкәт югалса, әманәтне кабул итеп алган кеше зыянны капларга тиеш түгел».

Сезнең очракта сез әҗәтле кеше булып саналмыйсыз, чөнки бу хәлләрдә сезнең гаебегез юк. Шәригать буенча, әманәтне үз хисабыгызга кайтарып бирергә тиеш түгелсез.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*ТР мөфтие*

# Берәр эш белән шөгыльләнгән вакытта Коръән уку рөхсәт ителәме? Бу Коръәнгә хөрмәт күрсәтмәү булмыймы?

**Сорау: Берәр эш белән мәшгуль булган вакытта Коръән укырга ярыймы? Әгәр кешенең тәһарәте булмаса, ул изге Китапның битләренә кагылмыйча гына анда язылганнарны укый аламы?**

**Җавап:** Әгәр эш кешегә Коръәнне ихлас йөрәктән укырга комачау итми икән, бу рөхсәт ителгән күренеш. Шулай ук тәһарәтсез хәлдә дә изге Китапның битләрен карандаш белән ачып барып укырга мөмкин.

«Әл-Фәтава Әл-Һиндия» китабында болай диелгән:

يَجُوزُ لِلْمُحْتَرِفِ كَالْحَائِكِ وَالْإِسْكَافِ قِرَاءَةُ الْقُرْآنِ إِذَا لَمْ يَشْغَلْ عَمَلُهُ قَلْبَهُ عَنْهَا وَإِلَّا فَلَا، وَلَوْ كَانَ الْقَارِئُ وَاحِدًا فِي الْمَكْتَبِ يَجِبُ عَلَى الْمَارِّينَ الِاسْتِمَاعُ، وَإِنْ كَانَ أَكْثَرَ وَيَقَعُ الْخَلَلُ فِي الِاسْتِمَاعِ لَا يَجِبُ عَلَيْهِمْ. صَبِيٌّ يَقْرَأُ فِي الْبَيْتِ وَأَهْلُهُ مَشْغُولُونَ بِالْعَمَلِ يُعْذَرُونَ فِي تَرْكِ الِاسْتِمَاعِ إِنْ افْتَتَحُوا الْعَمَلَ قَبْلَ الْقِرَاءَةِ وَإِلَّا فَلَا.

Кәсеп итүче остага, мәсәлән тукучыга, итекчегә эш вакытында Коръән укырга ярый, әмма аның шөгыле ихласлык белән укуына комачау итмәскә тиеш. Әгәр мәктәптә (яки башка урыннарда) бер кеше тавыш белән Коръән укыса, янәшәдән үтүчеләр туктап тыңларга тиешле, әгәр дә укучылар күп һәм тавышлар арасында буталчыклык күзәтелсә, ягъни кеше бер генә тавышны тыңлый алмаса, бу очракта мәҗбүри түгел. Бала йортта Коръән укыганда аның гаиләсе өй эшләре белән мәшгуль булса, бу вакытта алар Коръәнне тыңламаган өчен гафу (мәгъзур) үтенәләр, әгәр

алар эшләренә Коръән укыла башлаганчы тотынган булсалар, бу вакытта гафу үтенмиләр.

الْمُحْدِثُ إِذَا كَانَ يَقْرَأُ الْقُرْآنَ بِتَقْلِيبِ الْأَوْرَاقِ بِقَلَمٍ أَوْ سِكِّينٍ لَا بَأْسَ بِهِ، كَذَا فِي الْغَرَائِبِ.

Мөһдис, ягъни тәһарәте булмаган кеше, Коръәнне карандаш яки пычак белән ачып барып укуы гаеп түгел. Моның хакында «Әл-Гараиб» китабында да әйтелә.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*ТР мөфтие*

# Үрнәк затлар

# Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә бине Җәгъфәр Әл-Кудагый

Данлыклы мөхәддис (хәдис галиме), казый, тарихчы, дипломат Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә бине Җәгъфар Әл-Кудагый һиҗри 380, милади 990 еллар тирәсендә Каһирәдә (Мисыр) туып, һиҗри 454, милади 1062 елда вафат була. Тумышы белән бәни Кудага кабиләсенә бәйле булганга, Кудагый дигән исем белән танылган. Үз заманында Багдад, Мосул, Димәшкъ, Искәндәрия, Хорасан, Шираз кебек шәһәр һәм өлкәләрдән килгән олы, мәшһүр галимнәр белән күрешә. Алар арасыннан: кыйраәт галиме Әбү Габдулла Әхмәт бине Әл-Җизи, мөхәддисләрдән Әбү Мөслим Мөхәммәд бине Әхмәт бине Гали, Әбү Хәсән Әхмәт бине Габделгазиз бине Сарсал һәм Әбү Мөхәммәд Габдрахаман бине Гомәр Әл-Туҗиби, танылган Факыйһ Ибне Нәххас, мотасавиф (тәсаввуф галиме) Әбү Хәсән Гали бине Габдулла бине Җәһдам Әл-Хәмадани һ.б. кебек танылган галимнәрдән гыйлем өйрәнә. Мәккә, Истамбул, Рамлә һәм Тараблүс әш-шамга барып, 130га якын галимнәрдән хәдис риваять итү рөхсәте (иҗәза) ала. Фикеһ буенча шәфигый мәзһәбендә, ягъни гамәлдә әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать галимнәре юлын тота. Игътикадта әшгарый мәзһәбендә. Аның үзеннән Хатип Әл-Багдади, Әбү Фәраҗ Сәһле бине Бишер Әл-Исфрайини, Ибне Макулә, Мөхәммәд бине Футух Әл-Хәмиди, Әбү Сәгыйд Габделҗәлил Әс-Сәви, Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Әхмәт Әр-Рази һәм хәзрәти Галинең оныкларыннан, «Нәсиб» исеме белән искә алынган Әбү Әл-Касыйм Гали бине Ибраһим Әл-Галәви Әл-Хөсәйни кебек галимнәр хәдисләрне риваять иткәннәр.

Кудагыйның иң күп хезмәт кылган чагы Фатимиләр хәлифәсе Мөстансыйр Билләһ заманына туры килә. Казый буларак киң катламга танылуы белән берлектә, Фатимиләр чорында вәзир сәркатиплеге, илчелек һәм казыйлык вазифаларында хезмәт кыла (Кинди 63 б.). Мөстансыйр

Билләһ һиҗри 447, милади 1055 елда аны Константинопольга (Истамбул) илче итеп җибәрә. Шунда шул ук вакытта сәлҗек солтаны Тугърул бәйнең илчесе белән бер арага килә. Солтан Тугърул бәйнең Бизанс (Византия) императрицасына җибәргән хатындагы соравы буенча, сәлҗек илчесенә Константинополь (Истамбул) мәчетендә җомга намазының хотбәсендә Габбасиләр хәлифәсе Каим Биәмрилләһ исемен кушып укырга рөхсәт ителә. Тарихтан билгеле булганча, бу ике Габбасиләр белән Фатимиләр хәлифәлекләре арасында каршылыклык, дошманлык сөргән чорга туры килә. Бу вакыйга турында Кудагый, илче буларак, үзенең җитәкчесе Фатимиләр хәлифәсе Мөстансыйрга хәбәр җиткерә. Бу хәбәрне ишеткәч, Мөстансыйр Билләһ Бәйтелмокдистәге (Иерусалим) Камәмә чиркәвендәге христианнар өчен кодси, изге булган әйберләрен үз кулына ала. Шул вакыйгадан соң Бизанс гаскәрләре Фатимиләрнең диңгез буендагы җирләрен яулап алып, Каһирә шәһәрен камап алалар. Һиҗри 454, милади 1062 елга кадәр дәвам иткән кытлык сәбәбендә, Мисырда ваба хастасы кизүе башлана (Макризи 1 т. 335 б.). Бик күп халык ачлык һәм ваба кизүенән үлә. Шулар арасында олы шәхес буларак өлгереп җитешкән Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә бине Җәгъфар Әл-Кудагый хәзрәтләре дә һиҗри 454, милади 1062 елның декабрь аеның 21 көнендә вафат була. Кабере Карафәдәге Нәҗҗар зиярәтында.

Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә бине Җәгъфар Әл-Кудагыйның әсәрләре:

«Шиһаб Әл-Әхбәр». Баш хәрефләре бер булган, кыска хәдисләрдән тупланган бу җыентык «Әш-Шиһаб фил Хикәм вәл-әдәп» исеме белән танылып, киң таралыш тапкан.

«Мөснәд Әш-Шиһаб». «Шиһаб Әл-Әхбәр»дәге хәдисләрнең иснәдләре белән бергә җыелган әсәре.

«Дөстүре мәгалим әл-хикәм вә мәгъшүре мәкарим әш-шиям». Хәзрәти Галинең үгет-нәсыйхәтләре, әдәби сүзләре, сорауларга җаваплары, догалары, аеруча шигырь һәм тәмсилләреннән тупланган әсәр.

«Әл-мохтар фи зикр әл-хитат вәл-әсәр». Бу әсәрдә Мисырның топографиясе булдырылган.

«Әл-инбәгъ би әнбәгъ әл-әнбия вә тәварих әл-хөләфә вә виләят әл-өмәра» («Әл-Инбәгъ ганил әнбия», «Әнбәгъ әл-әнбия», «Тарих Әл-Кудагый», «Гуюн әл-мәгариф вә фөнүне әхбәр әл-хәләиф»). Пәйгамбәрләр, хәлифәләр һәм бәйлекләр тарихы буларак өч бүлемнән торган әсәр дөнья яратылганнан алып, һиҗри 427, миладв 1036 елга кадәр булган вакытны үз эченә алып, Габбасиләр һәм Фатимиләр чорын күрсәткән бер мохтасар (кыскартылган) тарих китабы булып санала.

«Дакаикуль әхбәр вә хәдаикуль игътибар». Вәгазь, нәсыйхәт һәм зикер китабы булган әсәр төрки телләргә тәрҗемә ителеп, киң таралыш тапкан. Бу әсәр ун гасыр буенча бүгенге көнгә кадәр безнең төрки халыкларда иң популяр китаплардан санала.

Моннан тыш, «Тәфсир Әл-Коръән» (20 том), «Мәнакыйб әш-Шәфигый», «Мөгъҗәм әш-шуюх», «Әмәли фил хәдис», «Әл-Инбәһ фил хәдис», «Әл-Әгъдәд» (Әл-Гадәд) әсәрләре булганы билгеле.

# Билял радыяллаһу ганһе – Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең мөәзине

Кара тәнле, озын буйлы, ябык һәм куе чәчле әлеге кеше пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бик якын иде. Әбү Габдулла Билял бине Рабәх радыяллаһу ганһе 30 яшендә Исламга килә. Ул, үзләренең Исламда икәнлекләрен ачыктан-ачык бәян иткән һәм моның аркасында авыр газапларга тартылган җиде кешенең берсе була. Билял радыяллаһу ганһе үзен мактый башласалар, башын түбән иеп, мин кичә генә кол булган хәбәши кешесе, дип әйтә торган иде.

Тәкъвалыгы, саф күңеле һәм тыйнаклыгы аны шундый бөек дәрәҗәләргә җиткерде ки, хәтта бу югарылыкка аны дәрәҗәле нәселдән, бай даирәдән булу да күтәрә алмас иде. Кол булуы да, кара тәнле икәнлеге дә, тәкәбберләрнең аңа түбәнсетеп караулары да аны сайлаган юлыннан читкә тайпылдырмады.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әле бер генә пәйгамбәргә дә Аллаһы Тәгалә җиде якын дусны бирмәгән иде, миңа исә шундыйларны ундүртне җибәрде», – диде. Ул кешеләр арасында Билял радыяллаһу ганһе дә бар иде.

Икенче бер хәдистә килгәнчә, Расүлебез галәйһиссәлам Билял радыяллаһу ганһедән болай дип сорый: «Йә Билял, диндәге үзеңнең иң зур өметләр баглаган гамәлең турында әйт әле, чөнки мин бу төндә җәннәттә синең аяк тавышларыңны ишеттем». Билял радыяллаһу ганһе: «Мин тәүлекнең кайсы вакытында гына тәһарәт алсам да, артыннан Аллаһы риза булырлык санда намаз укыйм. Бу гамәлдән башка берсенә дә аннан да зуррак өметләр багламыйм», – дип җавап бирә. Билял радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең әлеге сүзләрен исенә төшерсә, һәрвакыт аның күзләреннән яшь ага иде.

## Билял радыяллаһу ганһенең ныклыгы һәм тыйнаклыгы

Исламны кабул иткән беренче кешеләрне мөшрикләр каты газапларга дучар кылды: өсләренә тимер көбә кием кидереп, кызу кояш астында калдыра иделәр. Алар арасында Билял радыяллаһу ганһе дә булды. Мөшрикләр барысыныннан да диярлек ишетергә теләгән сүзләрен ишетте, әмма Билял радыяллаһу ганһе генә үз сүзендә, ышануында нык торды. Ул тәненә китергән газаплауларның Аллаһы Тәгаләнең бөеклеге алдында бер бәһасе дә юклыгын таный иде. Хәтта мөшрикләрнең балалары да аны газаплый торган булды. Бу вакытта да Билял радыяллаһу ганһедән «Аллаһы бер, Аллаһы бер» дип кабатлаудан башка сүз чыкмады. Кояш кыздырган эссе көндә, Билялны аның хуҗасы Умәйә бине Хәләф урамга алып чыгып, эссе комга яткыра һәм өстенә зур таш куеп, син үлгәнче шулай ятачаксың яки Мөхәммәд диненнән баш кагып, потларга табына башлыйсың, дип әйтә торган иде. Ә Билял радыяллаһу ганһе һаман да «Аллаһы бер, Аллаһы бер» дип кабатлап торды.

Билял радыяллаһу ганһене берничек тә җиңә алмагач, мөшрикләр аңа: «Ичмасам, безнең потлар турында берничә күркәм сүз әйт һәм без сине тынычлыкта калдырырбыз», – диделәр. Әмма Билял радыяллаһу ганһе «Аллаһы бер» дигәннән башканы әйтмәде.

Әбү Нугайм үзенең «Әл-Хөлия» дигән китабында хәбәр итә: Вәрака бине Нәүфәл Билял радыяллаһу ганһе яныннан үтеп киткәндә, аны газаплауларын һәм Билял радыяллаһу ганһенең «Аллаһы бер» дип кабатлаганнарын ишетеп, Билял радыяллаһу ганһегә: «Бер, Билял, бер», – дип әйтте. Һәм Умәйәгә карап: «Аллаһы белән ант итәм, әгәр сез аны үтерәсез икән, мин аның каберен рәхмәт һәм бәрәкәт урыны итәчәкмен», – дип әйтте.

Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең булачак мөәзинен җәфалаган урын яныннан Әбү Бәкер

радыяллаһу ганһе үтеп барганда, Умәйәгә карап: «Син бу кылганнарың өчен Аллаһыдан курыкмыйсыңмы? Нишләтәсең син бу мескенне, кайчанга хәтле шулай кыланырга җыенасың?» – дип сорады. Умәйә: «Син аны боздың, син аны коткар да инде», – диде. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе: «Мин шулай эшләячәкмен дә. Минем кара тәнле колым бар. Ул синекенә караганда көчлерәк һәм синең динеңне тотуда ныграк», – диде. Умәйә риза булды һәм алар Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән колларын алмаштырдылар. Билял радыяллаһу ганһе Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе тарафыннан азат ителгән җиденче кеше иде.

Билял радыяллаһу ганһе Мәдинәгә һиҗрәт кылучы кешеләр арасында да беренчеләрдән булды.

## Билял радыяллаһу ганһенең югары дәрәҗәсе

Гомәр радыяллаһу ганһе: «Әбү Бәкер безнең әфәндебез, ул икенче әфәндебез Билялне коллыктан азат итте»[1], – дип әйтә торган иде. Икенче тугры хәлифә булган кешедән дә яхшырак итеп кем бәя бирә алыр? Расүлебез галәйһиссәлам Гомәр бине Хаттабны «фарук», ягъни ялганны дөреслектән аеручы, дип атады. Игътибар итик: Гомәр бине Хаттаб Билял радыяллаһу ганһене әфәнде, дип атый. Димәк, тагын бер тапкыр, кешенең дәрәҗәсе аның тәкъвалыгында икәненә инанабыз.

Бервакыт пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Билял радыяллаһу ганһенең йортына килә һәм хатыныннан йорт хуҗасының кайдалыгын сорый. Билял радыяллаһу ганһенең хатыны: «Ул өйдә юк», – дип җавап бирә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Син аңа ачулы ахыры?» – дип сорый. Ул: «Билял кайта да һаман Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: шулай дип әйтте яки болай дип кушты, болай дип сөйли», – дип җавап кайтара. Аллаһының Илчесе: «Аның минем турында әйткәннәре хак. Билял алдамый. Син аны

[1] Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

әрләмә, чөнки, Билял сиңа ачулы булганда, Аллаһы синең гамәлләреңне кабул итми»[1], – дип әйтә.

Билял радыяллаһу ганһедән егермеләп сәхабәләр һәм табигыйннар хәдисләр риваять итә.

## Азан тарихы

Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә күченгәч мөселманнарны җәмәгать намазына җыя иде, алар бергә җыелышып, намаз вакытын көтә торган булганнар. Ул вакытта араларында әле намазга чакыручы кеше булмаган. Бервакыт алар ни рәвешле намаз вакыты җитү турында хәбәр итеп булуы турында уйлана башлаганнар. Кайберләре насаралар сыман кыңгырауга чаң сугуны тәкъдим иткән. Башкалары яһүдиләр сыман сурга кычкыруны әйткән. Ләкин әлеге ысуллар Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ошамаган. Икенче көннең иртәсендә аның янына Габдулла бине Зәед бине Гәбдераббиһи килгән һәм бу төнне үзенең гаҗәеп төш күрүен бәян иткән: «Төшемдә яшел төстәге кием кигән ир кешене күрдем. Аның кулында кыңгырау иде. Шуннан мин аннан: «Йә Аллаһының колы! Син бу кыңгырауны сатмыйсыңмы?» – дип сорадым. Ул: «Ә син аның белән нишлисең?» – дип сорады. Мин: «Без аның ярдәме белән кешеләрне намазга чакырыр идек», – дип әйттем. Ул миннән: «Сезгә яхшырак әйбер киңәш итимме?» – дип сорады. Мин: «Ә нәрсә яхшырак?» – дидем. Ул: «Син әйт: Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәдән Олуграк! Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәдән Олуграк! Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәдән Олуграк! Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәдән Олуграк! Гуаһлык бирәмен ки, тәхкыйк, бер Аллаһы Тәгаләдән башка һичбер илаһ юк! Гуаһлык бирәмен ки, тәхкыйк, бер Аллаһы Тәгаләдән башка һичбер илаһ юк! Гуаһлык бирәмен ки, тәхкыйк, Мөхәммәд галәйһиссәлам – Аллаһы Тәгаләнең илчеседер! Гуаһлык бирәмен ки, тәхкыйк, Мөхәммәд галәйһиссәләм –

[1] Ибне Гасәкир риваять итә.

Аллаһы Тәгаләнең илчеседер! Намазга ашыгыгыз! Намазга ашыгыгыз! Котылуга ашыгыгыз! Котылуга ашыгыгыз! Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәдән Олуграк! Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәдән Олуграк! Аллаһы Тәгаләдән башка һичбер илаһ юк!» Шуннан ул бераз дәшмичә торды һәм: «Ә шуннан соң, син әлеге сүзләрне берәр мәртәбә кабатлап чыгасың һәм «Намаз башлана!» дип әйтәсең», – дип әйтте.

Әлеге төшне мин Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сөйләгәч, ул: «Аллаһының ризалыгы булса, әлеге төш хак төш булыр. Билял радыяллаһу ганһе янына барып, аңа күргән төшеңне сөйлә, чөнки аның тавышы синекеннән югарырак», – дип әйтте. Мин Билял радыяллаһу ганһе белән янәшә бастым һәм аңа әлеге сүзләрне әйтеп тордым, ә ул кешеләрне намазга чакыра башлады. Моны ишетеп Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһе да өеннән ашыгып чыкты һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә мөрәҗәгать итеп: «Сине хаклык белән җибәргән Зат белән ант итәм! Ул күргән төшне мин дә күрдем», – диде. Шуннан пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы бөек! Бу тагын да ышанычлы»[1], – дип әйтте.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, Билял радыяллаһу ганһене «Ислам мөәзине» дип түгел, ә «Аллаһы Илчесенең мөәзине» дип атаганнар, чөнки ул азанны пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исән вакытында гына әйтә торган булган. Ә аның үлеменнән соң ул бары тик бер тапкыр гына азан әйткән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әлеге дөньядан китеп, аның урынына мөселманнарның эшләре белән идарә итү өчен Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе билгеләнгәч, Билял радыяллаһу ганһе берничә тапкыр азан әйтергә тырышып караган, ләкин «Гуаһлык бирәмен ки, тәхкыйк, Мөхәммәд галәйһиссәләм – Аллаһы Тәгаләнең Ил-

1 Әхмәд, Әбү Давыд, Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

чеседер», – дигән сүзләргә җитүгә, аны күз яшьләре баса торган булган һәм ул бер сүз дә әйтә алмаган. Ул Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе янына барып: «Йә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә алмашка килүче, мин Пәйгамбәребезнең: «Мөселманнарның иң яхшы гамәлләре – Аның юлында тырышлык күрсәтү, ягъни җиһад», – дип әйтүен ишеткән идем, – дигән. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе: «Син нәрсә телисең, Билял?» – дип сораган. Ул: «Мин үлгәнче мөселман җирләренең чикләрен сакларга телим», – дип җавап биргән. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе: «Ә безгә азанны кем әйтер соң?» – диде. Билял радыяллаһу ганһенең күзен яшь элпәсе каплый һәм ул: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үлеменнән соң мин бер кемгә дә азан әйтмәячәкмен», – диде. Әбү Бәкер радыяллаһу аңа ганһе: «Китмә, безгә азан әйтергә кал», – дип әйтте. Билял радыяллаһу ганһе: «Әгәр син мине коллыктан үзеңә булыр өчен коткарган булсаң, син әйткәнчә булсын. Тик әгәр син мине Аллаһының ризалыгы өчен коткарган булсаң, мине, Аның ризалыгы өчен ирекле иткән, Аллаһыга калдыр», – диде. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе: «Аллаһы белән ант итәм, мин сине Аллаһы ризалыгы өчен сатып алдым һәм Аның өчен ирекле иттем. Үзеңнең кая барасың килсә, шунда бара аласың», – дип әйтте.

Билял радыяллаһу ганһе Дәмәшкъга юл тота һәм шунда мөселман җирләренең чикләрен саклый.

Берничә ел үткәч, бер төнне Билял радыяллаһу ганһе төшендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күрә. Пәйгамбәребез аңа: «Йә Билял, синең яктан миңа карата нинди салкынлык бу, минем янга барып кайтырга вакыт түгелме икән сиңа?» – ди. Билял радыяллаһу ганһе борчылып уянып китә, аның күңелен курку били һәм ул тиз арада юлга чыга. Мәдинәгә барып җитү белән, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең каберенә бара һәм елый башлый. Вакыт-вакыт ул йөзен кабер өстенә дә куя. Аны шул халәттә пәйгамбәребез

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең оныклары Хәсән белән Хөсәен радыяллаһу ганһүмәләр күрәләр. Билял радыяллаһу ганһе йә берсен, йә икенчесен кочаклап елый. Алар аннан Пәйгамбәребез вакытындагы кебек азан әйтүләрен сорыйлар. Билял радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез мәчетенең түбәсенә менеп, элек азан әйткән урынына басып: «Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!» – дип әйтә башлаган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үлеменнән соң азан бер тапкыр да яңгырамаган һәм шуңа Мәдинә шәһәренең кешеләрен зур дулкынлану биләп алган.

Билял радыяллаһу ганһе: «Әшһәдү әл-ләә иләһә илләл-лааһ, әшһәдү әл-ләә иләһә илләл-лааһ», – дип дәвам иткән.

Әлеге сүзләрне ишетеп, Мәдинә шәһәре кешеләрендә калтырау барлыкка килгән.

Билял радыяллаһу ганһе тагын дәвам итеп: «Әшһәдү әннә Мүхәммәдәр-расүүлүл-лааһ, әшһәдү әннә Мүхәммәдәр-расүүлүл-лааһ», – дип дәвам иткән.

Мәдинә шәһәренең бөтен кешесе урамга йөгереп чыккан һәм берберсенә яшьле күзләре белән карап сорый башлаганнар: «Әллә Аллаһы Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне терелткәнме?» Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үлем көнен санамаганда, беркайчан да аның кадәр елаучы кеше булмаган[1].

## Билял радыяллаһу ганһенең үлеме

Билял радыяллаһу ганһе үлем хәлендә ятканда аның хатыны: «Йә, кайгы!» – дип әйткән. Ә Билял радыяллаһу ганһе: «Йә, шатлык, иртәгә мин яраткан, якын кешеләрем – Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның төркеме белән күрешәчәкмен», – дип әйткән.

[1] Әлеге вакыйганы Ибне Әсакир һәм Әбү Мөхәммәд Макдиси радыяллаһу ганһүмәләр тапшырдылар.

Билял радыяллаһу ганһе һиҗри буенча 20 нче елда Дәмәшкъ шәһәрендә 63 яшендә үлә, шунда кабере дә сакланган. Бүгенге көнгә кадәр анда кешеләр килеп йөри. Аллаһы Тәгалә аннан разый булсын һәм безне Үзенең бәрәкәтеннән мәхрүм итмәсен иде! Әәмин.

*Интернет ресурстан тәрҗемә*

# Фән

# Шәригать хөкемнәре

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим

## Харам золми вә харам гайре золми

Харам шәригатьтә бик каты тыелмыш гамәлдер. Аны кылу һич тиеш түгелдер. Харам гамәлне кылган кеше бик гөнаһлы булыр. Гөнаһ булуыннан куркып кылмый калган кеше саваплы булыр. Харамны хәләл дигән кеше имансыз булыр.

Харам гамәл ике төрледер: харам золми вә харам гайре золми. Харам золми – кылучы кешенең үзеннән башка кешегә дә зарары вә зыяны тия торган харамдыр. Мәсәлән: кеше үтерү вә сәбәпсез кыйнау вә яман тел тидерү, вә кеше малын урлап йә талап яки алдап алу кебектер.

Харам гайре золми – кылучының үзеннән башка кешегә зарары вә зыяны тимичә, үзенә генә гөнаһ китерә торган харамдыр. Анда башка кешенең хакы юктыр. Мәсәлән: харам тәгамнәрне ашау вә харам эчемлекләр эчү кебек. Харам золми вә харам гайре золминең аермалары шулдыр – харам золми кылган кеше соңыннан үкенеп тәүбә кылса да, зарар вә зыян ирешкән кеше риза булмыйча торып, Аллаһы Тәгалә ул кешенең гөнаһысын гафу итмәячәктер. Әмма харам гайре золми кылган кеше соңыннан үкенеп, ихлас илә Аллаһы Тәгаләгә тәүбә кылса, Аллаһы Тәгалә ул кешенең гөнаһысын шул сәгатьтә гафу итүе дә ихтималдыр. Мәсәлән: берәү бер кешенең малын урлап, йә талап алса, ул кеше соңыннан үкенеп никадәр тәүбә кылса да, мал иясен бәхилләтеп, ризалыгын алмыйча торып, Аллаһы Тәгалә аның гөнаһысын гафу итмәячәктер, чөнки гафу итсә, мал иясенә җәбер вә золым кебек буладыр. Әмма бер төрле харам тагәмне, йә харам эчемлекне эчкән кеше үкенеп, ихлас илә гөнаһыдан тәмам тәүбә кылса, шул сәгать Аллаһы Тәгалә аның гөнаһысын гафу итүе ихтималдыр. Чөнки бу мәсьәләдә һичкемгә җәбер вә золым юк-

тыр. Аллаһы Тәгалә Гафур вә Рәхимдер. Ихлас илә тәүбә кылган кешенең тәүбәсен кабул итүне вәгъдә кылмыштыр.

## Харам золми булган гамәлләр

Мөэмин вә мөселман булган кешегә кылуы харам золми саналган гамәлләрнең мәшһүрләре 93тер:

1. Кеше үтермәгез.
2. Һичбер хайванны утта яндырмагыз.
3. Кешенең бер әгъзасын кисеп йә сугып имгәтмәгез.
4. Һичбер файдасын уйламыйча, адәмгә зарары тими торган хайваннарны үтереп, җан кыймагыз.
5. Хайваннарның битләренә сукмагыз.
6. Кирәк кеше булсын, кирәк хайван булсын, җан иясенә һич золым кылмагыз.
7. Һичбер кешенең малын урлап ашамагыз.
8. Һичбер кешенең малын талап ашамагыз.
9. Иясе мәгълүм булган малны иясенә тапшырмыйча, үзегездә тотмагыз.
10. Сатуда йә алуда үлчәүдә хыянәт кылып, кеше малын үз малыгызга катнаштырмагыз.
11. Начар вә бозык малны алдап, яхшы мал бәясеннән сатмагыз.
12. Бирәчәк бурычларны түләмичә, үзегездә калдырмагыз.
13. Кулыгызга әманәт итеп бирелгән малны үзегезгә алып калмагыз.
14. Корсактагы җанлы баланы дару вә агу белән үтермәгез.
15. Ятим баланың малларын үз кирәгегезгә тотмагыз.
16. Хезмәт иткән кешенең хакын, хезмәте тәмам булгач та, бирмичә үзегездә тотмагыз.
17. Су кебек һәркемгә уртак булган малны бер кешегә усаллык илә алдырмыйча тормагыз.

18. Ялган сөйләп, һичбер кешегә зарар китермәгез.

19. Ялган акча ясап, чын акча урынына кешегә бирмәгез.

20. Һичбер кешенең гаепләрен белергә тырышып тикшермәгез.

21. Һичбер кешенең гаепләрен көйләп, бәетләп әйтмәгез.

22. Кеше алдында бер кешенең гаепләрен үзенә ишеттереп сөйләмәгез.

23. Үзе югында һичбер кешенең гаепләрен сөйләмәгез.

24. Кешенең гаепле җирләрен ишарә кылып, йә ачык күрсәтмәгез.

25. Бер кеше хакында һич юк гаепләрне бар итеп сөйләмәгез.

26. Үлгән кешенең һичбер гаепләрен сөйләмәгез.

27. Кешенең сөйләшүен йә кыяфәтен кыланып күрсәтеп хурламагыз.

28. Мәетнең тәнен кисмәгез вә сындырмагыз.

29. Мөэмин кешене имансыз, дип сүкмәгез.

30. Кешенең ата-анасын вә нәселен кабахәт сүзләр илә сүкмәгез.

31. Зина кылуы хак булмаган кешене зиначы, дип сүкмәгез.

32. Шөбһә илә үз хатыныгыздан туган баланы минем балам түгел, димәгез.

33. Гаепсез кешене залим түрәләргә чакыртып, гаепле итеп сөйләмәгез.

34. Ирле-хатынлы кешенең арасында сүз йөртеп, аларны бер-берсенә дошманлаштырмагыз.

35. Бер кешенең икенче бер кеше хакында сөйләнгән сүзен сөйләнмеш кешегә барып әйтмәгез, ягъни сүз йөртмәгез.

36. Ике дошман арасына кереп, һәр икесенә үзләренчә сөйләмәгез.

37. Ике дус кешенең араларын бозып, бер-берсенә дошманлаштырмагыз.

38. Хатыннарны куркытып, бер-берсе белән сугыштырмагыз, бер-берсенә каршы талаштырмагыз.

39. Кешегә начар кушаматлар чыгармагыз вә кушамат илә атамагыз.

40. Яшерен сөйләшкән кешеләрнең сүзләрен үзләренә белгертмичә тыңламагыз.

41. Сүз сөйләшүче кешеләрнең сүзләренә аркылы төшеп, каршы килеп, сүздән туктатмагыз.

42. Файдасыз сүзләрдән өстен чыгу вә үз сүзеңне аста калдырмау өчен, сүз көрәштермәгез.

43. Бер кешенең һичкемгә зарары тими торган яшерен серен халыкка белгертмәгез.

44. Васыять әйтү белән яки бүләк кылу илә, яки юк бурычны бар дип раслау, яки бер хәйлә илә варисларыгызга калачак малыгызны киметергә тырышмагыз.

45. Садака сораган йә бер йомыш сораган кешене сүкмәгез, вә аңа каты сүз әйтмәгез.

46. Кешегә, гәрчә уйнап булса да, кылыч-пычак вә күсәк илә кизәнмәгез.

47. Балаларыгызны, хатыннарыгызны вә хезмәтчеләрегезне кечкенә генә гаепләре өчен каты сүкмәгез.

48. Балаларыгызга, хатыннарыгызга вә хезмәтчеләрегезгә көчләре җитмәслек эш кушмагыз.

49. Бик кечкенә баланы имчәктән аермак өчен, йә башка бер эш өчен кыйнамагыз.

50. Хезмәтчеләрегезне вә кул астында булган кешеләрегезне һичберсен кыйнамагыз.

51. Зарарлы эшләр кылып күршеләрегезне рәнҗетмәгез.

52. Сәлам биргән кешегә, йә бер сүз әйткән кешегә, җавап бирмичә йөзегезне читкә бормагыз.

53. Бер эшне кылырга ниятегез булмаганда, алдап, кылырмын дип, вәгъдә кылмагыз.

54. Иманлы кешенең эшен яманлыкка юрап, һичбер дәлилсез, явыз гөман (фикер) кылмагыз.

55. Кешенең өй эченә рөхсәтсез карамагыз.

56. Һичбер хатын вә кызны көчләп, вә җәберләп, әгъзаларына кул тидермәгез.

57. Кеше өенә рөхсәтсез кинәттән килеп кермәгез.

58. Рөхсәтсез, кешенең яшерен хатын укымагыз.

59. Гуаһлыгыгыз (шаһит) хак була торып, гуаһлыгыгыздан тайпылмагыз.

60. Гуаһлыгыгыз булмаганда, ялган гуаһлык бирмәгез.

61. Үзегез хаклык тарафында булмаганда, мәхкәмәгә (хөкем йортына) барып, дәгъва кылмагыз.

62. Кешегә җәбер вә золым итүченең золымлыгына ярдәм кылмагыз.

63. Шәригатькә хилаф (каршы) хөкем итеп, һичбер кешегә зарар китермәгез.

64. Бәһа куярга тәгаен кылынганда, золымлык илә бер нәрсәнең бәһасен кыйммәт йә арзан куеп, һичбер кешегә зарар китермәгез.

65. Халык арасына сугыш, кычкырыш вә дошманлыкка сәбәп була торган фетнәләр салмагыз.

66. Ашлык кебек халыкка бик кирәкле нәрсәне арзан вакытта җыеп, беткәч, халыкка зур бәһале итеп сатмагыз.

67. Сатулык малыгызның гаепләрен алучыга әйтмичә, алдап сатмагыз.

68. Хәзрәти Расүлуллаһка явыз тел тидермәгез, бу эш харам гына түгел, бәлки имансызлыктыр.

69. Һичбер малны тиешле бәһасенә караганда, ике бәһа белән алучыга алдап сатмагыз.

70. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтмәгән сүзне Пәйгамбәр галәйһиссәламнең сүзе дип сөйләмәгез.

71. Ата-анагызны рәнҗетерлек эшләр кылып рәнҗетмәгез.

72. Остазларыгызны хурлап вә мәсхәрә кылып рәнҗетмәгез.

73. Балаларыгызга вә шәкертләрегезгә җәбер вә золым кылмагыз.

74. Хатыныгызны йә ирегезне рәнҗетмәгез.

75. Якын кардәшләр, бер-берегездән бизмәгез.

76. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәләмнең сәхабәләренең һичберсенә явыз тел тидермәгез.

77. Галим кешеләрне сүкмәгез вә хурламагыз.

78. Җәбер кылу максаты белән һичбер кешене оялтмагыз.

79. Җәбер кылу максаты белән һичбер кешене куркытмагыз.

80. Кешене алдап, ялгыш юлга җибәреп, адаштырмагыз.

81. Алдау нияте белән һичбер кешегә зарарлы киңәш бирмәгез.

82. Юл салучыларга уңайсызлык китермәгез.

83. Фәкыйрь кешеләрне фәкыйрьлеге өчен хурламагыз вә кимсетмәгез.

84. Һичбер кешене үзендә булмаган эшләр илә мактаган булып, алдап, дуслык изһар кылмагыз.

85. Һичбер кешене алдап сөйләштереп, серен алырга тырышмагыз.

86. Кыз баланы үзе риза булмаган кешегә көчләп никахламагыз.

87. Дүрт ай буена хатыныгыз белән һич күрешмичә сәфәрдә йөрмәгез.

88. Хатыннар! Сәбәпсез ирегезнең йортыннан чыгып, кайтмый йөрмәгез.

89. Зинадан пакь хатыныгызны, син зиначы дип, сүкмәгез.

90. Кешене алдап, буш эш эшләтмәгез вә хезмәт иттермәгез.

91. Гаһед куеп (вәгъдәләшеп), сүз куешкан эштә гаһедегезне бозмагыз.

92. Патша вә түрә булган кешеләр! Кул астыгыздагы кешеләргә җәбер вә золым кылмагыз.

93. Гадел патша вә әмир! Мөэминнәрнең хөкемнәренә каршылык кылып баш тартмагыз.

## Харам гайре золми булган гамәлләр

Мөэмин вә мөселман кешегә кылуы харам гайре золми саналган гамәлләрнең мәшһүрләре:

1. Имансыз булмагыз.

2. Аллаһы Тәгаләнең кылган эшләрен яратмыйча сөйләмәгез.

3. Иманыгызны юкка чыгара торган сүзләр сөйләмәгез.

4. Имансызлыкка китерә торган эшләрне кылмагыз. Мәсәлән: Аллаһы Тәгаләдән башка нәрсәләргә сәҗдә вә гыйбадәт кылу (ширек кату). Коръәнне хурлау, имансыз кешеләргә охшасам иде дип, аларның киемнәрен киеп йөрү кебек.

5. Аллаһы Тәгаләдән башка нәрсәләрнең ризалыгы өчен корбан чалмагыз. Мәсәлән: мәет ризалыгы өчен вә җеннәрнең зарарыннан имин булу өчен.

6. Аллаһы Тәгаләнең газап кылуыннан курыкмыйча, имин вә куркусыз булмагыз.

7. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өмет кисмәгез.

8. Иман вә игътикадтә үз фикерегез илә дәлилләрне һич уйламыйча кешегә ияреп кенә йөрмәгез.

9. Башланган фарыз вә ваҗиб гамәлләрне юри бозмагыз.

10. Фарыз вә ваҗиб булган гамәлләрне кылмый калмагыз.

11. Гает фитыр (Ураза бәйрәме), Гарәфә, Гает корбан вә аннан соңгы өч тәшрикъ көннәрендә руза тотмагыз.

12. Багучылык кылып, киләчәк заманда булачак эшләрдән хәбәр бирмәгез.

13. Багучыларның сүзләренә вә йолдызларга карап, киләчәктә булачак эшләрдән хәбәр итә торган мөнәҗимнәрнең (астрологларның) сүзләренә ышанмагыз.

14. Сихер гамәлләре кылган булып шөгыльләнмәгез.

15. Үзегездә булмаган яхшылык илә халык арасында макталуыгызга кызыкмагыз.

16. Мәккә-и Мөкәррәмәдә вә аның тирәсендә булган «Харам» дип аталган җирләрдә һичбер гөнаһ эш кылмагыз.

17. Бер кешенең гөнаһ вә харам эшне кылуына күңелегездән куанып тормагыз.

18. Һичбер кешене гөнаһ эшләргә димләмәгез.

19. Һичбер кешене саваплы эшләрдән тыймагыз.

20. Гөнаһ эшләрне кылуга һәвәсләндерә торган җыр вә шигырьләр сөйләмәгез.

21. Гөнаһ эшләрне кабул кылуга һәвәсләндерә торган сүзләр сөйләмәгез.

22. Гөнаһ эшләргә ярдәм кылмагыз.

23. Сөннәт гамәлләргә хилаф бер гадәт чыгармагыз.

24. Гөнаһ эшләрнең кылынуына күңелегездән сөенеп тормагыз.

25. Мәкруһ булган эшләрне гадәт итеп күп кылмагыз.

26. Шәригатькә хилаф булган гөнаһлы вә зарарлы гадәтләрне чыгармагыз.

27. Дин эшеннән дөнья эшен артык күрмәгез.

28. Һичбер эшне кирәк кадәреннән артык кылмагыз.

29. Отыш уеннары уйнап, акча вә мал отышмагыз.

30. Табыш илә, ягъни арттырып түләү шарты илә, бурычка акча бирмәгез.

31. Мәхкәмәдә (судта) йә сәүдәдә файда кылмак өчен, мал вә акча алмагыз.

32. Нәҗес вә харам нәрсәләр белән сәүдә кылмагыз.

33. Үз ихтыярыгыз илә үзегезнең авыру булуыгызга сәбәп була торган эшләр кылмагыз.

34. Һичбер кешене олуглап, рөкүгъ вә сәҗдә кылмагыз. Мәсәлән: артык иелеп вә бөгелеп сәлам бирү; вә җиргә ятып, аягына егылып ялвару.

35. Дөнья ләззәтләренә вә дөнья малына бик комсыз, һәвәсле вә хирыс булмагыз.

36. «Фәлән эшне кылсам, имансыз булыйм», – дип ант итмәгез.

37. Икмәктер, кояштыр дип, Аллаһы Тәгаләдән башка нәрсә илә ант итмәгез.

38. Харам эшне кылганда «Бисмилләһ» дип әйтмәгез вә аять укымагыз.

39. Шәригатьтә олуг күренгән нәрсәләрне кечкенәгә вә хурга санамагыз.

40. Мөселман кардәшләрегезгә явызлык кылуны күңелдән ният кылмагыз.

41. Һичбер кешегә зарар вә афәт килүенә сөенмәгез.

42. Үз-үзегезне үтермәгез.

43. Үз-үзегезнең бер әгъзагызны ихтыярыгыз илә киметмәгез вә имгәтмәгез.

44. Кешеләрнең кәефләрен китерү өчен әдәпсез җырлар җырламагыз.

45. Кешеләрнең кәефләре өчен көйле уеннар уйнамагыз.

46. Кешеләрнең кәефе өчен биемәгез.

47. Һич кешегә илтифат кылмаган рәвештә вә һичбер кешене кешегә санамаган рәвештә олуглык кыяфәте илә йөрмәгез.

48. Кешеләрне үзегездән түбән вә хур күреп һаваланмагыз.

49. Кылган гыйбадәтләрегезне күпсенеп, үзегезне изге санап йөрмәгез.

50. Дин мәсьәләсен белер өчен сораган кешегә белә торып әйтми вә өйрәтми калмагыз.

51. Кешегә вә хайванга ләгънәт укымагыз.

52. Кемгә генә булса да, кешегә явыз дога кылмагыз.

53. Гөнаһлы сүзләрне вә гайбәт сүзләрне тыңлап утырмагыз.

54. Көнчелек илә бер кешенең дәүләт вә абруе китүне теләмәгез.

55. Ачуыгыз килгән кешегә үпкәләп, өч көннән артык аның илә күрешмичә, ачуланып йөрмәгез.

56. Ачулы вә кайгылы вакытта киемнәрегезне ертмагыз, бернәрсәне дә атып ташламагыз.

57. Харам гамәл кылганыгызны һичбер кешегә күрсәтмәгез, кылу – бер харам, күрсәтү – икенче харам.

58. Гөнаһ кылучы фәсыйк (бозык) кешеләрне һич дус күрмәгез.

59. Изге вә тәкъва кешеләрне һич дошман күрмәгез.

60. Дөнья малы өчен, бер кешене бик артык тәгъзим кылып (олылап), үзегезне хур күрмәгез.

61. Күңелегездә булмаган эшләрне алдап сөйләмәгез.

62. Һичбер эш илә кәсеп кылмыйча, ялкауланып, эшсез ятмагыз.

63. Үз ризыгың өчен үзегез кәсеп кылмыйча, кешедән садака йә һәдия бирүләрен көтеп ятмагыз.

64. Коръән аятьләрен үзегез теләгәнчә бозып, мәгънә бирмәгез.

65. Вакыф малга һич хыянәт кылмагыз.

66. Бәйтелмал акчасын (дәүләт малын) тиешсезлек илә ашамагыз.

67. Үткән эшкә ялган ант итмәгез.

68. Ирләр, хатын кыяфәтенә кереп, хатын-кыз киемен кимәгез.

69. Хатыннар, ирләр кыяфәтенә кереп, ирләр киеме киеп йөрмәгез.

70. Кара йоннан сугылган мәҗүсиләр кия торган эшләпәне кимәгез. Ак булса яки бер тарафыннан бераз киселгән булса, дөрес дигән риваятьләр бар.

71. Билгә бармак юанлыгы гына нәзек билбау бәйләмәгез.

72. Ирләр! Ефәктән эшләнгән киемнәр кимәгез.

73. Ирләр! Алтын йөзек вә алтын сәгать кеби алтыннан ясалган зиннәтләр илә бизәнмәгез.

74. Ирләр! Йөзек вә билбау, вә кылыч бизәкләреннән башка җирдә көмештән ясалган зиннәтләр илә бизәнмәгез.

75. Алтын савытларны вә алтын коралларны истигъмәл кылмагыз. Мәсәлән: алтын кашык вә алтын саплы каләм тоту кебек.

76. Ирләр вә хатыннар, көмештән ясалган савыт вә коралларны истигъмәл кылмагыз.

77. Кеше вә хайван сурәтләре ясамагыз. Әмма агач вә йорт сурәтләре ясау дөрестер.

78. Ни рәвешчә генә булса да вә кем илә булса да, зина кылмагыз.

79. Зина гамәлләренә һич изгелек кылмагыз.

80. Хатыныгызны көнләмичә ят ирләр илә калдырмагыз.

81. Хатыныгыз хәезле (күрем килү) йә нифаслы (бала тапканнан соң) вакытында һич якынлык кылмагыз.

82. Гаделлек кулыннан килмәслек вә тәрбия кыла алмаслык кеше ике хатын алмасын.

83. Хатыныгызны хәезле вакытта талак кылмагыз.

84. Хатыныгызга берьюлы өч талак кылмагыз.

85. Хатыныгызны апагызга йә бер мөхтәрәм кыз кардәшегезгә охшатып, заһәр кылмагыз.

86. Ирләр! Хатыныгыздан башка хатыннарның йөзләренә күңел һавасы илә карамагыз.

87. Хатыннар! Хәләл ирегездән башка ирләрнең йөзләренә күңел илә карамагыз.

88. Ирләр! Ят хатыннарның тәннәренә күз салмагыз, гәрчә һәвәстән булмаса да.

89. Хатыннар! Ят ирләрнең тәннәреннән намазда өртү (каплану) фарыз булган әгъзаларына күз салмагыз.

90. Ирләр! Ирләрнең намазда өртү (каплану) фарыз булган әгъзаларына күз салмагыз.

91. Хатыннар! Хатыннарның баш, арка, күкрәк вә балтырыннан башка җирләренә күз төшермәгез.

92. Ир балаларның йөзенә күңел һавасы илә карамагыз.

93. Кешенең күз төшерү вә карау харам булган җирләренә кул тидермәгез.

94. Бер-берегезгә хәләл йә мөхтәрәм кардәш булмаган ир илә хатын, икегез генә бер җирдә ялгыз калмагыз.

95. Хатыннар! Бер генә кат бик юка кием киеп йөрмәгез.

96. Үзегезгә кирәк булмаган малыгызны кешегә бирмичә, яндырып йә суга салып әрәм итмәгез.

97. Бер мал йә тәгамне үзегез дә файдаланмыйча, кешегә дә бирмичә, черетеп һәлак итмәгез.

98. Калган ашларыгызны җиргә түгеп, заяга кылмагыз (әрәм итмәгез).

99. Үз ихтыярыгыз илә ашамыйча вә эчмичә торып, үзегезне зәгыйфьләндермәгез.

100. Туйганнан артык ашамагыз вә эчмәгез.

101. Бер-ике көнлек азыгыгыз вә ризыгыгыз була торып, кешедән садака теләнмәгез.

102. Аш вә тагәмне таптап вә түгеп хурламагыз.

103. Зәкят чыгарырлык малыгыз булганда, кешедән садака кабул итеп алмагыз.

104. Нәҗес нәрсәләрне ашамагыз вә эчмәгез.

105. Авыруга сабыштыра торган агулы нәрсәләрне ашамагыз вә эчмәгез.

106. Ите харам булган хайваннарның итләрен ашамагыз, сөтләрен эчмәгез.

107. Шәригатьчә бугазланмаган йә ауланмаган хайваннарның итләрен ашамагыз.

108. Бугазламыйча, бер афәт беләп үлгән хайванның итен ашамагыз.

109. Сасыган вә черегән итләрне ашамагыз.

110. Имансыз кеше суйган йә аулаган хайванның итен ашамагыз.

111. Ите хәләл булган хайванның оят, гаурәт булган әгъзаларын, куыкларын, үтләрен вә бизләрен ашамагыз.

112. Хайваннарның бугазларыннан чыккан каннарын эчмәгез.

113. Йөзем җимеше суыннан ясалган исерткеч эчемлекләрне эчмәгез.

114. Нинди генә заттан ясалган булса да, исертә торган эчемлекләр эчеп исермәгез, ашлыктан йә балдан, йә бәрәңгедән ясалган аракы, сөттән ясалган куәтле кымызлар кебек.

115. Әфьюн (опиум) кебек исертә торган үләннәрне йогып, йә авызга салып, яки суын, яки төтенен сулап исермәгез.

116. Бер кешенең урлап йә алдап кешедән алган малын, белә торып, сатып алмагыз.

117. Мәккә-и Мөкәррәмәдә «Харам» дип аталган җирдә булган киек хайваннарны аулап яки бугазлап үтермәгез.

118. Коръән укылганын ишеткәндә, аны тыңлаудан башка эш белән шөгыльләнмәгез.

119. Намазны вакытында укымыйча, казага калдырмагыз.

120. Рамазан аенда руза тотмый йөрмәгез.

121. Зәкят, гошер вә фитр садакаларын бирмичә, үзегезгә тотмагыз.

122. Өстегезгә фарыз була торып, хаҗны кылмый калмагыз.

123. Коръәнне тәҗвидсез, хәрефләрне үзгәртеп, бозып укымагыз.

124. Госел кылу тиешле булган кешеләр госел кылуны кичектермәгез.

125. Җөнеб (төшләнгән) булган кеше, хәездән йә нифастан арынган хатын госел кылуны кичектермәсен.

*Әхмәтһади Максудиның*

*«Шәригать хөкемнәре» китабыннан*

# Ант итү

Сорау: Нәрсә ул ант итү?

Җавап: Ант итү – ул әйләнә-тирәдәгеләрне берәр нәрсәнең дөреслегенә инандыру өчен әйтелә торган сүз.

С: Ант итүнең нинди төрләре бар?

Җ: Ант итү өч төрле була:

1. Әл-Гамус – ул ялган ант итү, ягъни бер кылынган гамәлне кылмадым дип, яисә киресенчә әйтеп, ант итү. Мәсәлән, берәү: «Валлаһи, мин моны эшләмәдем», – дип ант итә, ләкин дөреслектә ул моны эшләгән була. Мондый ант итү зур гөнаһ һәм алар батучылар дип аталалар, чөнки бу дөньяда гөнаһка, ә соңыннан утка баталар. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Аллаһыга ширек китерү, ата-ананы тыңламау, кеше үтерү һәм ялган ант итү зур гөнаһка керә», – диде. Мондый ант итүче кәффарәт түләргә тиеш түгел, Аллаһы Тәгаләгә тәүбә кылырга тиеш.

2. Ялварулы ант итү – әл-мөнгакыд – ул бер кешенең киләчәктә бер гамәлне кылуга яисә кылмауга сүз бирүе. Бу антны чит кеше аркасында бозса да ул кәффарәт түләргә тиеш.

3. Буш ант итү – әл-ләгу – бер кешенең үткәндә булган бер хәл өчен үзен хаклы дип уйлап ант итүе, ләкин дөреслектә ул ялгыша.

С: Берәүне ант итәргә мәҗбүр итсәләр һәм ул ант итеп, аны бозса, кәффарәт түләргә тиешме?

Җ: Әйе, тиеш.

## Ант итүгә бәйле шартлар

С: Нинди очракларда мөселман ант иткән булып санала?

Җ: Әгәр ул Аллаһы Тәгаләнең Әр-Рахмән, Әр-Рахим кебек бер исеме яки бөеклеге, Аның кодрәте кебек бер сыйфаты белән ант итсә, анты дөрес, Аллаһы Тәгаләнең гыйлеме белән ант итү дөрес түгел.

С: Әгәр кеше «Аллаһының ачуы белән ант итәм» дисә, бу ант итү буламы?

Җ: Юк, ант итү булып саналмый.

С: Әгәр кеше: «Әгәр мин моны эшләсәм, миңа Аллаһының ачуы төшсен» дип әйтүе ант итү булып саналамы?

Җ: Юк, ант итү булып саналмый.

С: Әгәр берәү ант иткәч, «Аллаһы теләсә» дип өстәсә, ант итү буламы?

Җ: Бу ант итү булмый, чөнки аның антын Аллаһы теләсә, бозарга да мөмкин.

С: Әгәр берәү: «Әгәр мин моны эшләсәм, мин яһүди, яисә насара, яисә мәҗүси, яисә потларга табынучы булам», – дисә, бу ант итү булып саналамы?

Җ: Әйе, бу ант итү була һәм аны бозган өчен кәффарәт түләргә кирәк.

С: Әгәр берәү Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән яки Коръән белән яки Кәгъбә белән ант итсә, бу ант итүгә керәме?

Җ: Юк, Аллаһыдан һәм Аның исемнәреннән һәм сыйфатларыннан башка әйберләр белән ант итү ширек китерү булып санала. Әбү Давыд Әбү Һөрайрадан хәдис риваять итә: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әтиләрегез, әниләрегез, үзегезгә тиң булганнар белән, Аллаһыдан башка теләсә нинди нәрсә белән ант итмәгез, бары тик дөресен әйткәндә Аллаһы белән генә ант итегез», – диде.

С: Әгәр берәү намаз укымаска, яки ата-анасы белән сөйләшмәскә, яки кемне дә булса үтерергә ант итсә, нишләргә?

Җ: Бу гөнаһлы эш булып санала, бу кешегә антын бозып, кәффарәт түләргә кирәк. Мөслим Әбү Һөрайрадан хәдис риваять итә: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем дә булса бер нәрсә белән ант итсә, соңыннан бу әйбердән әйбәтрәкне күрсә, үзенең антын бозып, хәерлерәк эшне эшләсен», – диде.

С: Әгәр берәү үзенә-үзе бер нәрсәне тыйса, бу аңа харам буламы?

Җ: Харам булмый, ләкин антын бозган өчен кәффарәт түләргә тиеш.

С: Әгәр кяфер ант итеп, соңыннан Ислам кабул иткәннән соң антын бозса, аңа кәффарәт түләргә кирәкме?

Җ: Юк, кирәкми, чөнки шәригатьтә мөселманның гына ант итүе дөрес булып санала.

С: Әгәр берәү үзе эшли алмаган, мәсәлән, ташны алтынга әйләндерү кебек нәрсә белән ант итсә, ул антын бозучы булып саналамы?

Җ: Әйе, болай итеп ант итүче шунда ук аны бозучы да булып санала.

С: Берәү Басрада булырга ант итсә, ләкин үлеменә кадәр анда була алмаса, аның тормышының кайсы вакытында бу анты бозылган булып санала?

Җ: Гомеренең соңгы вакытында анты бозылган булып санала. Мәсәлән, әгәр ире хатынына: «Әгәр мин Басрага бармасам, син аерыласың», – дисә, үлгәнче Басрага бара алмаса һәм хатыны белән җимагъ кылмаган булса, хатыны иренең үлеменнән соң аның мөлкәтеннән мирас ала алмый. Шулай ук ул гыйддә дә көтми. Әгәр хатыны белән җимагъ кылса, хатыны мирас та ала һәм гыйддә дә көтәргә тиеш була.

## Сөйләшмәскә ант итү

С: Әгәр берәү сөйләшмәскә ант итсә һәм намазда Коръән укыса, анты бозылган булып саналамы?

Җ: Юк, анты бозылган булып саналмый.

С: Әгәр берәү икенче кеше белән берничә көн буе сөйләшмәскә ант итсә, ул ничә көн антын тотарга тиеш?

Җ: Өч көн буена антын тотарга тиеш була.

С: Әгәр берничә ай буена дәшмәскә ант иткән булса, нишләргә?

Җ: Бу очракта, Әбү Хәнифә фикеренчә, 10 ай, ә укучылары әйтүенчә, 12 ай буе антын тотарга тиеш була.

С: Әгәр берәү икенче кеше белән сөйләшмәскә ант итеп, йоклаганда сөйләшсә, анты бозылган булып саналамы?

Җ: Әйе, анты бозылган була.

С: Берәү икенче кешегә аның рөхсәтеннән башка сөйләшмәскә ант иткәннән соң, бу иптәше белән ул рөхсәт иткәч кенә сөйләшсә, ләкин ул аның рөхсәт итүе турында белмәсә, анты бозылган буламы?

Җ: Әйе, анты бозылган була.

С: Берәү икенче кешенең хатыны белән сөйләшмәскә ант итсә һәм бу хатын иреннән аерылгач аның белән сөйләшсә, анты бозылган буламы?

Җ: Юк, анты бозылмый.

С: Берәү икенче кешенең колы белән сөйләшмәскә ант итеп, хуҗасы бу колны азат иткәч сөйләшсә, антын бозган буламы?

Җ: Юк.

## Ашау-эчүдән тыелуга ант итү

С: Әгәр берәү ипи ашамаска ант итсә, аңа нинди ипи ашарга ярамый?

Җ: Ул яши торган илдә яки шәһәрдә гадәттә нинди ипи ашасалар, шул ипине ашарга ярамый. Әгәр ул дөге яки кукуруз көлчәсен ашаса, анты бозылмый.

С: Берәү билгеле бер бәрәннең итен ашамаска ант итсә һәм бу бәрәнне үсеп сарык булганнан соң суеп ашаса, аның анты бозыламы?

Җ: Әйе, бозыла.

С: Бер кеше өлгермәгән җимешләрне ашамаска ант итеп, өлгергәннән соң ашаса, аның анты бозыламы?

Җ: Юк, нәкъ өлгерү яки өлгермәү халәте бу кешенең фикерен билгеләгән сәбәпле бозылмый.

С: Берәү чиләктән су эчмәскә ант итсә, ләкин бу чиләктән чынаякка салып эчсә, анты бозыламы?

Җ: Юк.

*«Әт-Тәсһил әл зарури ли мәсәил Кудури» китабыннан*

# Тарих

# Кәгъбәтулла ачкычын саклаучы Госман бине Талхә тарихы

Бүгенге көнгә кадәр Кәгъбәтулла ачкычы Госман бине Талхә радыяллаһу ганһе нәселеннән булган кешеләрдә саклана.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәгә кайтканнан соң, Кәгъбәтулла ишекләре ябык икәнен күрә. Ачкыч Госман бине Талхәдә була. Әлеге кеше бу вакытта мөселман булмый һәм шуңа да Аллаһы йортын бикләп куеп качкан була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәгә керү белән күп кеше Исламга килә. Аллаһының Илчесе ачкычның кемдә булуын сорый, аңа Госман бине Талхәне күрсәтәләр. Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе Госман бине Талхәгә килеп: «Йә, Госман! Ачкычны бир. Аны Аллаһының Илчесе эзли», – дип әйтә. Госман бине Талхә: «Йә, Мөхәммәд! Әгәр мин синең пәйгамбәрлегеңә ышансам, күптәннән синең өчен Кәгъбәтуллаһны ачар идем», – дип әйтә. Госман бине Талхә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлегенә ышанмыйча, ачкычны бирүдән баш тарта. Гали радыяллаһу ганһе ачкычны урлап, Кәгъбәтуллаһны ача. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы йортына кереп, анда ике рәкәгать намаз укый. Расүлебезнең абыйсы Габбас бине Габделмотталиб аңа болай дип әйтә: «Син безнең нәселебез хаҗиларны су белән тәэмин итү өчен җаваплы булганын беләсең. Шуңа күрә әгәр дә ачкычны безнең кулга бирсәң, безгә икеләтә хөрмәт күрсәткән буласың: без хаҗиларга су да эчерә алачакбыз һәм кирәк булганда синең өчен Кәгъбәтуллаһның ишекләрен дә ачарбыз». Бу вакытта Кәгъбәтуллага аять белән Җәбраил фәрештә иңә.

إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُكُمْ أَن تُؤَدُّوا الْأَمَانَاتِ إِلَىٰ أَهْلِهَا وَإِذَا حَكَمْتُم بَيْنَ النَّاسِ أَن تَحْكُمُوا بِالْعَدْلِ ۚ إِنَّ اللَّهَ نِعِمَّا يَعِظُكُم بِهِ ۗ إِنَّ اللَّهَ كَانَ سَمِيعًا بَصِيرًا ﴿٥٨﴾

**«Дөреслектә Аллаһы әманәтләрен әһелләренә тапшырырга сезгә әмер итәдер һәм кешеләр арасында хөкем итсәгез, гаделлек белән хөкем итегез, диядер. Аллаһының сезне Коръән белән вәгазь кылуы ни хуш нигъмәттер. Әлбәттә, Аллаһы сүзләрегезне Ишетүче, эшләрегезне Күрүче булды».**

«Нисә / Хатыннар», 4:58

Бу аятьтән соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ачкычны Госман бине Талхәгә кайтарырга кирәк икәнен аңлаган. Шул ук вакытта Гали радыяллаһу ганһене чакырып алып, аңа ачкычны Госман бине Талхәгә тапшырырга һәм урлаганы өчен гафу үтенергә кушкан. Гали радыяллаһу ганһе Госман бине Талхә янына килеп: «Йә, Госман, менә синең ачкычың. Аны урлап алганым өчен мине гафу ит», – дип әйткән. Госман бине Талхә гаҗәпләнеп: «Йә Гали, берничә минут элек кенә син мине әрләп, миңа янап чыгып киткән идең, хәзер килеп тыйнак рәвештә гафу үтенәсең, нәрсә үзгәрде соң?» – дип сораган. Гали радыяллаһу ганһе: «Аллаһы белән ант итәм, Госман, әле генә Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә сиңа кагылышлы аять иңдерде һәм сакларга дип тапшырылган әманәтне кире кайтарырга кушты. Бары шул сәбәп белән генә мин сиңа ачкычны кайтарып бирәм», – дип җавап кайтарган. Госман бине Талхә бу сүзләргә тәэсирләнеп, ләә иләәһә илләллаһу Мүхәммәдүр-расүлүллаһ кәлимәсен китерде һәм мөселман булды. Бу хәлләргә җавап итеп Җәбраил фәрештә икенче тапкыр, монысында инде Пәйгамбәребезгә әмер белән килә: «Йә, Мөхәммәд! Госман бине Талхә янына барып хәбәр ит: ачкыч Кыямәт көненә хәтле аның гаиләсендә булачак». Шушы көнгә хәтле Кәгъбәтулланың ачкычы Госман бине Талхәгә нәселеннән булган кешеләрдә саклана. Шул рәвешле вәхи иңүнең көче күрсәтелә. Күз алдыбызга гына китерик, Пәйгамбәребезнең абыйсы үзенә хөрмәт курсәтүне сорап, аннан ачкычны үзенә бирүне сорый һәм аны бары хәерле гамәлләрдә генә кулланачагына сүз бирә. Әмма, Госман бине Талхә мәҗүси булуына карама-

стан, Аллаһы Тәгалә ачкычны аңа кайтарырга әмер бирә. Бу вакыйгадан, Раббыбызның ихтыяры һәм гаделлеге безнең мәнфәгатьләрдән өстенрәк икәнен аңлыйбыз. Аллаһы Үзенең хикмәте белән ачкыч мәсьәләсен шулай хәл итте һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аңа буйсынды. Гәрчә аңа хәтле абыйсы ачкычны үзенә кайтаруын сораган иде һәм башка очракта Расүлебез аңа каршы килә алмаган булыр иде. Бу Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Ислам мәнфәгатьләрен үзенекеннән һәм башка мөнәсәбәтләрдән өстенрәк куйганын күрсәтә.

*Islam-today сайтыннан*

# Финляндия халкына фин телендәге беренче Коръәнне бүләк иткән татар кешесе



**Әхсән Бүре**

Финляндия татарларының иң данлыклы кешеләре арасында Әхсән Бүре (20.03.1886-09.11.1945) исемле шәхес билгеле. Әлеге һәм аннан читтәге җирләрдә ул шулай танылса да, чынлыкта әлеге шәхеснең исеме – Зиннәтулла Имаметдинов.

Финляндия татары булган Зиннәтулла Имаметдинов чыгышы белән Түбән Новгород өлкәсе Кызыл Октябрьск районының Актүк (Актуково) авылыннан. Кечкенәдән бик сәләтле булып үскән Зиннәтулла яшьли сәүдә эшләре белән шөгыльләнә башлый. Баштан Петербург, соңрак Финляндиянең (ул вакытта Терийоки дип аталган) Тампер шәһәрендә төпләнә. Бирекдә ул тукымалар һәм мех эшләнмәләре сатып байый.

Гаиләсенә күз салсак, Зиннәтулла, тугыз балалы гаиләдә тәрбияләнеп үсә. Әтисе Имаметдин Әхсән (1849-1906), әтисе Мәрхәбә Ибраһимова (1855-1941). Гаиләдә биш ир бала: Фәтхетдин, Заһидулла, Зиннәтулла, Габдулла, Габделкаюм, Габделхак һәм өч кыз бала: Хәлимә, Хәлизә, Катия тәрбияләнеп үсә.

«Әхсән Бүре» исеменең килеп чыгышы да кызыклы. «Әхсен» яки «Әхсән» исеме аңа гаиләсеннән бирелгән.  XIX гасырда Рәсәй империясендә, ул вакыттагы тәртипләр буенча, балаларга фамилияне әтисе исеме белән бирәләр иде. Шуның өчен Зиннәтулла әтисе ягыннан Имаметдин фамилиясен ала. Соңрак үз исемен Әхсән дип атап, фамилиясе урынына «Бүре» тәхәллүсен куша.

Алдан ук билгеләп үткәнчә, Әхсән, бик зирәк һәм сәләтле бала була. Ул бик яшьли сәүдә эшләрендә катнаша башлый. Һәм бу тырышлыклары Әхсәнгә кирәкле тәҗрибә тупларга һәм җитди тормыш юлына әзерләнергә ярдәм итә. XIX нчы гасыр ахыры XX нче гасыр башында Түбән Новгород татарларының күпчелеге Петербург шәһәрендә эшләр алып бара торган була. Һәм 1907 елда әле яшь кенә булган Әхсәнне әти-әниләре Петербургка туганнарына озата. Соңрак алар өлкән абыйсы Фәтхетдин һәм тагын бер татар гаиләсе белән аерым фатирга кереп яши башлыйлар. Әхсән Бүренең эшләре бик нык алга китә һәм бу уңайдан ул Финляндиянең ул вакытта Терийоки (Лениногорск өлкәсенең хәзерге Зеленогорск шәһәре) дип аталган шәһәрендә сәүдә эшләре белән шөгыльләнә башлый. Билгеләп үтик: ул вакытта Финляндия Рәсәй империясенә кергән һәм аның чикләре Петербургка якын булган.

1910 елда Әхсән Бүре үзенең бөтен эшен Терийоки шәһәренә күчерә. Аның сәүдәсе һәм милке елдан-ел арта бара. Алга киткән эшләрендә ярдәм итәр өчен ике кече энесен Гәбделхакны (1891-1944) һәм Габдулланы (1888-1949) үзе янына чакырта. 1917 елга абыйлы-энеле туганнар шактый керем туплыйлар. 1919 елда, Финляндия бәйсезлек алганнан соң, Әхсән Бүре үзенең эшчәнлегенең бер өлешен Финляндия көнбатышында урнашкан, тагын да эрерәк – Тампер шәһәренә күчерә. 1922 елда анда мех эшләнмәләре, тукымалар һәм төрек товарлары өчен зур кибет ача.

Әхсән Бүре дини гыйлемгә дә ия булган. 1916 елда ул дин өлкәсендәге имтиханнарны биреп, имам вазифаларын башкаруны үз өстенә ала. Алга таба аның бу сыйфаты финлыларны Ислам дине белән таныштыруга этәрәчәк тә. Киләчәктә Әхсән Бүре Финляндия татарлары арасындагы дөньяви һәм рухи лидерларның берсенә әйләнә. Ул актив рәвештә Рәсәй һәм Төркиянең дин эшлеклеләре белән аралаша. Советлар союзы үзенең чикләрен япканнан соң, ул Төркия белән элемтәләрен тагын да ныгыта. Әхсән Бүре хәйриячелек өчен акча кызганмый. 1930 елда Тампер

шәһәрендә фин-төрек мәктәбен ача. Шулай да әлеге шәхеснең финлылар өчен күрсәткән иң төп хезмәте ул – Финляндия халкын Коръәни-Кәрим һәм аның тәфсире белән таныштыру. Әлеге җиңел булмаган бурыч бик күп тырышлык һәм чыгымнар таләп итә. Әхсән Бүренең акчаларына һәм аның катнашында Коръән фин теленә тәфсир кылына һәм 1942 елда Тампер шәһәрендә бастырып чыгарыла. (Бу эш инде 1936 елда ук тормышка ашырылырга планлаштырылган булган).



Коръәнне тәфсир кылу һәм изге китапны бастыру Финляндия татарлары өчен зур казаныш һәм истәлекле, тарихи вакыйга була. Әхсән Бүре бу гамәле белән үз исемен Финляндия тарихында мәңгеләштерә. Әлеге вакыйгалардан соң эшмәкәр илнең бик күп танылган шәхесләреннән рәхмәт хатлары ала. Бигрәк тә рәхмәт сүзләрен Әхсән Бүре Финляндиянең элеккеге президентлары К. Дж. Штольберг һәм П. Е. Свинхуфвуд, чит ил эшләре министры Штольберг һәм П. Е. Свинхуфвуд, Югары суд рәисе Аарне Рекола, Хельсинки университеты ректоры, математик Рольф Неванлинна һәм башка бик күп күренекле шәхесләр тарафыннан кабул итә.

*islam-today.ru сайтыннан*

# Мирас

# Апанай мәчете тарихыннан

Апанай мәчете («Тау тишеге», «Икенче җәмигъ», «Байлар мәчете») Казан шәһәренең Иске Татар бистәсендәге Каюм Насыйри урамы, 27нче йортында урнашкан.

## Нигез салыну

Аның тарихы Екатерина II тарафыннан яңа ике таш мәчет төзергә рөхсәт бирелүе белән бәйле. Татар сәүдәгәре Якуп Солтангалиевнең ярдәме белән ике катлы кирпеч мәчет бинасы 1768–1770 елларда төзелә. Аның акчалата ярдәм итүе генә түгел, ә үзенең дә тормыш иптәше белән бергә мәчетнең төзелешендә катнашуы билгеле.

Башта мәчет бер заллы, сигез кырлы манаралы, фасады бишәр тәрәзәле булган. 1872 елда мәхәллә халкы 5 мең сум күләмендә акча җыя һәм гыйбадәтханәнең төньяк ягыннан өчәр тәрәзәле ике катлы өстәмә бина кушыла (архитекторы – П.И.Романов). 1882 елда коммерция киңәшчесе Юнысов Исхак Гобәйдулла улы мәчет тирәли кирпеч дивар, бер катлы кибет төзеткән (хәзер К.Насыйри ур., 25 йорт), аны 1887 елда Ю. М. Апанаев зурайткан һәм икенче катын салдырган.

Кызганычка, Якуб Солтангалиевнең нәселе XVIII гасыр ахырында өзелә. Шул вакыттан Апанай мәчете атаклы татар сәүдәгәрләре, Апанаевлар тарафыннан алып барыла башлый. Мәчет атамасының тарихы да шуңа бәйләнеп китә.

«Апанай» дигән исем мәчет мәхәлләсендә Апанаевлар яшәгәнгә бәйле, чөнки, алда әйтелгәнчә, нәкъ шул меценатлар озак вакыт аны карап торганнар. Икенче исем – «Байлар» да Апанаевлардан килә. «Тау тишеге» исеме исә калкулыклы рельеф һәм җимерелә барган ярның якын булуына бәйле.

Мәчетнең беренче имамы булып 1763 елда Муртаза Габделгазизов билгеләнә, биредә ул 30 елдан артык эшчәнлек алып барган. Апанаев мәчетенең беренче имамнарыннан тагын берсе – Кили авылы (Татарстанның хәзерге Балтач районына керә) кешесе, Хиҗазда һәм Бохарада укыган Салих Сәгыйтов булган.

1831 елда, Фәхретдин мулланы алыштырып, танылган дин белгече һәм педагог, Бохарада укып кайткан Исхак Сәгыйтов имам булып сайланган. Аның вафатыннан соң, 1838 елда әлеге урынга Думай авылы (Татарстанның хәзерге Мамадыш районына керә) кешесе Мөхәммәткәрим Мөхәммәтрәхимов билгеләнгән. Ул үзенең вазифаларын 1861 елга кадәр башкарган. Аны И. Сәгыйтовның улы Сәләхетдин алыштырган. С. Сәгыйтов – Апанаев мәчетенең Шәрекъ урта гасырлар тәртибен яклаган соңгы рухание, данлыклы остаз була. Аның иң сәләтле укучыларының берсе – Галимҗан Баруди булган.

1876 елның 19 октябрендә губерна фатихасы белән имам булып Таҗетдин Бәширов расланган. 1880 елда Апанаев мәчетенең имам-хатыйблары булып аталы-уллы Габделгалләм һәм Мөхәммәткасыйм Салиховлар сайланган. Алар мәхәлләдә яңача укыту кертүгә зур хезмәт куйганнар.

Апанаев мәчете шәһәрнең иң бай мәхәлләсендә, Апанаевларның биләмәләрендә урнашкан. Мәчетне һәм мәдрәсәне тоту өчен күп күләмдә акча тотылган. Чыгымнарның бер өлешен мәчет диварлары эчендәге кибет табышы, мәчет амбарларын файдаланудан алынган керем, сәүдәгәр Усмановлар һәм Апанаевларның васыять итеп калдырган байлыгыннан килгән процентлар каплаган.

## Үзгәрешләр кичерү

Апанай мәчете ТатҮБК Президиумының карары нигезендә 1930 елда ябыла. Совет чорында манара, мәчет залларының гөмбәзләре җимерелә, ә эчке як өч катка бүленә. Декоратив элементларның күбесе юк ителә. Бина-

да балалар бакчасы урнаштырыла. Министрлар Кабинетының 1995 елның 18 сентябрендәге карары нигезендә мәчет «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә тапшырыла, косметик ремонт эше башлана.

1995 елда мәчетне мөселман мәхәлләсенә кайтаралар. Шул вакытта мәчетнең имамы мәшһүр дин әһеле, җәмәгать эшлеклесе Вәлиулла хәзрәт Якупов булган. Апанай мәхәлләсе бөтен Рәсәйгә билгеле булган «Иман» нәшрияты эшчәнлеген дәвам иттерә.

Мәчет 2003 елга кадәр эшләгән, аннары төзекләндерү-торгызу эшләренә ябылган. Манара, михраб, эчке яктагы ике каты торгызыла. Бу объект федераль дәрәҗәдәге тарихи һәм мәдәни һәйкәл булып тора, ул тарихи мирасны саклау буенча төрле дәүләт программаларына кертелгән, шуннан соң татар халкының архитектура энҗесе дип саналган мәчетне торгызу эшләре башланган. Апанай мәчете федераль бюджеттан финансларга тиешле һәйкәлләр исемлегенә кертелгән. 2011 елның 2 декабрендә төзекләндерүдән соң Апанай мәчете ачылды.

Хәзерге көннәрдә мәчетнең имам-хатыйбы булып Нияз хәзрәт Сабиров эшли. Мәчет Казан шәһәренең Идел буе һәм Вахитов районнары мөхтәсибәтенә керә.

## Касыймия мәдрәсәсе (Күл буе, Галләмия, Апанай мәчете мәдрәсәләре)

1772 елда Казанда Апанай мәчете каршында ачылган дини уку йорты, кадими мәдрәсә, XX гасыр башында Казанның абруйлы югары дини уку йортларының берсе, 1898 елдан 2нче җәмигъ мәчете мулласы, мөдәррис Мөхәммәткасыйм Салихов (Мөхәммәткасыйм Габделгалләм улы Салихи, 1871-1954) исеме белән аталып йөртелә.

XVIII гасырның 70-елларында Казанда икенче таш мәчет – Апанай мәчете төзелгәч, яңа мәхәллә өчен дини уку йорты да (мәдрәсә) оештырыла. Мәдрәсәгә беренче еллардан ук шәкертләр күп йөри, алар өчен

сәүдәгәр Салих Мостафин 1799 елда хәзерге Борнай мәчете урынында (Әхтәмов урамы, 7нче йорт) агачтан аерым мәчет төзеп бирә.

Мәдрәсәдә укыту эшендә кадими ысуллар кулланылса да, заманына күрә яхшы белем биргәннәр.

«Касыймия мәдрәсәсе реформаларга кадәрге мәдрәсәләр арасында иң беренче урын алып торды, анда иң күренекле мөдәррисләр генә хезмәт итте», – дип билгели Җамал Вәлиди.

«Беренчедән, мәхәлләдә мәдрәсәне тоту өчен беркайчан да акчасын кызганмаган бай сәүдәгәр гаиләләре күп булды, икенчедән, мәхәллә халкы мәчеткә имам итеп, димәк, мәдрәсәгә мөдәррис итеп тә, гыйлем ияләрен җентекләп сайлап ала белде», – дип әйткән Шиһабетдин Мәрҗани.

Ш. Мәрҗани химаяче юмарт сәүдәгәрләрдән бигрәк тә Әхмәтҗан Фазлулла улы Рәхмәтуллинны (1832-1910) билгеләп үтә. Ул мәдрәсәнең ике катлы кирпеч бинасын төзетүне башлап йөри, бина төзелеп беткәч, сыйныф бүлмәләрен җиһазлауны, шәкертләргә яхшы тулай торак, ашханә, кер юу урыны һ.б. көнкүреш биналары булдыруны да кайгырта.

Шиһабетдин Мәрҗани мөгаллимнәрдән бигрәк тә 1830-1875 елларда мәдрәсәдә хезмәт иткән 3 имамны аерып күрсәтә, болар: аталы-уллы Исхак һәм Сәлахетдин Сәгыйтовлар, Мөхәммәткәрим Мөхәммәтрәхимов. Шул ук вакытта Ш. Мәрҗани Мөхәмммәткәрим Мөхәммәтрәхимовның да, Галимҗан Барудиның мөгаллиме булган Сәлахетдин Сәгыйтовның да укыту алымнарын тәнкыйтьли. Шәригать белгече, рухани буласы килгән шәкертләргә «Касыймия» мәдрәсәсеннән дә әйбәтрәк уку йорты булмый. Бохара ислам мәктәбен тәмамлаган, өйләрендә зур-зур китапханәләр туплаган, югары гыйлемле мөдәррисләр, мөгаллимнәр Русия империясенең төрле тарафларыннан күп санлы шәкертләр җыя торган була. 1875 елда мәдрәсәдә 300 дән артык шәкерт укыган.

Алга таба мәдрәсә дә сизелерлек үзгәрешләр кичерә. Укытыла торган фәннәрнең саны арта, дөньяви фәннәр махсус дини фәннәрне кысры-

клый; мәдрәсәнең үз шәкертләре арасыннан үсеп чыккан мөгаллимнәр укыта башлый.

Гарәп теле дәресен Әхмәтһади Максуди (1868-1941) укыта. Ул сигез ел шул мәдрәсәдә укый, укып бетергәч, 1890-1892 елларда шунда ук мөгаллимлек итә. Мәдрәсәләрдәге укыту системасын үзгәртү кирәклеген иртә аңлаган яшь мөгаллим 1892 елда татар мәгарифендә чын мәгънәсендә инкыйлаб ясаган, ягъни татар әлифбасына 6 хәреф кертеп, һәм «Имляда ишетелгәнчә язу тиешле» дигән кагыйдәсеннән файдаланып, үзенең «Мөгаллим әүвәл» әлифбасын бастырып чыгара.

Әлеге мәдрәсәне тәмамлагач, 1909 елдан Әхмәтзәки Вәлиди (1890-1970), мәдрәсә тарихында беренче тапкыр, төркиләр тарихын, төрек һәм гарәп әдәбиятларын укыта, шушы уку йортында ул үзенең халыкара танылу алган төрки телләр белгече карьерасын башлый.

1911-1916 елларда рус сыйныфларында рус теле һәм математика фәннәреннән драматург Гафур Коләхмәтов (1881-1918) белем бирә.

Мәдрәсәдә: булачак галим-дин белгече Муса Бигиев (1873-1949), II һәм III Дәүләт Думасы депутаты Садри Максуди (1875-1945), күренекле татар язучысы Гаяз Исхакый (1878-1954) укый. Шәкертләр арасында булачак язучылар Заһир Бигиев (1870-1902), Галиәскар Камал (1879-1933), Мөхәммәт Гали (1893-1952), Афзал Шамов (1901-1990), җырчы Камил Мотыйгый (Төхфәтуллин, 1883-1941) һ.б. булган.

*«Татарстан Җөмһүрияте: татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре» китабыннан, «Фест» нәшрияты, 1995 ел*

# Тәрбия

# Әдәпләр

## Әдәплелегең сәламең белән беленер

«Әс-Сәлам» – Хак Сөбеханәһу вә Тәгаләнең мөбарәк исемнәренең берсе: кешеләрнең бер-берләренә саулык, тынычлык теләү, хәлен сорашудыр. Димәк, сәлам ул хөрмәт-ихтирам, кадер вә мәхәббәт символы.

Мәүләнә хәзрәтләре әйтүенчә: «Урамнан узучы таныш булмаган кешенең яхшылыгын нәрсәдән белә алабыз? Әлбәттә, сәламеннән!»

Мәгълүм ки, кешегә җәмәгатьчелек тарафыннан бирелә торган бәһа аның тормышындагы башка бәһаләрдән өстен тора. Уку йортын югары билгеләргә тәмамласа да, адәмнәр арасында үз урынын, хөрмәт-игътибарны табып, яхшылык белән беленмәсә, адәмнең хәле мөшкел булыр. Димәк, һәркем иң әүвәлдә халык тарафыннан югары бәһаләнергә тиеш. Моның өчен беренче шарты, һичшиксез, гүзәл сәламләшүедер.

Сәламләшү фәкать кулны сузып, яки «сәлам», «хәлләр ничек» дип кую белән генә гамәлгә ашты дип саналмый. Сәлам нихәтле самими булса, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре дә шул хәтле яхшы була.

Коръәни Кәримдә:

وَإِذَا حُيِّيتُم بِتَحِيَّةٍ فَحَيُّوا بِأَحْسَنَ مِنْهَا أَوْ رُدُّوهَا ۗ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ حَسِيبًا ﴿٨٦﴾

> **«Әгәр сезгә сәлам биреп сәламләсәләр, аннан яхшырак булганы белән сәлам бирегез яки аны кайтарыгыз. Хакыйкатьтә, Аллаһы – һәрнәрсәне исәпләп торучы!»**

«Нисә / Хатыннар», 4:86

Сәлам кагыйдә буенча, «Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ», дип дәшү. Әмма гади генә «Әссәләмү галәйкүм!» дип сәлам бирү бөтенебезгә тиешле бурыч булып тора.

«Әдәбеңне сәламеңнән белерләр» дигән әйтем очраклы гына таралмаган. Димәк, сәлам – әхлакның югары билгесе, әдәп символы, гомумкешелек кыйммәтенең иң гүзәледер.

Кеше гүзәл холыкка, әдәпле булырга омтылса гына, чын мәгънәдә бәхеткә ирешә ала. Сәламга җитди игътибар бирү, бөтенесе белән самими сәлам белән алмашу гадәте кешеләрне берләштерә генә түгел, ә бәлки тәкәбберлектән дә коткара.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә ки: «Җайдак җәяү баручыга, үтеп баручы утырганга, азчылык күпчелеккә сәлам бирә»[1]. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тәмуг әһеле кемнәр икәнен әйтимме? Һәрбер дорфа, буш, мактанчык, канәгатьсез һәм тәкәббер адәм тәмуг әһеледер!»[2] – дип безне кисәтә.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе хәтта балалар яныннан үтеп барса, аларга беренче үзе сәлам биреп үтә иде. Ул сәхабәләргә өйрәтеп килде: «Сез җәннәткә керә алмыйсыз, мәгәр мөэмин булмасагыз, мөэмин була алмыйсыз, мәгәр бер-берегезне яхшы күрмәсәгез, мәхәббәт итмәсәгез». Шулай ук әйтә иде. «Арагызда өлфәт-мәхәббәтне көчәйтә торган гамәлне өйрәтимме?» Сәхабәләр: «Әйе, йә Расүлуллаһ галәйһиссәлам», диештеләр. Ул: «Сәламне таратыгыз!» – дип җавап бирде.

Бер адәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Исламда иң яхшы гамәл нинди?» – дип сорады. Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Ачларны туендыру, таныш вә таныш булмаганнарга сәлам бирүдер», – дип җавап кайтарды.

Бүгенге көндә исә бу сөннәт буенча гамәл кылу кимеде.

1 Әбү Һөрайра.

2 Харис бине Вәхб Әл-Хузагый риваяте.

Асылда озак вакыт күрешми торган дуслар, туганнар кочаклашулары табигый, безнең халкыбыз гадәтенә күрә ир кешеләр кочаклашкан вакытта яңакларын яңакларына тидерәләр, әмма үбешмиләр.

Зирәк халкыбыз кешенең сәлам бирүендәге әдәбенә карап, аның нинди тәрбия алганына бәя бирә дә инде.

Яхшы исемгә лаек булу өчен яхшы гамәлләрне кылу лязем. Яхшы гамәлләрнең башлангычы, нигезе исә сәлам бирүдән башлана. Коръән сүзе белән әйтсәк:

فَإِذَا دَخَلْتُم بُيُوتًا فَسَلِّمُوا عَلَىٰ أَنفُسِكُمْ تَحِيَّةً مِّنْ عِندِ اللَّهِ مُبَارَكَةً طَيِّبَةً ۚ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمُ الْآيَاتِ لَعَلَّكُمْ تَعْقِلُونَ ﴿٦١﴾

**«Әгәр өйләргә керсәгез, бер-берегезне Аллаһыдан булган мөбарәк һәм хуш исәнләшү белән сәламләгез. Менә шулай Аллаһы сезгә аятьләрне аңлата! Шаять, сез гакылга килерсез».**

«Нур», 24:61

Игътибар итик, Раббыбыз безгә «мөбарәк һәм хуш» сәламне әйтергә куша. Без менә шул мөбарәк һәм хуш сүзләрне таратсак икән, сәлам бит ул кеше йөрәгенә юл ачучы мөбарәк сүздер.

## Ашау әдәбе

Мөхтәрәм җәмәгать! Мөселманнар һәрьяктан да әдәплелеккә һәм үз-үзләрен камилләштерүгә омтылырга тиешләр.

Билгеле булганча, Пәйгамбәребезнең әхлагы Коръән булган, ягъни ул үз-үзен тотышында Коръәни Кәримгә һич ихтилаф кылмаган.

Динебез күрсәтмәләрендә ашау кагыйдәләрен яктыртуга аерым игътибар бирелә, чөнки моның белән кеше үзен генә түгел, ә бәлки гаилә әгъзаларын да савапка этәрә һәм сәламәтлеген дә арттыра.

Ашау әдәпләренең беренчесе: тәгамнең хәләл, пакь булуы, ягъни мөселман кеше гаиләсен хәләл ризык белән тәэмин итүгә игътибар бирергә тиеш. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә:

وَكُلُوا مِمَّا رَزَقَكُمُ اللَّهُ حَلَالًا طَيِّبًا ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي أَنتُم بِهِ مُؤْمِنُونَ ﴿٨٨﴾

**«Аллаһы сезгә ризык иткән хәләл һәм хуш ләззәтлеләрдән ашагыз һәм үзегез иман китереп инанган Аллаһыдан куркыгыз!»,** – дип әйткән.

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:88

Димәк, кеше Аллаһы Тәгалә хәләл кылган нәрсәләрне хәләл юл белән табылган акчага сатып алып, кулланырга тиеш.

Ашау алдыннан кулларны юу ашау әдәбенең әүвәлгеседер. Бу турыда Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ашаудан алда кулларны юу бер савап булса, ашап бетергәч юуда ике өлеш савап бар», – дип әйткән. Шул мәгънәдәге башка бер хәдистә исә: «Ашаганчы һәм ашаганнан соң кулны юу фәкыйрьлекне куа, бу гамәл пәйгамбәрләрнең сөннәтедер»[1], – дип әйтелә.

Мөселманнар табын янына утырганда да әдәпне үтәргә тиешләр, ягъни табын янына утыргач торып киткәнчегә хәтле бертөрле утырырга кирәк, янтаеп та, ятып та торырга ярамый. Әбү Җүһайфа радыяллаһу ганһе риваять иткән хәдистә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләммм: «Мин янтайган килеш ашамыйм»[2], – дип әйткән. Шулай ук, Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм аягүрә хәлдә ашауны, су эчүне яратмаган. Мондый хәлдә ашау әдәп нормаларын гына бозып калмый, ә сәламәтлек өчен дә зарарлы санала.

1 Табәрани риваяте.

2 Бохари вә Тирмизи риваяте.

Япон галимнәре күзәтүләренә караганда, аягүрә торган хәлдә ашауга яки эчүгә гадәтләнгән кеше сукыр эчәк (аппендицит) ялкынсынуы белән авырырга мөмкин, чөнки кеше аягүрә торганда сукыр эчәк тамагы югарыга – ризык килү юлына карап ачылган булса, утырганда исә эчәкләр тупланып, шушы эчәк аска карап тора икән. Нәтиҗәдә аңа һичнәрсә төшми.

Уртача ашау да әдәпнең аерылгысыз өлеше. Чиктән тыш күп ашау нәтиҗәсендә ашказаны һәм эчәкләр хәрәкәте азая.

Бу турыда да Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисе бар: «Карынның өчтән бер өлеше ашамлык, янә бер өлеше эчемлек вә калган өлеше һава өчендер». Менә шундый рәвештә тукланган кешенең табибка ихтыяҗы калмый. Бу турыда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Без шундыйлар ки, ачыкканны хис итмичә ризык капмыйбыз, ашаганда да чиктән күп ашамыйбыз!»[1] – дип әйткән

Янә бер әдәп: гаилә әгъзаларының табын янында җыелып ашауларыдыр. «Ризыкның яхшысы күпчелек белән булганыдыр», дип әйтелгән хәдис шәрифкә күрә гаилә әгъзаларының бөтенесе бер табын янына утырган хәлдә ашаулары максатка яраклыдыр, чөнки болай булганда уртада мөнәсәбәтләр ныгый, җылылык арта.

Бер хәдистә: «Бисмилласыз башланган эшнең ахыры китектер», – дип әйтелә. Моңа бөтен эшләр дә карый, димәк, ашауны да бисмилла белән башлау тиешле. Гайшә радыяллаһу ганһә Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять иткән хәдистә: «Кем ашаса, Аллаһының исемен зикер итсен. Әгәр башында Аллаһының исемен зикер итүне онытса «Бисмиллаһи әүвәлүһү вә ахирәһү» дисен[2]», –дип әйткән.

Болай ашый башлау ризыкка бәрәкәт өсти. Тәгам тәнгә сеңеп, кешегә көч керә. Киресенчә булса, бәрәкәт кача. Бу хәл хәдисләрдә дә теркәлгән: «Пәйгамбәребез алты сәхабәсе белән ашарга утырган. Бер

---

1 Суютый, «Җәмигъ әл-кәбир».

2 Әбү Давыд вә Тирмизи риваяте.

әгъраби исә килеп, ике мәртәбә алып бөтен ризыкны ашап бетерде. Шунда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр ул «бисмиллә» әйткән булса, һәммәбезгә дә җитәр иде»[1], – дип әйткән.

Уң кул белән ашау шулай ук сөннәт гамәлләрдән санала. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кем ашаса, уң кулы белән ашасын. Су эчсә, уң кулы белән эчсен».

Әдәпләрнең янә берсе: ризыкны яманламау, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм беркайчан да ризыкны гаепләмәде. Берәр ризык күңеленә хуш килмәсә, ул аны ашамый иде. Әмма ризык яхшы булмады, мин бу ашамлыкны хуш итмәдем кебек сүзләрне әйтми иде.

Шулай ук, ризыкны үтә дә кайнар яки үтә дә суык хәлдә ашамаска, ашаган вакытта эчемлек кулланмаска кирәк. Бу да әдәпкә керә, чөнки кайнар яки суык ризык ашказаны эшләвенә начар тәэсир итә, ашаган вакытта эчемлек эчү ризыкның файдалы матдәләренең тәнгә сеңми калуына сәбәп була.

Ашап бетергәннән соң, әлбәттә, дога кылына. Аллаһы Тәгаләгә хәмед, нигъмәтләр өчен шөкер әйтелә. Шөкер исә нигъмәтләрне бетүдән саклый.

Йомгаклап әйткәндә шуны аңлыйк: кеше сәламәт вә рәхәттә яшәүне теләсә, әйтеп үтелгән әдәпләргә гамәл кылуны вә нигъмәтләрне биргән затка шөкерана итүдә даимчылык кылуы лязем.

## Юлда йөрү әдәбе

Тормышның бөтен өлкәләрендә булган кебек, юлда йөрүгә дә хас әдәп кагыйдәләре бар. Аларның иң беренчесе – дога уку.

Юл йөрү әдәбенең тагын берсе юлда барганда уртача бару. Юлдан барганда тиз-тиз, ашыгып йөрү яки бик әкрен сүлпән йөрү дә ярамый.

[1] Тирмизи риваяте.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм йөргәндә вәкарь белән йөргән. Әнә шул сөннәткә муафыйк гамәл кылу тиешле. Коръәни Кәримдә:

وَعِبَادُ الرَّحْمَٰنِ الَّذِينَ يَمْشُونَ عَلَى الْأَرْضِ هَوْنًا وَإِذَا خَاطَبَهُمُ الْجَاهِلُونَ قَالُوا سَلَامًا ﴿٦٣﴾

**«Һәм Рахманның коллары җир йөзендә түбәнчелек белән йөриләр...»** – дип әйтелә.

«Фуркан / Аеручы», 25:63

Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм юлдан барганда адымнарын җирдән куәт белән, гүяки түбәнрәккә барган кебек ясый иде. Кайчан берәр тарафка борылса, бөтен тәне белән борыла иде, фәкать муенын гына борып тормас иде.

Шулай итеп, юлда йөргәндә әдәп вә тыйнаклык белән йөрү тиешле. Хосусан, базарларда, адәм күп булган урыннарда шулай булу кирәк.

Картларга ихтирам күрсәтү дә ошбу әдәпләр арасына керә. Әгәр юлчы яше олыракка юлыкса, аның артыннан барсын, мөмкин кадәр аңа хөрмәт күрсәтсен.

Юлда дуслар әдәбенә ригая итү дә зарури. Берәр кеше дус яки туганнары белән очрашса, һаваланып, үзен олыга санап, алларыннан үтүгә хәрәкәт итмәве хәерлерәк. Ләкин тәкәбберләнмичә, әдәп, хөрмәт, хезмәт күрсәтеп алларыннан үтеп китүендә зарар юк.

Шулай ук, юлда барган вакытта иптәшләр белән очрашканда артык сораулар бирү дә яхшы түгел. Әгәр берәү аңа сәлам бирсә, җавап биреп үтеп китсен, юлның уртасында аның белән сорауларга батып, сөальләрне күбәйтү дөрес булмас.

Хәзрәти Мөхетдин бинн Әл-Гарәби болай дип әйткән: «Юлда берәр кеше дустын очратканда аннан хәлең ничек, кайдан киләсең яки кая

барасың, дип сорамасын, чөнки бу сорашулар аны уңайсыз хәлгә калдыруы мөмкин».

Юл йөрү әдәбеннән тагын берсен китерик: юлда очраган таш, чәнечкәле нәрсәләр, пыяла һ.б. шуңа охшаш юлчыларга зарар китерерлек әйберләрне алып читкә кую.

*Вәлиулла хәзрәт Якуповның*

*«Вәгазьләр» китабыннан*

# Ата-ананың бала хозурында булган хаклары бәяны

Факыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди Сәгыйд бине Мәсгудтән, ә ул Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять итә. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Әгәр ата-анасы булган мөэмин таңны аларга изгелек кылган хәлдә каршы алса, Аллаһы Тәгалә ул мөэмин өчен җәннәттәге ике ишекне ачар. Ул мөэмингә бу ике ишектәгеләрдән беркем дә ачуланмас. Ата-аналары разый булганчыга кадәр, Аллаһы Тәгалә дә аннан разый булыр».

«Әгәр залим булса дамы?» – дип соралды. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе: «Әгәр залим булса да», – дип әйтте.

Бу хәбәр дә риваять ителде. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе әйтте: «Әгәр мөэмин ата-анага явызлык кылган хәлдә таңга керсә, Аллаһы Тәгалә аңа җәһәннәмдәге ике ишекне ачар. Ата-анадан берсенә генә дә изгелек кылса да, югарыда әйтелгәнчәдер».

Факыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди радыяллаһу ганһе иснәде белән Гата радыяллаһу ганһедән риваять итә. Гата радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Муса галәйһиссәлам: «Әй Аллаһым, миңа васыять ит», – дип әйтте. Аллаһы Тәгалә: «Үзем белән васыять итәм», – дип әйтте. Муса галәйһиссәлам: «Миңа васыять ит», – дип әйтте. Аллаһы Тәгалә: «Анаң белән васыять итәм», – дип әйтте. Муса галәйһиссәлам: «Әй Аллаһым, миңа васыять ит», – дип әйтте. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Анаң белән васыять итәм». Муса галәйһиссәлам: «Миңа васыять ит», – дип әйтте. Аллаһы Тәгалә: «Сиңа атаң белән васыять итәм», – дип әйтте.

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһедән риваять ителде. Ул болай дип әйтте: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бер кеше килде һәм: «Мин көрәшергә телим», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ата-анаң исәнме?» – дип сорады. Ул кеше: «Әйе, исәннәр», – дип

җавап кайтарды. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Болар хакында тырыш»[1].

Факыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Бу хәбәрдә ата-анага изгелек кылу Аллаһы Тәгалә юлында көрәшүдән артыграк икәненә дәлил бар, чөнки Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм ул кешегә көрәшне ташларга һәм ата-анага изгелек эшләргә боерды. Дәхи, без дә шулай әйтәбез, дөреслектә, гомумән бөтен кеше өстенә афәт килмәгән вакытта, кешегә ата-анасы рөхсәт бирмичә, әүвәл Аллаһы Тәгаләнең юлына көрәшкә чыгу дөрес булмас. Ата-анага итагатьле булу – көрәшкә чыгудан артыграктыр».

Бәһез бине Хәким атасыннан, ә ул бабасыннан риваять итте. Аның бабасы: «Әй Расүлуллаһ, кемгә изгелек итим?» – дип сорады. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Анаңа изгелек кыл», – дип җавап кайтарды. Ул: «Моннан соң кемгә?» – дип сорады. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Анаңа» – дип җавап кайтарды. Ул: «Моннан соң кемгә?» – дип сорады. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Анаңа изгелек ит», – дип әйтте. Ул: «Моннан соң кемгә?» – дип сорагач, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Атаңа, моннан соң аннан калган туганнарга һәм башка туганнарга», – дип җавап бирде.

Зәед бине Галидән, ә ул атасыннан, ә ул бабасыннан риваять итә. Зәед бине Галинең бабасы болай дип әйткән: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Әгәр Аллаһы Тәгалә ата-анага гөнаһлы булуда уфтанудан да түбәнрәк нәрсәне белсә, әлбәттә, аны да тыяр иде. Гөнаһлы кеше нәрсәне дә булса кылырга теләсә, кылсын, мәңге җәннәткә кермәс. Изгелек кылырга теләүче теләгән нәрсәсен кылсын, мәңге утка кермәс».

Факыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди болай дип әйтте: «Аллаһы Тәгалә атаны олылауны Үзенең китабында зикер һәм васыять итмәсә дә, ата-ананы хөрмәт итү һәркемгәваҗиб икәнлеге акыл белән дә беленер. Акыллы

[1] Аларны кайгырт (ред.).

кешегә ата-ананың олуглыгын тану һәм аларның хакын үтәү важиб булыр. Акыл ничек белмәсен, бит, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә китапларының барысында да, ягъни Тәуратта, Инҗилдә, Зәбурда һәм Коръәндә зекер итте һәм бөтен китапларында әмер биреп, барлык пәйгамбәрләргә вәхи белән ата-ананы олылауны һәм ата-ананың хакын тануны васыять итте. Үз ризалыгын ата-ананың ризасына һәм Үзенең ачуын ата-ананың ачуына кылды. Янә әйтелде: «Индерелгән өч аять өч нәрсәгә якындыр. Аллаһы Тәгалә аларның берсен дә өч якын нәрсәдән башка кабул итмәс. Өч аятьнең беренчесе, Аллаһы Тәгаләнең сүзедер:

وَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ وَآتُوا الزَّكَاةَ وَارْكَعُوا مَعَ الرَّاكِعِينَ ﴿٤٣﴾

**«Намазны үтәгез һәм зәкятне бирегез».**

«Бәкара / Сыер», 2:43

Бер кеше намаз укыса, әмма зәкятне бирмәсә[1], ул кешенең намазы кабул ителмәс.

Икенчесе, Аллаһы Тәгаләнең сүзе:

وَأَطِيعُوا اللَّهَ وَالرَّسُولَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿١٣٢﴾

**«Аллаһы Тәгаләгә һәм аның Расүленә итагать кылыгыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:132

Берәр кеше Аллаһыга итагать итсә, әмма Пәйгамбәргә итагать итмәсә, аннан кабул ителмәс.

Өченчесе, Аллаһы Тәгаләнең сүзе:

أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ إِلَيَّ الْمَصِيرُ ﴿١٤﴾

**«Миңа һәм ата-анагызга шөкер итегез».**

«Локман», 31:14

1 Мөмкинчелеге була торып та, зәкят бирмәү хакында (ред.).

Берәр кеше Аллаһы Тәгаләгә шөкер итсә, әмма ата-анасына шөкер итмәсә, аннан да кабул ителмәс.

Моңа Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителгән хәдис дәлилдер: «Дөреслектә бала ата-анасына карата гөнаһлы булса, ата-ананың ләгънәте баласының асылын[1] кисәр. Берәү үзенең ата-анасын разый кылса, тәхкыйк, Аллаһы Тәгаләне разый кылды. Бер кеше үзенең ата-анасын ачуландырса, тәхкыйк, үзенең Бар кылучысын ачуландырды. Бер кеше үзенең ата-анасына яки аларның берсенә генә ирешсә[2] һәм аларга яхшылык итмәсә, ул җәһәннәмгә керер һәм Аллаһы Тәгалә аны ерак кылыр».

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Гамәлләрнең кайсысы яхшырак?» – дип соралды. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Вакытында укылган намаз, моннан соң ата-анага изгелек кылу, моннан соң Аллаһы Тәгалә юлында булу», – дип әйтте.

Фәркад Әс-Сәбхидән риваять ителә. Ул әйтте: «Кайбер китапларда, бала өчен ата-анасы янында аларның рөхсәтләре белән генә сөйләшү тиеш, дип укыдым. Аларның алдында уңнан да һәм сулдан да йөрергә тиеш түгел, мәгәр баланы ата-анасы чакырган вакытта, аларга җавап бирү өчен генә йөрер. Шулай булса да, кол хуҗаның артыннан йөргән кебек, алар артыннан йөрер».

Дәхи зикер ителде. Дөреслектә, бер кеше Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә килеп: «Әй Расүлуллаһ, дөреслектә, минем анамның яши-яши акылы үзгәрде һәм зәгыйфьләнде. Мин аны кулым белән ашатам, эчертәм, тәһарәтләндерәм һәм аны иңбашыма күтәрәм. Йә, (шул рәвешле) мин аңа тиешлене кайтараммы?» Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай әйтте: «Юк, йөздән бере дә юк. Шулай булса да,

[1] Тамырын (ред.).

[2] Ата-ананың берсе генә исән булып (ред.).

тәхкыйк, син яхшылык кылдың һәм Аллаһы Тәгалә сиңа аз бәрабәренә күп белән саваплandырыр».

Һәшим бине Горвә атасыннан риваять итә. Атасы: «Хикмәттә язылган: атасына ләгънәт иткән кеше мәлгуньдер. Анасына ләгънәт иткән кеше шулай ук мәлгуньдер. Юлдан чыгучы, яисә сукырны юлдан адаштыручы, Аллаһы исеменнән башка исем белән малны суючы, җиренең чиген үзгәртүче, ягъни үз җирең белән башка җир арасында булган чикне үзгәртүче, ягъни харам булган галәмәтләрне кылучы кеше мәлгуньдер. Ата-анасына ләгънәт иткәннең мәгънәсе, ягъни ата-анасы ләгънәт кылырдай эш кылса, гүя ул кеше ата-анага ләгънәт кылучыдыр», – дип әйтте.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Дөреслектә, ата-ананы сүгү – гөнаһның иң зурысыннандыр». Әйтелде: «Ата-анасын сүгү ничек булыр?» Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Берәү кешенең атасын сүгәр дә, аннан үз атасын сүгәр яки кеше анасын сүгеп, аннан үз анасын сүгәр».

Әббән Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән риваять итә, Әнәс бине Мәлик болай дип әйтте: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында Галькамә исемле бер егет бар иде. Ул бик тырыш иде, эчкерсезлеге олуг булды һәм бервакыт ул авырып китте. Хатынын Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәбәр бирергә җибәрде. Хатыны: «Дөреслектә, минем ирем үлем хәлендә һәм мин сиңа иремнең хәлен белдерергә теләдем», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Билял, Гали, Сәлман һәм Гаммәр радыяллаһ ганһүмнәргә: «Галькамәгә барыгыз, аның хәлен белегез», – дип әйтте. Алар аңа киттеләр һәм янына кереп, Галькамәгә: «Ләә иләһә илләллаһ дип әйт», – дип әйттеләр. Аның теле бармады, һәлак булачагын ачык белгәннән соң, Галькамәнең хәлен Пәйгамбәргә хәбәр итү өчен хәзрәти Билялны Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына җибәрделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Аның

ата-анасы бармы?» – дип сорады. «Аның атасы вафат булды, әмма аның олы яшьтәге анасы бар», – дип әйтелде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Әй Билял, Галькамәнең әнисенә бар, аңа миннән сәлам җиткер һәм аңа: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына барырга көчең җитсә, кил, әгәр көчең җитмәсә, көт. Сиңа Расүлуллаһ үзе килер, дип әйт», – диде. Билял Галькамәнең анасына хәбәр бирде. Галькамәнең әнисе: «Мин үзем аның өчен фида булыйм, мин аңа барырга хаклырак», – дип әйтте. Таягын алып Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм каршысына китте.

Ул хатын Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сәлам биргәч, Пәйгамбәр аңа сәламне кайтарды. Расүлуллаһ галәйһиссәлам аны каршысына утыртты һәм: «Миңа дөресен сөйлә, ялганласаң да, миңа Аллаһы Тәгаләдән Галькамәнең хәле ничек булуы хакында вәхи килде», – дип әйтте. Галькамәнең анасы әйтте: «Әй Расүлуллаһ, улым намаз укый, ураза тота иде. Дирһәмнәрнең бөтенесен садака кыла торган иде. Ул дирһәмнәрнең үлчәве һәм саны күпме икәнен белмәде».

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аның хәле белән синең хәлең ничек булды?» – дип сорады. «Әй Расүлуллаһ, мин аңа ачулы идем», – дигәч, ул: «Бу ни өчен?» – дип кабат сорады. Бу хатын әйтте: «Минем зарарыма хатынына йомшак иде. Һәрнәрсәдә хатынына буйсынды, миңа карата гөнаһлы була иде». Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Галкамә әнисенең ачуы Галькамәнең телен «Ләә иләәһә илләллаһ» кәлимәсен әйтүдән тыйды», – дип әйтте.

Моннан соң Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Билялга болай дип боерды: «Бар, күп итеп утын җыеп яндыр». Бу хатын: «Әй Расүлуллаһ, улымны – йөрәк җимешемне минем алдымда ут белән яндырасыңмы? Минем йөрәгем моны ничек күтәрсен?» – дип сорады. Аңа Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Әй Галькамәнең әнисе, Аллаһы Тәгаләнең газабы катырак һәм газаплырактыр. Аллаһының

Галькамәне ярлыкавы сиңа яшерен булса да, аннан разый бул. Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, син аңа ачулы булган вакытта, аңа намаз, садака файда бирмәс». Галькамәнең анасы кулын күтәреп әйтте: «Әй Расүлуллаһ, Аллаһыны, сине һәм монда булучыларны шаһит итәмен, тәхкыйк, мин Галькамәдән разый булдым».

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Әй Билял, Галькамәгә бар һәм кара, ул «Ләә иләәһә илләллаһ» сүзен әйтә аламы? Бәлки Галькамәнең анасы Расүлуллаһ галәйһиссәламнән оялып, күңелендә булмаган нәрсә белән сөйләгәндер», диде. Хәзрәти Билял китте, Галькамәнең ишегенә барып җиткәч, Галькамәнең «Ләә иләәһә илләллаһ» дип әйткәнен ишетте.

Кергәч: «Әй кешеләр, Галькамә әнисенең ачуы аның телен шәһадәт кәлимәсеннән тыйды. Дөреслектә, аның ризалыгы Галькамәнең телен чиште», – дип әйтте.

Галькамә шул көндә үлде. Аның янына Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм килеп, аны юарга һәм кәфенләргә боерды. Аның өчен җеназа намазын укыды. Моннан соң Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның кабере янына басты һәм: «Әй мөһаҗирләр һәм ансарлар, берәү хатынын үз анасыннан артык күрсә, аңа Аллаһы Тәгаләнең ләгънәтедер. Аның сарыф һәм гадел, ягъни фарыз һәм нәфел намазлары кабул ителмәс», – дип әйтте.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе Аллаһы Тәгаләнең сүзләренең тәфсирен риваять итә:

«Раббың Үзенә генә гыйбадәт итүне һәм ата-анага изгелек кылуны хөкем итте». Ягъни Раббың Үзеннән башкага берләмәвегезне боерды. Янә әйтелер, гөнаһта һичкемгә буйсынмагыз, ләкин сезгә кушкан нәрсәдә һәм ата- анага изгелек кылу, ягъни аларны тәрбияләү һәм алар өчен йомшак булу белән Аллаһыга буйсыныгыз. «Синең каршыңда картлыкка ирешсә, ягъни ата-анадан берсе яки икесе дә картайса, аларга «уф» та дип әйтмә».

Бу сүзнең мәгънәсе шул, ата-анаң картаеп бәвел һәм нәҗесләрен чыгарырга мохтаҗ булсалар, бу вакытта борыныңны тотма, йөзеңне борма. Алар икесе дә син кечкенә булганда бәвелеңне түктеләр, киемеңне нәҗестән чиста тоттылар. Моннан соң Аллаһы Тәгалә әйтте: «Боларны кайтарма, ягъни күңелләрен калдырма. Аларга сүзне авыр кылма, яхшы, йомшак, күркәм сүз әйт. Рәхмәттән түбәнчелек канатын кыл», ягъни кечелек кыл, тәкәбберләнмә. Алар өчен рәхмәтле бул һәм әйт: «Әй Аллаһым, аларга рәхмәт ит, ягъни әгәр үлсәләр, аларга ярлыкау белән дога кыл. Балага ата-анасы исән булганда һәм янә үлгәннән соң аларның хакларын тану важибтер. Һәр намаздан соң аларга ярлыкауны сорап, дога кылу важиб булыр».

Аллаһы Тәгаләнең: «Әй, Раббым, аларның икесенә рәхимлек кыл», дигән сүзләрен, Ибне Габбас үзенең тәфсирендә: «Алар өчен исән булганда һәм үлгәннән соң да ярлыкау белән дога кыл», – дип бирә, ягъни «Алар мине кече булганда тәрбия иттеләр, мин зур булгач, аларны миннән ярлыкау белән бүләклә».

Табигыйннәрнең кайберсеннән риваять ителде. Дөреслектә, алар әйттеләр: «Берәү ата-анасы өчен һәр көнне биш мәртәбә дога кылса, тәхкыйк, ата-ананың хакын үтәгән булыр». Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ إِلَيَّ الْمَصِيرُ ﴿١٤﴾

**«Миңа һәм ата-анаңа шөкер ит, дип боердык, ахырда Миңа кайтасыз».**

«Локман», 31:14

Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү – ул һәр көнне биш мәртәбә намаз уку. Ата-анага шөкер итү – ул һәркөнне биш мәртәбә алар өчен дога кылу. Моннан соң Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: «Аллаһы сезнең күңелегездә

булган нәрсәне белүчедер», ягъни аларның күңелендә ата-анага булган йомшаклыкны һәм яхшылыкны белүчедер.

رَّبُّكُمْ أَعْلَمُ بِمَا فِي نُفُوسِكُمْ ۚ إِن تَكُونُوا صَالِحِينَ فَإِنَّهُ كَانَ لِلْأَوَّابِينَ غَفُورًا ﴿٢٥﴾

**«Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә гөнаһтан кайтучыларга ярлыкаучыдыр».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:25

Ягъни, әгәр ата-ана хакын калдырсагыз, Аллаһы Тәгаләгә тәүбә итегез, чөнки Аллаһы Тәгалә кайтучыларга ягъни гөнаһтан кайтучыларга ярлыкаучы булды.

Әйтелде: «Ата-ана өчен бала хозурында ун хак бар. Беренчесе, ризыкка мохтаҗ булса, баласы аны ризыкландырыр». Икенчесе, киемнәргә мохтаҗ булса, әгәр аңа көче җитсә, аны киендерер. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَصَاحِبْهُمَا فِي الدُّنْيَا مَعْرُوفًا

**«Билгеле булганча, дөньяда боларның икесенә иптәш бул».**

«Локман», 31:15

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу аять турында болай дип әйтте: «Гадәттә, иптәш шул була: һәркайчан ачыксалар, аларны ашату, ялангач булсалар, аларны киендерү».

Өченчесе, ата яки ана баланы хезмәтенә мохтаҗ булса, бала аңа хезмәт итәр. Дүртенчесе, әгәр аны ата-анасы чакырса, аларга җавап бирер һәм аңа әзер булыр. Бишенчесе, әгәр ата-анасы аңа бер эш белән әмер кылса, гөнаһ эш белән әмер итмәгәндә һәм гайбәт белән кушмаганда, аларга буйсыныр. Алтынчысы, ул ата һәм ана белән йомшак сүз илә

сөйләшер һәм авыр сүз белән сөйләшмәс. Җиденчесе, аның исеме белән эндәшмәс. Сигезенчесе, ата-ана артыннан йөрер. Тугызынчысы үзенә разый булган нәрсәне ата-ана өчен разый итеп күрер. Үзе өчен мәкруһ күргән нәрсәне алар өчен мәкруһ күрер. Унынчысы, үзе өчен дога кылганда, Аллаһы Тәгаләгә ата-анасы өчен ярлыкау белән дога кылыр. Нух галәйһиссәламнән хикәя йөзеннән Аллаһы Тәгалә әйтте:

رَّبِّ اغْفِرْ لِي وَلِوَالِدَيَّ

**«Әй Аллаһым, мине һәм минем ата-анамны гафу кыл».**

«Нух», 71:28

Шулай ук Ибраһим галәйһиссәлам хикәя йөзеннән әйтте:

رَبِّ اجْعَلْنِي مُقِيمَ الصَّلَاةِ وَمِن ذُرِّيَّتِي ۚ رَبَّنَا وَتَقَبَّلْ دُعَاءِ ﴿٤٠﴾ رَبَّنَا اغْفِرْ لِي وَلِوَالِدَيَّ وَلِلْمُؤْمِنِينَ يَوْمَ يَقُومُ الْحِسَابُ ﴿٤١﴾

**«Йә Рабби минем үземне һәм балаларымны намазларны үтәүче кыл. Раббыбыз, доганы кабул ит, әй Раббыбыз, мине һәм ата-анамны, мөэминнәрне хисапка торгызган хәлдә, ягъни Кыямәт көнендә ярлыка».**

«Ибраһим», 14:40-41

Кайбер сәхабәләрдән риваять ителә: «Ата-анага дога кылуны ташлау бала өчен тормышны тар кыла. Ул балага ата-анасы вафат булганнан соң аларны разый кылу мөмкинме?» Аңа әйтелде: «Аларны өч төрле нәрсә белән разый кылыр. Беренчесе, баланың изге булуы, чөнки ата-анага баланың изгелегеннән сөеклерәк һичнәрсә булмас. Икенчесе, ата-ананың якыннары һәм дуслары белән аралашу, күрергә бару. Өченчесе, алар өчен ярлыкауны сорау, дога кылу һәм алардан садака бирү».

Галә бине Габдрахман атасыннан, ул Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Әгәр

адәм баласы вафат булса, аның гамәле киселә, әмма өч гамәле киселмәс. Ул – җәрия садакасы, файдалана торган гыйлем, ярлыкау сорап дога кылучы изге бала».

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителә. Дөреслектә, ул салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Атаңны якын күрүче белән дуслыкны өзмә. Әгәр киссәң, нурыңны сүндерерсең, чөнки синең мәхәббәтең – атаң мәхәббәтедер».

Дәхи зикер ителде. Бәни Сәләмә кабиләсеннән бер кеше Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә килде. Ул кеше болай дип әйтте: «Дөреслектә, минем ата-анам вафат булдылар. Боларның изгелекләреннән берәр нәрсә калдымы?» Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Әйе, калды. Аларга ярлыкау теләү, васыятен кичерү, дусларын хөрмәтләү. Ата-анаңны якын итә торган кардәшләрне якын күрү».

Аллаһы Тәгалә белүчедер.

*«Тәнбиһүл-гафилин» китабыннан*

# Баланың ата хозурында булган хакы бәяны

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Ата өчен баланың хакыннан өч нәрсә бар: бала туганнан соң аңа күркәм исем бирү, телә башлаганнан соң ул балага Коръәнне өйрәтү, яше җиткәч, өйләндерү яки кияүгә бирү».

Гомәр радыяллаһу ганһедән риваять ителә: дөреслектә, бер кеше аңа үз улын китереп болай дип әйтте: «Дөреслектә, бу улым миңа гөнаһ кыла». Гомәр радыяллаһу ганһе аннан: «Атаңа гөнаһ кылуда Аллаһыдан курыкмыйсыңмы? Чөнки бу атаның хакыннандыр», – дип сорады. Улы: «Әй мөэминнәр әмире, улның атасы каршында хакы бармы?» – дип сорады. Гомәр радыяллаһу ганһе әйтте: «Әйе бар, улының ата каршындагы хакы – ул улының анасын хур кылмау, ягъни улы өчен хатыны сәбәпле гарьлек булмасын өчен түбән дәрәҗәле хатынга никахланмас». Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Улының исемен күркәм кылу һәм улына Коръән өйрәтү». Улы әйтте: «Аллаһы белән ант итәм, анамны хурламады түгел, хурлады, ул анам, Синд шәһәренә бәйләнгәндер. Атам анамны дүрт йөз дирһәмгә сатып алды. Исememне дә күркәм кылмады, «юләр» дип атады. Аллаһы Тәгаләнең китабыннан бер аятьне дә өйрәтмәде». Гомәр радыяллаһу ганһе атага карады һәм: «Улым мине рәнҗетә дип әйтәсең, ул сине рәнҗетүдән элек син аңа, тәхкыйк, гөнаһ кылгансың. Миннән чык», – дип боерды.

Факыйһ радыяллаһу ганһе әйтте: «Атамнан ишеттем, Әбү Хәфес Әл-Йәскәнди хикәя кыла. Ул Сәмәрканд галимнәреннән булды. Аңа бер кеше килде һәм: «Дөреслектә, улым миңа сукты һәм рәнҗетте», – дип әйтте. Әбү Хәфес болай дип әйтте: «Сөбеханәллаһ, ул атасына сугамы?» Бу кеше: «Әйе, сукты һәм мине рәнҗетте», – дип әйтте. Әбү Хәфес: «Аңа әдәпне һәм гыйлемне өйрәттеңме?» – дип сорады. Ул кеше: «Юк», – дип җавап

кайтарды. Әбү Хәфес: «Аңа Коръәнне өйрәттеңме?» – дип сорады. Ул кеше юк дип җавап кайтарды. Әбү Хәфес: «Ул нәрсә эшли?» – дип сорады. Ул кеше: «Игенче булып эшли», – дип җавап кайтарды. Әбү Хәфес: «Ни өчен сиңа сукканын белдеңме?» – дип сорады. Ул кеше юк дип җавап кайтарды.

Әбү Хәфес әйтте: «Шаять ул улың таңга кергәндә һәм игенчелеккә юнәлгәндә ишәккә атланган булган, сабан – үгезе алдында, эт артында булгандыр. Ул Коръәнне күркәм укымаган, син җырлагансың да, аңа катнашкансың, ул сине сыер дип уйлаган. Аллаһы Тәгаләгә шуңа хәмед ит, яхшы әле башыңны сындырмаган».

Сәбит Әл-Баннани радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Ул: «Дөреслектә, бер кеше бер урында атасына суга торган булды. Аңа әйтелде: «Бу нәрсә?» Атасы әйтте: «Аңа катнашмагыз, чөнки мин бу урында атамны суга торган идем һәм үзем бу урында суга торган улым белән бәлаләндем. Бу минем сугу белән бәрабәр, аның өчен шелтә юктыр», – дип әйтте.

Кайбер хакимнәр әйттеләр: «Бер кеше ата-анасын рәнҗетсә, баласыннан шатлыкны күрмәс. Бер кеше эшләрендә киңәш кылмаса, хаҗәтенә ирешмәс. Гаиләсе өчен тырышмаса, тереклекнең ләззәте китәр».

Шәгъби Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Баласына ярдәм иткән атага Аллаһы Тәгалә Үзенең изгелеге хозурына рәхмәт иткән иде. Ягъни атасы ул эштә гөнаһ кылудан курка торган эш белән баласына әмер итмәс».

Изгеләрнең кайберәүләреннән риваять ителә. Дөреслектә, ул улын бер эш белән дә әмер итми иде. Бернәрсәгә мохтаҗ булса, улыннан башкага куша торган иде. Бу эшеннән соралды. Ул: «Дөреслектә, мин улыма бер эш белән әмер кылсам, моның сәбәпле, миңа гөнаһлы булыр һәм ул тәмугны үзенә ваҗиб итәр, дип куркам. Мин улымны тәмуг белән яндырмыйм», – дип җавап кайтарды.

Фөдаел бине Гыйад: «Кешелеклелекнең тәмамы[1] – ул ата-ананы хөрмәтләү, туганнарны якын күрү, кардәшләрне хөрмәтләү, хатыны, баласы һәм хезмәтче белән үз холкын күркәм кылу, динне саклау, малны ислах, ягъни төзек кылу, малның артыгын нәфәка[2] кылу, эшсез кешеләр белән утырмыйча, йорт эшенә юнәлү», – дип әйткән.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителде. Ул әйтте: «Дүрт нәрсә ирнең изге дәүләтледер: хатынының изге булуы, балалары яхшы булуы, аңа катнашкан кешеләрнең изге булуы, ризыкның үз шәһәрендә булуыннандыр».

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән риваять ителде.

Ул әйтте: «Кеше җиде нәрсәдән соң әҗерләнер. Берәү мәчет төзесә, анда берәү намаз укыса, аның өчен әҗер булыр. Янә берәү елга агызса, ул кешегә бу елгадан аккан һәм кешеләр эчкән су кадәр әҗер булыр. Берәү агач утыртса, аннан кешеләр йә кошлар ашаган кадәр аңа әҗер булачак. Берәү Коръәнне күчереп язса һәм күркәм кылса, ул Коръәнне берәү укыган вакытта, бу кешегә әҗер килеп торыр. Берәү чишмә чыгарса, ул чишмәнең әҗере аңа барыр. Берәү үзеннән соң ярлыкауны теләүче бала калдырса, ул бала изге булса, тәхкыйк, атасы аңа Коръәнне һәм гыйлемне өйрәтсә, ул гыйлемнең әҗере атасына булыр, баласының әҗере кимемәс. Әгәр ата Коръәнне өйрәтмичә, баласына бозыклык юлын өйрәткән булса, аның гөнаһы атасына булыр. Баласының гөнаһы кимемәс.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәр бәндә үлсә, аның өч гамәленнән кала башка гамәлләре киселер: җәрия садакасы, ул калдырган файдалы гыйлем һәм аңа хәерле дога кылучы изге бала», – дип әйтте.

*«Тәнбиһүл-гафилин» китабыннан*

[1] Яхшысы, асылы (ред.).

[2] Бүлеп бирү (ред.).

# МӘҮЛИД ӘН-НӘБИ

# Мәүлидүн-Нәби бәйрәме хакында

Элеккеге заманнарда пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренең туган көнен аерым-ачык билгеләп бәйрәм итү һәм шул көндә фәкыйрь-мескеннәрне ашлар ашатып, аларны садакалар биреп шатландыру, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тууы, үсүе хакында гарәп яки төрки телләрдә бәян ителгән касыйдәләрне укылганы төгәл билгеле түгел.

Әмма һиҗри исәп белән алтынчы гасырда, Ирбиль падишаһы, Мәлик Мозаффар Әбү Сәгыйт Күкбүре бине Гали бине Биктәгин[1], Мөхәммәд Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне ихлас күңеленнән яратканга һәм үзе дә бик юмарт кеше булганга күрә, шушы «Мәүлид – шәриф касыйдәсе»н укуны һәм зур табыннар – ашлар әзерләп, халыкны җыеп ашатуны, шунда күп изгелек кылып, садакалар таратып, кешеләргә ярдәм итүләрне гадәткә кертә. Ул һәр ел саен «Мәүлид – шәриф» көнендә галимнәрне, мәшәехләрне һәм дә күп санлы фәкыйрьләрне җыеп зур аш мәҗлесе ясый. «Мәүлед – шәриф» касыйдәләрен укучыларга һәм голямә, мәшәехләргә яхшы, матур киемнәр бүләк итеп, якынча, өч йөз мең алтын микъдарында мал сарыф итә. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне бик тә яратканга күрә, күңеле тулып, аның өммәтен, бихисап фәкыйрьләрне һәм гыйлем әһелләрен, бу «Мәүлид – шәриф» бәйрәме сылтавы белән, шулкадәр күп маллар сарыф итеп, шатландыра торган була.

Хафиз бине Рәҗәп «Ләтаифүл – мәгариф» исемле китабында дүшәмбе көн ураза тотуның мөстәхәб булуы хакында хәдис-шәриф бәян итеп, «Мәүлид – шәриф бәйрәме»нә һәм анда, ачык рәвештә халыкка белдереп, шөкераналар кылырга кирәклегенә дәлилләр булганлы-

[1] Әбү Сәгыйд Күкбүре бине Гали бине Биктәгин – Әрбил хөкемдары (1190–1232). Ул беренчеләрдән булып 1207 елны Мәүлидне бәйрәм буларак оештырган.

гын күрсәтә. Хәдисләр җыентыгы «Мөслим»дә, Әбү Катада радыяллаһу ганһенең, риваять итүенчә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән, аның дүшәмбе көн ни өчен ураза тотуы турында сорагач: «Зәликә йәүмүн вулидтү вә унзиләт галәййә фиһи ән нүбүвәтә!» – дип әйткән. Тәрҗемәсе: «Бу көн мин туган һәм миңа пәйгамбәрлек иңдерелгән көн!» – дип җавап бирә.

Димәк, бу Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең туган көнен һәм пәйгамбәрлек килгән көнен аерым гыйбадәт белән хөрмәт итүе, шушы олы нигъмәт өчен (кешеләргә сөекле Пәйгамбәрен җибәргәне өчен), мөселманнарның Аллаһы Тәгаләгә шөкерана кылырга тиешлеген күрсәтә. Шуңа күрә, ай хисабы буенча да аның туган көнен, шәригать кысаларыннан чыкмыйча, нинди рәвештә булса да хөрмәт итү нигезсез түгел, ә киресенчә дөрес икәнлеге исбатлана.

Телгә алынган Хафиз бине Рәҗәпнең «Ләтаифүл – мәгариф»ендә, «Мөслим» дә Әбү Катада, радыяллаһу ганһенең риваяте буенча, китерелгән хәдисләргә таянып исбат ителгәннән соң, шулай ук мөхәддис, Факыйһ галимнәрне дә искә алып үтмичә булмас. Суютый, Гаскалани вә Касталани хәзрәтләренең дә, бу мәсьәләдә хәдис-шәрифләр китереп, Пәйгамбәребез галәйһиссаләтү вәссәламнең туган көнен ихтирам итүне, рөхсәтле һәм күркәм эш икәнлегенә фәтва биргәннәрен дә күрә алабыз. Боларны төгәл итеп белергә теләгән кешеләр, шәех Йосыф бине Исмәгыйль Нәбаһәнинең «Хуҗҗәтуллаһи галәл галәмин фи мугъҗизәт сәйидиль мурсәлин» китабына мөрәҗәгать итә алалар!

Вәффәканә-ллаһу вә ийййәкүм бимә фиһи ридаһү! (Аллаһы безгә һәм сезгә Аның ризалыгын алырга ярдәм итсен!)

*Бу мәкалә Дамелла Галимҗан хәзрәт Әл-Барудиның*
*«Әд-Дин вәл-әдәб» журналыннан алынды*

# Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам – иң камил кеше

Безнең чорның алтынчы гасырында, бу дөньяга бөтен кешелек өчен үрнәк камил кеше җибәрелә – соңгы Пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәлам дөньяга туа. Бөек Аллаһы изге Коръәндә җирдәге һәм Ахирәттәге тормыш бәхетле булсын өчен, барлык кешеләргә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә иярергә куша.

Мөхәммәд галәйһиссәлам, пәйгамбәрләр имамы буларак, барлык пәйгамбәрләрнең иң матур сыйфатларын үзендә туплаган. Ул мул сулы елгалар койган диңгез кебек. Һәрбер кеше аның тормышын үзенә үрнәк итеп алырга мөмкин. Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә: «Мин күркәм әхлакны камилләштерү өчен җибәрелдем»[1], – дип әйткән.

Аллаһы Раббыбыз да Коръәни Кәримдә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмне мактап:

وَإِنَّكَ لَعَلَىٰ خُلُقٍ عَظِيمٍ ﴿٤﴾

**«Хакыйкатьтә, син – югары әхлак иясе»**, – дип әйткән.

«Нун», 68:4

Ул игелекле, итагатьле, шәфкатьле, миһербанлы, сабыр, киң күңелле, юмарт, ышанычлы, тыйнак иде. Бу сыйфатлар Пәйгамбәребез галәйһиссәламдә иң камил дәрәҗәдә була. Коръәндә:

لَّقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا ﴿٢١﴾

**«Тәхкыйк, Аллаһы Расүлендә сезгә иярергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр, Аллаһыдан савап-**

---

[1] Имам Әхмәд бине Хәнбәл Мөснәде.

**ны һәм Ахирәттә җәннәтне өмет иткән хәлдә, Аллаһыны күп зекер итүче мөэминнәр өчен»,** – дип әйтелгән.

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:21

Аллаһы Илчесе галәйһиссәламнең әхлак чыганагы – Коръән булган. Шуңа күрә Расүлебезнең холкы нинди иде соң? – дигән сорауга Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә: «Аның холкы – Коръән иде», – дип җавап биргән. Ул Коръәни Кәрим тыйган нәрсәгә ачуланып караган һәм Коръәни Кәрим кушкан нәрсәдән канәгатьләнү тойган. Ул Аллаһыга ошамаган гамәл кылучыларны хөкем иткән һәм шелтәләгән. Расүлебез галәйһиссәлам Аллаһы риза булмаган нәрсәләр өчен генә ачуланган.

Аллаһы Расүле галәйһиссәлам югары дәрәҗәдә намуслы һәм ышанычлы, кешеләр белән мөнәсәбәттә йомшак һәм дустанә кеше булган. Ул әхлакый, саф фикер йөртергә яраткан. Аллаһы Илчесе галәйһиссәламгә тупаслык, әдәпсезлек һәм оятсызлык ят булган. Ул беркайчан да явызлыкка явызлык белән җавап бирмәгән, дошманнарын кичерә белгән. Әгәр кемдер аннан берәр нәрсә сораса, яки берәр нәрсә белән кызыксынса, Аллаһы Илчесе галәйһиссәлам һәрвакыт йомшак һәм төпле итеп җавап биргән, тупас һәм ихтирамсыз бер сүз дә кулланмаган. Ул беркайчан да әңгәмәдәшен ярты сүздә бүлдермәгән. Әгәр берәрсенең сүзе чамадан чыкса, ул аны йә кире каккан, йә торып киткән.

Аллаһының Расүле гәләйһиссәлам: «Миңа тәрбияне Аллаһы Үзе бирде, һәм бу тәрбия нинди күркәм булды»[1], – дигән.

Сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең күркәм яшәү рәвешен, әдәбен күреп бик сокланганнар. Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе болай дигән: «Мин Аллаһының Расүле гәләйһиссәламгә ун ел хезмәт кылдым. Бер мәртәбә дә ямьсез сүз сөйләгәнен ишетмәдем. Беркайчан да: «Бу эшне ник болай эшләдең?» – дип ачуланганын күрмәдем»[2], – дигән.

1 Суютый «Җәмигъ әс-сәгыйрь».

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Аллаһының Расүле галәйһиссәлам күршеләрен хөрмәт иткән һәм кунакларын ихтирам белән кабул иткән. Аның Аллаһы өчен хезмәт итмәгән яки яхшы гамәл кылмаган бер генә минуты да булмаган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам киләчәккә өмет белән караган, төшенкелеккә бирелүне яратмаган. Ул ике эшнең берсен башларга кирәк булганда, аларның иң файдалысын сайлаган. Ул бәлагә төшкәннәргә ярдәм итәргә һәм мәзлумнарны коткарырга яраткан.

Аллаһы Илчесе галәйһиссәлам үзенең сәхабәләрен бик яраткан, алар белән еш киңәшләшкән һәм алар турында кайгырткан. Әгәр сәхабәләреннән берәрсе авырып китсә, ул аларның хәлен белергә бара торган булган. Әгәр берәрсе югалып торса, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аны эзләгән. Берәрсе вафат булса, аның хакына дога кылган. Ул һәрвакыт башкаларның гафу үтенүен кабул иткән, аның өчен көчле дә, көчсез дә үз хокукларында тигез булган. Сүз остасы буларак, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам күп төрле гыйбрәтле хикәяләр һәм тарихлар сөйли торган булган. Ул һәрвакыт дөресен генә сөйләгән.

Аллаһы Расүле галәйһиссәламнең тәрбиялелеге һәм әдәплелегенә килгәндә, ул сәхабәләренә бик мәрхәмәтле, хөрмәтле мөнәсәбәттә булган, кысан җирдә һәрвакыт башкаларга күбрәк урын калдырган. Берәрсен күрсә, ул аны һәрвакыт беренче булып сәламләгән.

Аллаһы Илчесе галәйһиссәлам бик тыйнак булган. Кешеләр җыелган җиргә яки җыелышка килгәч, ул урын бар җиргә утырган һәм моның белән барысының да бертигез хокуклы икәнлеген ассызыклаган. Әңгәмәдәше белән утырганда, беркайчан да аннан алда торып басмаган. Ашыккан вакытта һәрвакыт гафу үтенгән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм беркайчан да ярлыларга фәкыйрьлекләре өчен җирәнеп карамаган, байлар алдында түбәнчелек күрсәтмәгән. Ул һәрвакыт иминлекне югары куйган. Ашаганда, эчкәндә уң кулын файдаланган, чөнки аңа Аллаһы шулай кушкан. Ул хуш

исләрне яраткан: суган, сарымсак кебек начар ис таратучы нәрсәләрне сөймәгән. Аллаһының Илчесе галәйһиссәләм үзенең сәхабәләреннән кием белән дә, җыелышларда утырган урыны белән дә аерылып тормаган. Пәйгамбәребезне белмәгән берәр кеше килсә: «Ә сезнең кайсыгыз Мөхәммәд соң?» – дип сорый торган булган.

Кием кигәндә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам тубык сөягенә кадәр җиткән озын җилән киеп йөрергә яраткан. Кием-салымда да, ризыкта да бернинди артыклыкны кабул итмәгән. Башына чалма һәм башлык кия торган булган, ә уң кулының чәнчә бармагында көмеш балдагы булган. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтте:

لَقَدْ جَاءَكُمْ رَسُولٌ مِّنْ أَنفُسِكُمْ عَزِيزٌ عَلَيْهِ مَا عَنِتُّمْ حَرِيصٌ عَلَيْكُم بِالْمُؤْمِنِينَ رَءُوفٌ رَّحِيمٌ ﴿١٢٨﴾

**«Ий кешеләр, тәхкыйк, сезгә үз арагыздан пәйгамбәр килде, Аллаһыга карышуыгыз аңа авырдыр, сезнең иманга килүегез өчен ул бик тырышучы, мөэминнәргә шәфкатьледер».**

«Тәүбә», 9:128

«Күңелебездә пәйгамбәребезгә мәхәббәт бармы?» – дигән сорау бирәсе килә. Ни өчен без бәхетсез соң? Бездән Раббыбыз канәгатьме? Тормышыбыз кая бара? Без кешеләр белән нинди мөнәсәбәттә? Без аларга ярдәм итәбезме, аларны аңлыйбызмы? Яисә без үзебез турында гына уйлыйбызмы?

Сорауларга җавап табыйк та, тормышыбызны үзгәртик, җәмәгать.

## Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә карата булган әдәп

Сәхабәләр сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә карата һәрвакыт әдәпле булганнар. Алар: «Без Аллаһының Расүле галәйһиссәламнең нәсыйхәтләрен тыңлаганда, күңелләребез Раббыбыз Аллаһыга һәм Аның пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәламгә карата мәхәббәт һәм әдәп белән тула иде, әйтерсең лә башларыбызга кошлар кунган һәм әгәр без хәрәкәтләнсәк, ул кошлар очып китәр иде»[1], – дигән.

Сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә сорау бирергә һәм аның күзләренә туры карарга да оялганнар. Хәтта Аллаһының Расүле Мөхәммәд галәйһиссәлам янәшәсендә еш булган сәхабәләр дә, аңа карата әдәп саклап, аның күзләренә ачык карый алмаганнар. Имам Тирмизи рахимәһуллаһи хәбәр иткәнчә, бары тик Әбү Бәкер белән Гомәр радыяллаһу ганһүмә генә аның күзләренә карап сөйләшә алганнар, калган сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәлам белән сөйләшкәндә күзләрен читкә ала иделәр.

Гамр бине Гас радыяллаһу ганһе үз гомеренең соңгы минутларында болай дип сөйләгән: «Мин озак вакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәлам янында тордым, ләкин аны бик хөрмәт иткәнгә һәм оялганга күрә, башымны күтәреп аңа озак карый алмадым. Әгәр бүген миннән аның йөзе турында сорасалар, ышаныгыз миңа, сөйләп бирә алмас идем»[2], – дигән.

Коръәндә пәйгамбәрләрнең исемнәре китерелгән булса да, Аллаһы Тәгалә соңгы Пәйгамбәргә бер тапкыр да «Йә Мөхәммәд» дип мөрәҗәгать итмәде. Аллаһы Раббыбыз аңа «Йә Нәби», «Йә Расүл», дип эндәште. Аллаһы Тәгалә барлык мөселманнарга Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә карата әдәпле булырга боерды. Бу турыда Коръәндә болай диелгән:

---

[1] Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

لَّا تَجْعَلُوا دُعَاءَ الرَّسُولِ بَيْنَكُمْ كَدُعَاءِ بَعْضِكُم بَعْضًا ۚ قَدْ يَعْلَمُ اللَّهُ الَّذِينَ يَتَسَلَّلُونَ مِنكُمْ لِوَاذًا ۚ فَلْيَحْذَرِ الَّذِينَ يُخَالِفُونَ عَنْ أَمْرِهِ أَن تُصِيبَهُمْ فِتْنَةٌ أَوْ يُصِيبَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ ﴿٦٣﴾

**«Бер-берегезне чакырган кебек, Пәйгамбәрне дә шулай чакырмагыз. Арагыздан бәгъзеләрегез юкны сылтау итеп, мыштым гына (рөхсәтсез) качып киткәннәрне Аллаһы белә. Аң булыгыз, Аның әмереннән качып китеп (бу дөньяда) үзегезгә фетнә-бәла чакыра күрмәгез яки (Ахирәттә) андыйларга бик хәтәр җәза китереп сугуы бар».**

«Нур», 24:63

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе бу аять турында болай дигән: «Кешеләр Аллаһының Расүле галәйһиссәламгә «Йә Мөхәммәд», «Йә Әбү-Әлкасыйм» дип эндәшәләр иде. Аллаһы Тәгалә аның дәрәҗәсен күтәрер өчен, алай дип әйтүдән тыйды, шуннан соң кешеләр Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә «Йә Нәби», «Йә Расүл», дип мөрәҗәгать итә башладылар.

Бер солтан тормышыннан мисал китерәм. Габделгазиз исемле солтан авырып, урын җирендә яткан вакытта, аңа нурлы Мәдинә шәһәреннән хәбәр килә. Ул үз ярдәмчеләрен чакыртып: «Миңа аякка басырга ярдәм итегез. Мәдинә шәһәреннән килгән хәбәрне басып тыңларга тиешмен. Аллаһының Расүле галәйһиссәламнең күршеләрен ятып тыңлау ярамас», – дип әйткән. Нурлы Мәдинәдән хат килгән саен, бу солтан тәһарәтен яңартып, кулына хат алып, аны үбеп, маңгаена куеп: «Бу хатта нурлы Мәдинәнең тузаны», – дигән һәм шуннан соң гына хатны укыган.

## Мәүлид кичәсенең фәзыйләтләре

Хәзрәти Мәгъруф Әл-Кәрхи (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын) болай дигән: «Кем дә булса Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәүлиден укытырга ризык хәзерләсә һәм мәүлидне хөрмәтләп, туган, дус-ишләрен жыйса, өен ут белән яктыртса, яңа киемен киеп, хуш исләр, хуш ислемайлар белән сөртенсә, Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә ул бәндәне Пәйгамбәрләр белән бер төркемдә булдырыр һәм (аның урыны) югары Гыйллийййиндә (җиденче күктә) булыр», – дигән.

Заманының бердәнбере, гасырында берүзе (сыйфатларына карата) булучы Имам Фәхретдин Әр-Рази болай әйткән: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәүлиден тоз, яисә бодай, яки башка бер ризык өстенә укыса шул ризыкка бәрәкәт иңәр. Инде су өстенә мәүлид укылганнан соң, ул суны эчүченең кальбенә (йөрәгенә) мең нур һәм шәфкать хисләре керер, мең явызлык һәм авыру чыгып китәр. Мондый йөрәк, башка йөрәкләр үләчәк көнне үлмиячәктер». Сүз Кыямәт көне турында бара.

Галимнәрнең солтаны Имам Җәләледдин Әс-Суютый (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын) болай дип әйткән: «Берәр йортта, яисә мәчеттә, яисә берәр мәхәлләдә (кварталда) Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәүлиде укылса ул йортның, яисә мәчетнең, яки мәхәлләнең тирә-якларын фәрештәләр чорнап алалар һәм шушы урынның халкына фәрештәләр салават әйтеп торырлар һәм барысына да Аллаһы Тәгалә тарафыннан мәрхәмәт һәм Аллаһының разыйлыгы насыйп булыр. Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Газраил галәйһимуссәлам фәрештәләр исә мәүлид укуга сәбәпче кешегә үзләре салават әйтерләр». Һәм аның хәбәр итүенчә: «Әгәр берәр мөселманның өендә мәүлид укылса, ул өйгә Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән корылык тимәс, вәба (чума) авыруы кермәс, ут тимәс, су (ташкын) тимәс, бәла-афәтләр, нәфрәт, хөсет, явыз күз, караклардан имин булыр. Әгәр

мәүлид укучы бәндә вафат булса, Аллаһы Тәгалә Мөнкир вә Нәкир сорауларына җавап бирүне җиңеләйтер, һәм ул бәндә кодрәтле Аллаһы Тәгаләнең хаклык урынында булыр».

*«Мәүлид Ән-Нәби» китабыннан*

# Йәгез, бер дога

# Дога – гыйбадәтнең җелеге

Үзен мөселман дип санаган кеше һәр эшен, һәр көнен дога белән башларга тиеш. Дога – гыйбадәтнең җелеге, нинди дә булса бер хаҗәтеңне фәкать бер Аллаһы Тәгаләдән генә сорау ул. Без Аллаһыдан үзебезгәме, балаларыбызгамы, якыннарыбызгамы ниндидер изгелек, яхшылык, яки бәла-казалардан иминлек сорыйбыз икән, димәк, Аңа ышанабыз. Шуның өчен дә дога кылу динебезнең әһәмиятле бер өлеше, ул ышануга дәлил булып тора. Аллаһыга ышанмаган кеше Аннан ярдәм сорый да, ярдәмен өмет итә дә алмый. Ышанмау яки ышануның зәгыйфь булуы кешеләрнең киләчәккә өмет белән каравын юкка чыгара. Шул сәбәптән бүгенге көндә күпләр төшенкелеккә, өметсезлеккә бирелеп яшиләр, үз-үзләренә кул салучылар да көннән-көн арта. адәм баласы тынычлыкны Аллаһыдан табасы урынга аны исерткеч эчемлекләрдән, наркотиклардан, кәеф-сафа корып яшәүдән, байлыктан эзли, әмма таба алмый. Бу дөньяда да, Ахирәттә дә мәңгелек хакыйкать һәм мәңге үзгәрмәүче Аллаһы гына бар. Башка бар нәрсә дә үзгәрә һәм вакытлыча гына. Иманы нык кеше үзенә килгән бәла-казаларның вакытлы гына икәненә ышана, Аллаһының ярдәменнән өметен өзми һәм ихлас күңелдән, күз яшьләре белән дога кылып, Раббысыннан сорый: «Раббәнәә әәтинәә фид-дүнйәә хәсәнәтәү вә фил әәхыйрати хәсәнәтәүү вә кыйнәә гәзәәбәннәәәрь», ягъни: «Ии, тәрбиячебез Аллаһы, безгә дөньяда да җиңеллекләр һәм яхшы тормыш бир, Ахирәттә дә ярдәмеңнән ташлама, безне ут газабыннан имин кыл». Кем догасы бу һәм безне шулай дога кылырга кем өйрәтте? Бу – Аллаһының безгә бүләге. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдәге «Әл-Бәкара» сүрәсенең 200 нче аятендә безгә шул рәвешле дога кылырга куша.

Димәк, дога кылганда без фәкать Аллаһыдан гына ярдәм сорарга һәм догабыз да фәкать Аңа гына юнәлгән булырга тиеш. Икенчедән, без дөньядагы нигъмәтләрне генә сорап канәгатьләнергә тиеш түгел, чөнки

бу дөнья – вакытлы бер мизгел генә, дөньядагы борчу-мәшәкатьләр дә вакытлы гына, үтүчән. Әгәр үтеп бетмәсә, үлем бервакыт аңа чик куя. Ахирәт бар, ул – мәңгелек. Һәм андагы газаптан үлеп котылып булмый. Әгәр без бу дөнья рәхәте артыннан гына куып, шуларны гына теләп, шуларга гына алданып яшәсәк, үлеп терелгәннән соң хәлебез бик мөшкел булачак.

Риваять бар: дөнья яралтылгач, Аллаһы җаннарга Җәннәтне дә, җирне дә күрсәтә. Җаннарның кайберләре Җәннәттә калырга теләгән, кайберләре җирне якын күргән. Әмма Җәннәтне дә, җирне дә якын итмичә, безнең фәкать Аллаһы янында буласыбыз килә, – дип әйтүчеләр дә булган. Аллаһы Раббыбыз: «Мин бәла-казалар килгән кешеләргә якын булам, сез шуңа сабыр итә алырсызмы?» – дип әйткән. Ул җаннар: «Сиңа якын булыр өчен, без шуңа риза», – дигәннәр. Алар Җир йөзенә киләчәк пәйгамбәрләр, әүлияләр һәм изге кешеләрнең җаннары булган. Менә шуңа күрә дә иң зур авырлыклар, борчу-мәшәкатьләр, хәсрәтләр пәйгамбәрләргә, аннан соң әүлияләргә һәм изге мөселманнарга килә. Бу төркем кешеләренә Аллаһының вәгъдәсе – Җәннәт һәм ул кешеләр сыйратны да яшен тизлегендә үтәчәкләр.

Игелекле кешеләргә дә бәла-казалар килә, дип күп кеше бу дөньяда алдана һәм көферлеккә төшә. Чөнки иманы зәгыйфь кеше: «Әнә, намаз да укый, уруза да тота, мәчеткә дә йөри, байлыгы да юк, сәламәтлеге дә юк, хәсрәте башыннан ашкан, шулай булгач, фарызларны үтәп, хәрамнан тыелу нигә кирәк?» – дип, ялгыш нәтиҗә ясап харап булалар.

Дога фәкать Аллаһыга гына юнәлгән булырга тиеш. Һәм үтенүче дөнья рәхәтен генә сорап, Ахирәтне онытмасын. Дога кабул булуы өчен шартлары да бар. Иң элек дога ихластан һәм саф күңелдән булырга тиеш.

Менә шул сәбәптән дә инде Пәйгамбәребезнең хәдисендә: «Әти-әнисенең баласына, мәзлумның һәм мосафирның кылган догасына киртә юк», – дип әйтелә.

Әти-әнисенең баласына карата гамәлендә берниндирия юк, алар ихластан, кайвакыт эшләгән эшләре балаларына ошамыйча, ачу-нәфрәт уята торган булса да, ата-ата балабызга яхшы булсын, дип тырыша. Күңелләрендә балаларына карата сафлык, мәрхәмәтлелектән башка нәрсә булмаган өчен, аларның догалары да бәрәкәтле.

Мәзлум кеше – ул кыерсытылган, җәберләнгән, олы кайгы кичерүче кеше. Аның да күңеле, бәгыре кайгы-хәсрәттән телгәләнгән, нечкәргән, йомшарган. Әлбәттә, мондый кешегә кечкенә генә ярдәм дә, бер йомшак җылы сүз дә бик яхшы тәэсир ясый һәм ул ихластан шатлана, аның да ихластан теләгән теләгенең кабуллыгына шик юк. Юк кына бер сүз белән без андый кешене бик каты рәнҗетергә дә мөмкин. Андый кешеләргә карата сизгер, сабыр, ягымлы булырга кирәк.

Без кайвакыт юлдагы кешегә ярдәм итмичә үтеп китеп, каядыр барып җиткәч, садака биреп, кемгәдер дога кылырга кушабыз. Дога бит ул сатыла яки сатып алына торган әйбер түгел. Ул – иманучы белән аның Раббысы арасындагы керсез мөнәсәбәт. Бер изге максатыңа ирешәсең бик килә икән, син нинди дә булса игелек эшләп, мохтаҗнымы, авырунымы, ятимнеме, шәкертнеме, солдатнымы, юксынучынымы, әти-әниеңнеме, халык өчен тырышучы дин әһеленме сөендер һәм Аллаһыдан хаҗәтеңне сора. Кайгыдан гаҗиз булып утыручы, синең гамәлеңнән сөенеп, елмаеп җибәрсә, менә моннан да олы дога була алмый. Ә инде үзебез өчен үзебездән дә ихласрак дога кыла алучы кем бар икән? Үзебезнең хәлне үзебездән дә яхшырак аңлаучы кем бар? Шуның өчен дә без Аллаһының ярдәмен дә ихластан үзебезгә үзебез сорарга тиешбез. Әлбәттә, инде күңелебезнең саф булуы шарт.

Аллаһы Раббыбыз Коръәндә:

وَإِذَا سَأَلَكَ عِبَادِي عَنِّي فَإِنِّي قَرِيبٌ ۖ أُجِيبُ دَعْوَةَ الدَّاعِ إِذَا دَعَانِ ۖ
فَلْيَسْتَجِيبُوا لِي وَلْيُؤْمِنُوا بِي لَعَلَّهُمْ يَرْشُدُونَ ﴿١٨٦﴾

> **«Ии, бәндәм, хаҗәтләреңне Миннән сора, әлбәттә, Мин синең үтенечләреңне ишетүчемен, сиңа ярдәм дә итүчемен, әмма үзең дә Мине танучы һәм кушканнарымны үтәүче бул», – дип белдерде.**
>
> «Әл-Бәкара / Сыер», 2:186

Димәк, үзебез, якыннарыбыз өчен сораган теләкләребез кабул булсын өчен, без Аллаһы кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелучы да булырга тиешбез. Югыйсә, без күп вакыт кәеф-сафа корып, күңел ачып йөрибез, изге гамәлләр кылмыйбыз, бәлагә таргач, садака да бирәбез, дога да кылабыз, нәзер дә әйтәбез. Кайвакыт: «Кичә фәлән әбигә бер сум садака дә бирдем инде, нигәдер авыруым һаман бетми әле», – дип зарланырга да күп сорап тормыйбыз. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Сәламәтлекне садака белән ныгытыгыз», – дигән хәдисе ул: «Сау-сәламәт вакытта фарызларыгызны да үтәгез, мәчетләргә дә йөрегез, изгелекләр дә эшләгез», – дигәнне аңлата.

Дога кылганда калеб-күңел сафлыгы турында түбәндәге риваятьтә бик матур сөйләнә. Бер кавем залим түрәләр золымыннан иза чигә икән. Бу кешеләр Аллаһыдан күпме генә ялварып дога кылсалар да, болар өстеннән золымлык һич китми, кимеми ди. Кешеләр бик аптыраганнар һәм үз хәлләрен бер галимгә аңлатканнар. Әлеге галим бу халык янында бераз яшәгән һәм нәтиҗә ясап: «Әй, кешеләр, сез бит дога кыласыз, әмма сезнең күңелегез үлгән. Аллаһы үле калебтән доганы кабул итми», – дип әйткән. Кешеләр үзләренең күңелләре каралуның, калебләре үлүнең, бәгырьләре катуның сәбәбен сораганнар. Әлеге галим аның 10 төрле сәбәбен әйткән.

Бүген без дә начар, залим түрәләрдән, булдыксыз хуҗалар, начар депутатлардан зарланабыз. Әлеге сәбәпләрне без дә тыңлап карыйк. Бәлки, шифасы тиеп, безнең калебләр дә терелер. Аллаһы насыйп итсә иде.

## Беренче сәбәп

Аллаһыга ышанабыз, дисез, әмма кушканнарын үтәмисез. Без дә бит бүген: «Аллаһыга ышанабыз», дибез. «Ләә иләәһә илләллаһ», – дип тә әйтәбез. Мәет янында бу сүзләрне әйтеп «ярышабыз», әмма күбебез, хәтта әүвәлге һәм иң әһәмиятле булган фарызыбыз – намазыбызны үтәргә дә ашыкмыйбыз. Балаларыбызга да асыл гыйбадәтебезне өйрәтмибез, аларны намаз укырга күнектермибез. Тик картайган көнебездә барыбызга да миһербанлы, шәфкатьле бала кирәк була. Аллаһыга итагать итмәгән бала әти-әнигә дә итагать итә алмый.

## Икенче сәбәп

Коръән укыйсыз, әмма мәгънәсен аңлап гамәл кылмыйсыз. Монысы да безнең турыда әйтелгән кебек. Без дә бит кешеләр җыеп Коръән дә укытабыз, Коръән аятьләрен язып, стенага да эләбез, матча башына да куябыз, муенга тагабыз, кесәгә тыгабыз, тик нишләптер Коръән кушканча яшәргә генә тырышмыйбыз. Хәтта кешеләрдә түр башына менеп, Коръән укып йөрүче «абыстайларыбыз», «муллаларыбыз» арасында да намаз укымаучылар бар.

Без Коръәннең мәгънәсен аңлап, шуның буенча тормыш алып барырга тиешбез. Әгәр ике куллап тотынып эшләмәсә, өйдә балта торганга карап кына хуҗасы балта остасы булмый. Шуның кебек, өйдә Коръән аятьләре тотып кына, әгәр гамәл кылмасаң, хак мөселман булып булмый.

## Өченче сәбәп

Пәйгамбәрне сөябез, дисез, әмма сөннәтләрен үтәмисез. Пәйгамбәребезнең сөннәтләре күп. Әмма иң әһәмиятлесе – беренче урында торганы – җәмәгать намазы. Җәмәгать намазы булган җирдә

дин, ә җәмәгать намазы булмаган җирдә шәйтан була. Бүген өйләрдә, гаиләләрдә тынычлык булмау, бер-береңә хөрмәт белән карамау йортта җәмәгать намазы укымаудан килә. Пәйгамбәребез: «Җәмәгать намазы укырга мөмкинлек булып та, кешеләр намазны ялгыз укысалар, араларыннан шәйтан йөрер», – дип әйткән. Ә инде бөтенләй намаз укылмаган өйгә шәйтан хуҗа була. Бүген мөселманнар арасында татулык, бердәмлек булмауның да бер сәбәбе җәмәгать намазына салкын карау.

### Дүртенче сәбәп

Шәйтанны сөймибез, дисез, әмма аның белән дус яшисез. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дигән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنَّمَا الْخَمْرُ وَالْمَيْسِرُ وَالْأَنصَابُ وَالْأَزْلَامُ رِجْسٌ مِّنْ عَمَلِ الشَّيْطَانِ فَاجْتَنِبُوهُ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٩٠﴾

**«Әй, иман китергән кешеләр, хәмер эчү, отыш уеннары, сыннарга табыну, багучылык белән шөгыльләнү – барысы да шайтан гамәле, алардан ерак торыгыз, шаять котылу табарсыз»,** – дип белдерде.

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:90

Кызганычка, бүген безнең тормышыбызның бар өлкәсендә дә аракы. Адәм баласы өйләндем, дип тә эчә, бала туса да эчә, сөенечтән дә, кайгыдан да исерткечкә тартыла. Элек кеше хезмәт хакы кергән хөрмәткә хәмер авыз итеп алырга ияләшкән булса, хәзер хезмәт хакы түләмиләр, дип эчә. Әле дә Аллаһының рәхмәте киң, безне Җир өстендә тота.

Бер генә ана да, хатын-кыз да иренең яки улының эчеп-исереп кайтуын теләми. Эчеп кайтсалар: «Кайсы юньсезе эчертте икән?» – дип ачулана. Эчертеп җибәрүчегә чын күңелдән, күз яшьләре белән рәнҗи. Шул ук хатынга икенче көнне якынының бер баласы яки ире кунаккамы,

берәр эштә булышыргамы килсә, кичә генә елап, борчылып утырган хатын бүген үзе хәмер тәкъдим итә. Әгәр инде эчертә алса, «Кунак иттем, хөрмәт иттем», – дип сөенә. Ул кешенең хатыны, балалары, әти-әнисе ни әйтер, анысын уйламый. Яшәвебез монафикъларча, үзебезнекеләрнең эчүен теләмәсәк тә, башкаларны эчертәбез. Балаларының ачы күз яшьләре Кыямәт көнендә үлчәүнең кайсы тәлинкәсенә төшәр? Җитмәсә, гәзит тулы йолдызнамә, шуңа карап тормышны көйләргә азапланабыз. Багучылар, ырымга ышанучылар белән дөнья тулды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Диннең зәгыйфьләнгәнен шуннан белерсез, ырымга, хорафатка ышану артыр», – дигән.

## Бишенче сәбәп

Җәннәтне телисез, әмма гамәл кылмыйсыз. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйткән:

الَّذِينَ يُنفِقُونَ فِي السَّرَّاءِ وَالضَّرَّاءِ وَالْكَاظِمِينَ الْغَيْظَ وَالْعَافِينَ عَنِ النَّاسِ ۗ
وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ ﴿١٣٤﴾

**«Ул Җәннәткә омтылучылар кайгылы вакытта да, шатлыклы вакытта да тиешле гыйбадәтләрен кылырлар, ачуларын эчкә алырлар, дошманнарын гафу итәрләр».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:134

Бездә бу сыйфатларның кайсысы бар?

*Җәлил хәзрәт Фазлыев*

# Көн дә кирәкле догалар

## Сәййидүл-Истигъфар

Габдулла бине Бүрәйдә радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Сәййидүл-Истигъфар»ны укыган кеше шул көнне үлсә, Җәннәткә керер. Кичен шушы доганы нык ышану белән укыган кеше шул ук кичтә үлеп китсә, Җәннәткә керер»:

اللَّهُمَّ أَنْتَ ربِ لاَ إِلَهَ إلاَّ أَنْتَ خَلَقْتَنِ وَأَنا عَبْدُكَ وَأَنا عَلى عَهْدِكَ وَوَعْدِكَ مَا اسْتطَعْتُ. أَعوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا صَنَعْتُ أَبوءُ إِلَيْكَ بنعْمَتِكَ عَلى وَاعْتَرفُ بذُنوبِ

فَاغْفِرْ لِى ذُنوبِ إِنَّهُ لاَ يَغْفِرُ الذُنوبَ إلاَّ أَنتَ.

Аллаһуммә әнтә Раббии, ләә иләәһә илләә әнтә, халәкътәнии вә әнә габдүкә вә әнә галәә гаһдикә вә үәгъдикә мәстәтагътү. Әгүүҙү бикә миң шәрри мәә санәгътү, әбүү-ү иләйкә бинигъмәтикә галәййә вә әгътәрифү биҙүнүүбии фәгъфир лии ҙүнүүбии. Иннәһүү ләә йәгъфиру-ҙ ҙүнүүбә илләә әнтә.

«Йә Аллаһым! Син минем Раббым. Синнән башка илаһ юк. Мине Син яраттың. Мин Синең колың. Сиңа биргән вәгъдәмне көчем җиткән кадәр үтәргә тырышырмын. Кылган яманлыкларымнан Сиңа сыенам. Миңа биргән нигъмәтләреңне таныйм һәм гөнаһларымны да таныйм. Мине гафу ит. Дөреслектә, Синнән башка гөнаһларны ярлыкаучы юк».

## Тәүбә догасы

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм түбәндәге доганы кыла торган була:

اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِي مَا قَدَّمْتُ وَما أَخَّرْتُ، وَما أَسْرَرْتُ وَما أَعْلَنْتُ، وَما أَسْرَفْتُ، وَما أَنْتَ أَعْلَمُ بِهِ مِنِّي، أَنْتَ الْمُقَدِّمُ وَأَنْتَ الْمُؤَخِّرُ، لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ

«Йә Аллаһы! Миңа элек һәм хәзер кылган, яшерен һәм күрсәтеп кылган гөнаһларымны һәм Син миннән дә яхшырак белгәнне гафу ит! Син – Үзең теләгәннәрне алдынгы итүче һәм Син – артка Җибәрүче. Синнән башка һич илаһ юктыр».

Көн дәвамында түбәндәге тәүбә догасын мөмкин кадәр ешрак кабатларга кирәк:

أَسْتَغْفِرُ اللَّهَ وَأتُوبُ إِلَيْهِ

«Аллаһымнан ярлыкау сорыйм һәм Аңа тәүбә китерәм».

## Гөнаһ кылсаң укыла торган дога

Золым (начарлык), хата, белмичә һәм белеп гөнаһ кылсаң, Аллаһыдан гафу үтенергә ашыгыгыз:

اللَّهُمَّ اغْفِرْلِى خَطَايَاىَ وَذُنُوْبِى كُلِّهَا

«Аллаһым, барча хаталарымны һәм гөнаһларымны гафу ит».

## Һәр фарыз намаздан соң укыла торган истигъфар

أَسْتَغْفِرُ اللَّهَ العَظِيمَ الَّذِي لاَ إِلَهَ إِلاَّ هُوَ، الحَيُّ القَيُّومُ، وَأتُوبُ إِلَيهِ

«Аннан башка илаһ булмаган, мәңге Исән һәм бар нәрсәгә тереклек Бирүче Аллаһыдан гафу сорыйм һәм Аңа тәүбә китерәм».

### Диндә нык булу өчен укыла торган дога

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм еш кына шушы доганы укый торган булган:

يا مُقَلِّبَ الْقُلوبِ ثَبِّتْ قَلْبِ عَلَى دِينِكَ

«Әй, йөрәкләрне Үзе теләгән шәкелгә кертүче Аллаһым! Минем йөрәгемне Үзеңнең хак динеңә юнәлт».

### Әти-әни өчен истигъфар сорау

رَبِّ اغْفِرْ لِي وَلِوَالِدَيَّ وَلِمَن دَخَلَ بَيْتِي مُؤْمِنًا وَلِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ

Әлеге дога Коръәни Кәримдә килә:

رَّبِّ اغْفِرْ لِي وَلِوَالِدَيَّ وَلِمَن دَخَلَ بَيْتِيَ مُؤْمِنًا وَلِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَلَا تَزِدِ الظَّالِمِينَ إِلَّا تَبَارًا ﴿٢٨﴾

**«Ий Раббым, мине вә ата-анамны ярлыка һәм минем өемә мөэмин булып кергән кешене ярлыка, вә барча мөэмин ирләрне вә мөэминә хатыннарны ярлыка!»**

«Нух», 71:28

Бу доганы Нух пәйгамбәр кылган булса, Ибраһим галәйһиссәлам түбәндәге доганы кыла торган була:

رَبَّنَا اغْفِرْ لِي وَلِوَالِدَيَّ وَلِلْمُؤْمِنِينَ يَوْمَ يَقُومُ الْحِسَابُ ﴿٤١﴾

**«Ий Раббыбыз, үземне вә ата-анамны һәм барча мөэминнәрне ярлыка, Кыямәт көнендә хур итмә!»**

«Ибраһим», 14:41

# Нәсыйхәт

# Гыйлем алуның фазыйләтләре турында

Кечкенә чактан ук олылар авызыннан, Кытайга барып булса да гыйлем ал яки бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлем тупла, дигән сүзләрне ишетеп үсәргә туры килде. Күпләрегезнең мәшһүр татар халык мәкален ишеткәнегез бардыр. Ул болай яңгырый: «Көчле берне егар, белемле меңне егар».

Чыннан да, кешелек тарихында гыйлем алуга, белемле, зыялы булуга зур урын бирелә. Яшәешебезнең һәр тармагын үз эченә алган, бер генә мәсьәләдән дә читтә калмаган динебездә гыйлем гаҗәеп әһәмиятле төшенчәгә ия.

Әбү Дәрда исемле сәхабә болай дигән:

«Гыйлем иясе яки гыйлем алучы яки гыйлемне тыңлаучы бул. Ләкин дүртенчесе булма – һәлак булырсың». Моннан аңлашылганча, һәркайсыбызга гыйлемле, белемле булып, шул гыйлемне башкаларга да өйрәтү тиешле. Мөселман кешегә гыйлем алу бишектән алып ләхеткә кадәр фарыз булып тора. Белем алмый икән, димәк, Аллаһы Тәгалә каршысындагы бурычын үтәми. Дөньяви гыйлемме, дини гыйлемме – мөселман кешесе икесен дә тигез күреп өйрәнергә тиеш. Дөньяви гыйлем белән дини гыйлем бер-берсенә бәйләнгән, бер-берсен тулыландырып торалар. Аларны аерып карау һич дөрес түгел. Дин әһелләре дә, дөньяви гыйлем бирүчеләр дә моны аңларга тиеш. Чөнки дөньяви гыйлемнәр дә Аллаһы Тәгалә куйган кануннарны өйрәтәләр. Физика, химия, биология, математика яки бүтән фәннәр – алар барысы да Аллаһының Җир йөзенә урнаштырган кагыйдәләрен өйрәтә. Кеше нихәтле галимрәк булса, гыйлемне нихәтле күбрәк өйрәнсә, тирәнрәк белсә, ул Аллаһы Тәгаләгә шуның хәтле якынрак була, чөнки ул Аллаһы Тәгаләнең бу дөньяны бик тә камил сурәттә яратканлыгын аңлый. Анда бөтен нәрсә кануннарга буй-

сына, тәртипсез хәрәкәтләнүче бер генә нәрсә дә юк. Бөтенесенең эчендә бертөрле нигез ята. Бөтенесенең төзелеше охшаш, бер-берсенә бәйләнгән һәм берсе-берсеннән башка була алмый.

Гыйлем сүзе Коръәндә 70 тән артык урында кабатланып килә. Аллаһы Тәгалә изге Коръәндә болай дип әйтә:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ

**«Әйт син аларга: «Белгән белән белмәгән бер булырмы?».**

«Зөмәра / Халык Төркеме», 39:9

يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ

**«Аллаһы Тәгалә сезнең арадан иманлыларның һәм гыйлем ияләренең дәрәҗәсен арттырыр. Аллаһы бөтен кылган гамәлләрегезне белеп тора».**

«Мүҗадәлә / Бәхәсләшү», 58:11

Хөрмәтле мөселманнар! Игътибар итегез! Аллаһы Раббыбыз Корәннең иң беренче аяте белән безне белем алырга чакыра:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ

**«Сине барлыкка китергән Раббың исеме белән укы!»** – дип боера.

«Галәк», 96:1

Мөфәссирләр аңлатуынча, бу аятьтәге «укы!» дигән сүз җирдәге һәм күктәге гаҗәеп матурлыкка, төрле мәхлүкъларга карап фикерлә, уйлан, белем ал дигәнне аңлата.

Өйрәтеп калдырган гыйлем өчен савап кеше үлгәч тә гамәл дәфтәренә языла барачак. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм болай дип әйткән:

«Кеше вафат булганнан соң, барлык гамәләре дә өзелә, ләкин аның өч төрле гамәле файда китерәчәк: 1) садакатүл-җәрия, ягъни кеше үлгәннән соң да файда китерә торган садака. 2) башкаларга биреп калдырылган белем; 3) балаларның догалары[1].

Тәфсир галиме Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһе гыйлемнең фазыйләте турында болай дип әйткән: «Гыйлемне кабатлау минем өчен төнне намаз укып чыгуга караганда яхшырак», – дигән.

Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе болай дип әйткән:

«Гыйлем акчадан хәерлерәк, чөнки гыйлем сине саклый, ә син акчаны саклыйсың. Гыйлем ул хөкемдар, ә акча хөкемгә дучар булучы, акчаны – сарыф итү киметә, ә гыйлем тарату белән арта».

Әбү Зәрр һәм Әбү Һөрайра исемле сәхәбәләр (Аллаһы алардан разый булсын) шулай дип әйткәннәр:

«Гыйлемнән бер нәрсә өйрәнү безнең өчен 1000 рәкәгәть нәфел намазына караганда яхшырак. Ә берәр гыйлемне кешегә өйрәтү аны гамәлдә куллануына һәм кулланмавына карамастан безнең өчен 100 рәкәгатьтән дә хәерлерәк».

Хәсән Басри (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын) галимнәр турында болай дип әйткән: «Гыйлем ияләренең язуда кулланыла торган кара буяулары шәһитләрнең каннары белән бергә үлчәнелә һәм гыйлем ияләренең кара буяулары үлчәүдә авыррак булачак».

Бер вакытны мәшһүр галим Ибне Мөбәрактән:

«Әгәр дә сиңа Аллаһы Тәгалә кичкә үләсең дип әйтсә, нишләр идең? – дип сорадылар. Ул: «Гыйлем алыр идем», – дип әйткән.

1 Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Имам Нәвәви (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын) гыйлем алуның нәфел намазын укуга караганда өстенрәк булуын шулай дип аңлаткан: «Бөтен галимнәр дә гыйлем алу – нәфел уразасын тоту, нәфел намазын уку, тәсбих әйтү кебек, тән гыйбадәтләренә караганда яхшырак дип әйттеләр. Моның дәлиле: гыйлемнең файдасы кешенең үзенә генә булмыйча башка кешеләргә дә булганы өчен. Ә нәфел гыйбадәтләр кешенең үзенә генә файда китерә. Шулай ук бөтен гыйбадәтләр дә гыйлемгә мохтаҗ, ә киресе түгел. Галимнәр пәйгамбәрләрнең варислары, ә гыйбадәт кылучылар турында андый сүзләр әйтелмәгән. Гыйлем – ул Аллаһының сыйфаты».

Галимнәрнең гыйлемгә карата әйтеп калдырган шушы сүзләре гыйлемнең мөселман тормышында бик зур урын алып торганын күрсәтәләр.

## Гыйлем алуның Ислам динендәге хөкеме нинди?

Гыйлем алу хөкеме буенча кайбер вакытта фарыз гайн, ә кайбер вакытта фарыз кифәя булырга мөмкин. Гыйлемнең фарыз гаене ул – фарыз гамәлне дөрес үтәү өчен кирәк булган гыйлем. Бу төргә көндәлек дини гамәлләрне, гыйбадәтләрне кылырга ярдәм итүче гыйлем керә. Шәһадәт кәлимәсе, аның мәгънәсен аңлау, тәһарәт, намаз, ураза, зәкят, хаҗ, сәүдә, никах, талак, кебек гыйлемнәрне аның белән шөгыльләнүче һәр кеше өйрәнергә тиеш.

Фарыз кифая булган гыйлем – ул фарыз гаен гыйлеменнән тыш булган шәригать белемнәре яки дөньяви эшләрне алып барыр өчен ярдәм итә торган гыйлемнәр.

Кеше Аллаһыга дога кылганда һәрвакыт гыйлемен арттыруны сорарга тиеш. Аллаһы Тәгалә моны үзе куша:

وَقُلْ رَبِّ زِدْنِي عِلْما

**«Син әйт: «Әй Раббым! Миңа гыйлемне арттыр».**

«Та Һа», 20:114

Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Укытучының хакларыннан аңа күп сорау бирмәү, аны җавап бирә алмаслык авыр хәлдә калдырмау, арганын сизсәң үҗәтлек күрсәтмәү, торырга теләсә киеменнән тартмау, серен таратмау, аның янында бер кемне дә яманламау, ялгышуын теләмәү, әгәр дә ялгышса гафу итү, аны Аллаһының әмерен саклаганчыга хәтле хөрмәт итү, аның алдына утыру, әгәр дә берәр ярдәмгә мохтаҗ булса, иң беренче булып ярдәм итү һәм аны башка кеше синеңчә әйтмәде дип авыр хәлдә калдырмау».

Суфиян Әс-Сәүри (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын): «Гыйлем алган вакытта иң беренче эш – ул дәшмәү. Икенчесе гыйлем бирүчене игътибар белән тыңлау, өченчесе гыйлемне истә калдыру, дүртенчесе алган гыйлем нигезендә гамәл кылу һәм бишенчесе ул гыйлемне башка кешеләргә өйрәтү. Әгәр берәү шушы биш шартны үтәсә, камил гыйлем иясенә әверелер», – дигән.

Дүрт мәзһәб галимнәренең гыйлем алу рәвешләре белән танышыйк.

## Имам Әбү Хәнифә (Аллаһының аңа рәхмәте булсын)

Бу галим Аллаһыдан куркучы, күп гыйбадәт кылучы, гыйлеме белән Аллаһының ризалыгына омтылучы кеше була. Ул күп вакытта төне буе намаз укып чыга торган иде.

Әбү Хәнифә укытучысы Хәммәд бине Сөләйманга карата бик ихтирамлы иде. Шуңа күрә ул өендә утырган вакытта аягын укытучысы өенә таба сузмый торган була. Ул һәр намаз саен әти-әнисе белән беррәттән укытучысы өчен дә Аллаһыдан гөнаһларын гафу итүне сорый торган иде.

## Имам Мәлик (Аллаһының аңа рәхмәте булсын)

Ул кечкенә чагында эссе вакытта да, бик салкын вакытта да Ибне Зәһра исемле галимнең ишек төбендә гыйлем алу өчен көтеп тора торган була. Бу галим сукырайгач ул аны 7 ел буе өеннән мәчеткә алып бара.

Имам Мәлик хәдис сөйләргә утырса һәрвакыт тәһарәт ала, сакалын тәртипли, ислемай сибә торган иде. Ул җитди кыяфәт алганнан соң гына хәдис сөйли башлый. Аның шулай эшләвен бер кеше күреп шулай ди: «Ни өчен син шулай эшлисең?» Ул: «Мин шушы рәвешле Аллаһы Илчесенең сүзләрен зурларга телим», – ди.

Имам Мәлик әйтә торган була: «Гыйлем – ул нур, Аллаһы аны Үзе теләгән кешегә бирә , шуңа күрә гыйлем ул күп хәдисләр белү дә түгел».

Ул күп сорауларга «белмим», – дип җавап бирә торган була. Җитәкчеләрдән килгән бүләкләрне ул садака итеп бирә торган була.

## Имам Шәфигый (Аллаһының аңа рәхмәте булсын)

Ул укытучысы Имам Мәлик каршында китап битен ачса укытучысы ишетмәсен дип әкрен генә ача торган иде.

Имам Шәфигый төнне өч өлешкә бүлә торган була: бер өлешен гыйлемгә, икенче өлеше гыйбадәткә, ә өченче өлеше йокыга.

Рамазан аенда намаз эчендә Коръәнне 60 тапкыр укып чыга торган иде. Ул: «Уналты яшьтән бирле туйганчы ашаганым булмады», – дип әйткән. «Чөнки туйганчы ашау ул тәнне авырайта һәм йөрәкне катыландыра, зирәклекне юкка чыгара, йокыны китерә һәм кешене гыйбадәттән читләштерә. Мин Аллаһы белән бер кайчанда ант итмәдем», – дигән.

Шәфигыйнең укучысы Әр-Рабигъ: «Мин Шәфигыйгә хөрмәт күрсәтү йөзеннән аның каршында су эчмәдем», – дип әйткән.

## Имам Әхмәд (Аллаһының аңа рәхмәте булсын)

Имам Әхмәд әти-әнисе һәм укытучысы Шәфигый өчен 40 ел буена дога кылган дип хәбәр ителә. Әбү Гобәйд исемле галим әйтә: «Бервакытны мин Имам Әхмәднең хәлен белү өчен төрмәгә кердем, шул вакытны миннән бер кеше дини мәсьәлә хакында сорады, ләкин мин Имам Әхмәдкә ихтирам йөзеннән аңа җавап бирмәдем». Имам Әхмәд китапларның нөсхәсен язып акча эшли торган була. Әбү Давыд Имам Әхмәд турында шундый сүзләр әйтә: «Ул беркайчан да дөньяны искә алмый иде. Ул 40 ел буе фәкыйрьлеккә сабыр итте. Әгәр дә ул үзенә бирелгән бүләкләрнең бер өлешен алган булса иң бай кеше булыр иде. Моңа карамастан ул юмарт кеше булды, өч тапкыр җәяү хаҗ кылды».

Аллаһы Тәгалә барыбызга да бары тик файдалы белемнәр алырга гына насыйп итсә иде.

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

# Олы гөнаһлар

## Намазга игътибар итмәү

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَخَلَفَ مِن بَعْدِهِمْ خَلْفٌ أَضَاعُوا الصَّلَاةَ وَاتَّبَعُوا الشَّهَوَاتِ ۖ فَسَوْفَ يَلْقَوْنَ غَيًّا ﴿٥٩﴾ إِلَّا مَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ صَالِحًا فَأُولَٰئِكَ يَدْخُلُونَ الْجَنَّةَ وَلَا يُظْلَمُونَ شَيْئًا ﴿٦٠﴾

**«Ул пәйгамбәрләрдән соң явыз кавем килде, алар намазларын кичектереп, казага калдырып яки бөтенләй укымыйча заигъ иттеләр, вә шәһвәткә, нәфес теләгән нәрсәләргә иярделәр, алар тиздән Ахирәттә каты газапка очраучылардыр. Мәгәр иман китереп, тәүбә итеп төзәлеп, изге гамәлләр кылганнары җәннәткә керерләр, аларга хаксыз золым итү булмас».**

«Мәрьям», 19:59-60

Шулай ук:

فَوَيْلٌ لِّلْمُصَلِّينَ ﴿٤﴾ الَّذِينَ هُمْ عَن صَلَاتِهِمْ سَاهُونَ ﴿٥﴾

**«Ни үкенеч вә һәлакәтлек ихлассыз намаз укучыларга. Алар намазларыннан гафилләр, аны вакытында укымаслар, намазның рөкеннәрен хөрмәт кылмаслар, намазларының вакытыннан кичегүенә кайгырмаслар».**

«Магун», 107:4-5

Шулай ук Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә мондый аять тә китерә:

مَا سَلَكَكُمْ فِي سَقَرَ ﴿٤٢﴾ قَالُوا لَمْ نَكُ مِنَ الْمُصَلِّينَ ﴿٤٣﴾

**«Сезне сакар җәһәннәменә нәрсә салды, нинди сәбәп белән анда кердегез?» Сакардагы кешеләр әйтерләр: «Без намаз укучылардан түгел идек».**

«Мүддәссир / Бөркәнүче», 74:42-43

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: Алар белән безнең аерма – ул намаз. Кем дә кем намаздан баш тартса, имансызлыкка чыга»[1], – дип әйткән.

Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм имам Бохари хәдисләр җыентыгында килгән түбәндәге хәдисне әйтеп калдырган: «Икенде намазын укымыйча калдырган кешенең гамәлләре юкка чыгарылачак».

Имам Мөслим хәдисләр җыентыгында түбәндәге хәдис китерелә: «Намаз – ул имансызлыктан каплап тора торган пәрдәдер».

«Аллаһы Тәгалә намазларын үз теләге белән калдыра башлаган кешене саклаудан, яклаудан туктый»[2].

Гомәр Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Намазын кадерсезләгән кешенең ислам белән уртаклыгы юк», – дип әйтә.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләрен җиткерә: «Мөселман кешедән Кыямәт көнендә иң беренче соралачак нәрсә – ул аның намазы. Әгәр дә ул аны тиешенчә үтәгән булса, аны котылу көтә, шулай булмаганда исә (тиешенчә үтәлмәгән очракта), ул өметен югалтачак һәм аны канәгатьсезлек көтәчәк»[3].

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләрен җиткерә: «Намазын кадерсезләгән кешенең нуры да, дәлилләре дә, котылу чарасы да калмая-

---

1 Имам Тирмизи, имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

чак. Кыямәт көнендә андый кеше Карун, Фиргавен, Һаман һәм Гобәй бине Хәләф белән янәшә булачак»[1].

Бу кешеләр янында басып тору – намаз укымаучының имансызлыкка никадәр якын булуын да күрсәтә. Әмма пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Могаз радыяллаһу ганһегә түбәндәге сүзләрен әйтә: «Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк икәнлегенә һәм Мөхәммәд – Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре икәненә ихлас күңелдән гуаһлык (шаһитлык) китергән һәрбер кешегә Аллаһы Тәгалә җәһәннәмдә булырга юл куймас».

Намазны вакытында кылмау яки аннан баш тарту, караклык яки зина кылу – зур гөнаһлар. Әгәр дә кеше намаздан үз теләге белән берничә тапкыр баш тартса, зур гөнаһлы булачак. Әгәр бу дәвамлы булса һәм кешенең гадәтләренең берсенә әйләнсә, әлбәттә, фасыйк һәм залимнәрдән булыр иде.

## Зәкят түләмәү

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قُلْ إِنَّمَا أَنَا بَشَرٌ مِّثْلُكُمْ يُوحَىٰ إِلَيَّ أَنَّمَا إِلَٰهُكُمْ إِلَٰهٌ وَاحِدٌ فَاسْتَقِيمُوا إِلَيْهِ وَاسْتَغْفِرُوهُ ۗ وَوَيْلٌ لِّلْمُشْرِكِينَ ﴿٦﴾ الَّذِينَ لَا يُؤْتُونَ الزَّكَاةَ وَهُم بِالْآخِرَةِ هُمْ كَافِرُونَ ﴿٧﴾

**«Син аларга әйт: «Мин дә сезнең кебек үк бер адәм баласымын, ләкин миңа Аллаһыдан вәхи киләдер, сезнең Илаһыгызның ялгыз бер генә Аллаһы икәнлеге белән, Аңа чын иман китереп туры итагать итүче булыгыз, һәм тәүбә итеп, Аннан гафу сорагыз! Мөшрикләргә – һәлак булудыр. Ул мөшрикләр зәкят бирмәсләр вә алар Ахирәт көненә ышанмаслар».**

«Фүссиләт / Аңлатылды», 41:6-7

[1] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَالَّذِينَ يَكْنِزُونَ الذَّهَبَ وَالْفِضَّةَ وَلَا يُنفِقُونَهَا فِي سَبِيلِ اللَّهِ فَبَشِّرْهُم بِعَذَابٍ
أَلِيمٍ ﴿٣٤﴾ يَوْمَ يُحْمَىٰ عَلَيْهَا فِي نَارِ جَهَنَّمَ فَتُكْوَىٰ بِهَا جِبَاهُهُمْ وَجُنُوبُهُمْ
وَظُهُورُهُمْ ۖ هَٰذَا مَا كَنَزْتُمْ لِأَنفُسِكُمْ فَذُوقُوا مَا كُنتُمْ تَكْنِزُونَ ﴿٣٥﴾

**«Янә бар шундый кешеләр: алар алтын вә көмешне җыеп асрарлар, Аллаһы юлына һич тә бирмәсләр, аларга рәнҗетә торган газап булачагы белән хәбәр бир. Кыямәт көнендә җыйган ул алтын-көмешләре җәһәннәм утында кыздырылып маңгайларына, вә кабыргаларына, вә аркаларына басылыр һәм әйтелер: «Болар дөньяда вакытта үзегез өчен асраган алтын вә көмешләрегез. Инде саранлык белән җыеп саклаган малыгызның газабын татыгыз».**

«Тәүбә», 9:34-35

Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам болай дип әйткән:

«Дөя, сыер яки сарык иясе булган берәр кеше аларга карата тиешле мөгамәләдә булмаса, Кыямәт көнендә тигез һәм иркен урынга утыртылачак. Алар (ул хайваннар) бу кешене тояклары белән таптаячаклар, мөгезләре белән сөзәчәкләр һәм тешләячәкләр. Шулай ук көтүе белән дөяләр дә аның өстеннән йөриячәк. Аның өстеннән дөяләрнең соңгысы узгач, кабаттан беренче дөя кайтарылыр. Һәм бу хәл дәвамлыгы 50 мең ел булган Кыямәт көне беткәнче дәвам итәр. Шуннан соң аңа йә җәннәткә, йә җәһәннәмгә юл күрсәтеләчәк»[1].

«Әгәр хәзинәләре булган кеше аларга карата тиешлесен үтәмәсә[2], Кыямәт көнендә бу байлыклар аның алдында бик зур елан булып киләчәк»[3].

---

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан; хәдиснең бер өлеше.

[2] Зәкят чыгармаса, садака итеп бирмәсә (ред.).

[3] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе зәкят түләүдән качып йөрүчеләр белән көрәшә торган булган һәм болай дигән:

«Аллаһы Расүленә биргән кебек, ул кешеләр миңа бер кәҗә генә булса да бирергә теләмәсәләр, мин алар белән шуның аркасында да көрәшермен»[1].

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَلَا يَحْسَبَنَّ الَّذِينَ يَبْخَلُونَ بِمَا آتَاهُمُ اللَّهُ مِن فَضْلِهِ هُوَ خَيْرًا لَّهُم ۖ بَلْ هُوَ شَرٌّ لَّهُمْ ۖ سَيُطَوَّقُونَ مَا بَخِلُوا بِهِ يَوْمَ الْقِيَامَةِ ۗ وَلِلَّهِ مِيرَاثُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ ۗ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ ﴿١٨٠﴾

**«Аллаһы рәхмәт итеп биргән малда саранлык кылучы кешеләр шул саранлыклары үзләренә файда, дип уйламасыннар. Бәлки саранлыклары үзләренә начарлыктыр, саранлык белән җыйган маллары тиздән Кыямәт көнендә муеннарына чорналыр. Җирдәге вә күкләрдәге байлык Аллаһыныкы, һәм Аллаһы кылган эшләрегездән хәбәрдар».**

«Әле Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:180

Пәйгамбәребез мондый очракларда болай дип әйтә торган булган: «Зәкят бирүдән баш тарткан кешеләрдән зәкятне дә, малларының яртысын да алырмын. Бу – Аллаһы Тәгаләнең хокукларының берсе».

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Аллаһы Илчесе галәйһиссәламнең түбәндәге сүзләрен ишеткән: «Җәһәннәмгә беренче булып түбәндәге өч төркем керәчәк:

– үз халкына золымлык кылган хөкемдар;

– милкенә карата тиешлесен үтәмәгән кеше[2];

– тәкәббер фәкыйрь».

---

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

2 Зәкятен чыгармаган (ред.).

**Ата-ананы хөрмәтләмәү**

وَقَضَىٰ رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا ۚ إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِندَكَ الْكِبَرَ
أَحَدُهُمَا أَوْ كِلَاهُمَا فَلَا تَقُل لَّهُمَا أُفٍّ وَلَا تَنْهَرْهُمَا وَقُل لَّهُمَا قَوْلًا كَرِيمًا
﴿٢٣﴾ وَاخْفِضْ لَهُمَا جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُل رَّبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا
رَبَّيَانِي صَغِيرًا ﴿٢٤﴾

**«Аллаһы фәкать Аллаһыга гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә хөкем итте вә әмер бирде. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» та димә, вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә! Вә аларга шәфкать итеп, рәхим канатларыңны җәй! Вә әйт: «Ий Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм Ахирәттә шәфкатьле бул!»**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:23-24

وَوَصَّيْنَا الْإِنسَانَ بِوَالِدَيْهِ حُسْنًا ۖ وَإِن جَاهَدَاكَ لِتُشْرِكَ بِي مَا لَيْسَ لَكَ بِهِ
عِلْمٌ فَلَا تُطِعْهُمَا ۚ إِلَيَّ مَرْجِعُكُمْ فَأُنَبِّئُكُم بِمَا كُنتُمْ تَعْمَلُونَ ﴿٨﴾

**«Без кеше затына ата вә анага изгелек итәргә әмер бирдек. Әгәр ата һәм анаң син Аллаһы дип танымаган Аллаһыдан башка бернәрсәгә гыйбадәт кылырга чакырсалар гына, ул вакытта аларга итагать итмә. Кайтарылуыгыз Миңа бит, шулвакытта кылган эшләрегездән хәбәр бирермен».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:8

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм җиде зур гөнаһларны санаганда, алар арасында ата-ананы хөрмәтләмәүне дә искә алды».

Шулай ук Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте – атаның рәхмәтендә, ә Аның ачуы – атаның ачуында ята», – дип әйтә.

Шулай ук Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый хәдис әйтеп калдырган: «Әтиеңә карата булган яхшы мөнәсәбәтең җәннәткә иң яхшы ишек аша керергә сәбәпче булачак. Аның (әтиеңнең) хокукларын үтәргә тырышып, бу ишек аша узуың яки аларны үтәмичә, хакларын кысрыклап, аңа (шул ишеккә (ред.)) юлны югалтуың хәзер сиңа гына бәйле».

Шулай ук ул: «Җәннәт – әниләрнең аяк астында» [1], – дип әйткән.

Берьюлы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер сәхабә килеп, җиһадта катнашырга рөхсәт сораган. Расүлебез галәйһиссәлам аннан:

– Синең әти-әниләрең исәнме? – дип сораган.

Теге сәхабә:

– Әйе – дип җавап биргән.

Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аларны тәрбияләү синең җиһадың булсын» [2], – дигән.

Бервакыт Расүлебездән, кемгә карата яхшы мөнәсәбәттә булырга кирәк, дип сораганнар. Ул: «Әнигә, әтигә, кыз туганыңа, ир туганыңа,

---

1 Хәдиснең нәкъ менә шушындый варианты табылмаган. Әмма моның кебек хәдис Эн-Нәсаинең «Сөнән Эн-Нәсаи» җыентыгында килә. Берьюлы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына Җәһимә исемле сәхабә килеп сугышта катнашырга рөхсәт сорый. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан: «Синең әниең бармы?», – дип сораган. Теге сәхабә: «Әйе», – дип җавап бирә. Шуннан соң Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әниеңә хезмәт ит һәм җәннәтне аның аяк астыннан табарсың», – дип әйтә. «Сөнән Эн-Нәсаи» 6/11.

2 Бохари, Китап-Әл-Җиһад, 3004; Мөслим Китап-Әл-Бирр, 2549; Тирмизи 1671.

синең өчен иң якын булган кешегә һәм туганлык буенча чираттагы иң якын кардәшеңә»[1], – дип җавап биргән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләре риваять ителә:

«Түбәндәге кешеләр җәннәткә кермәячәк: ата-анасын хөрмәтләмәүче, кылган яхшылыгы белән шелтәләүче, исерек кеше һәм сихергә ышанучы»[2].

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе, Расүлебез галәйһиссәлам янына бер кеше килеп, йә, Аллаһының Илчесе, нинди гөнаһлар иң зурлардан санала, дип сораганын хәбәр итә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам:

– Аллаһыга ширек кылу, – дип җавап биргән.

Теге кеше:

– Тагын нинди гөнаһ? – дип сораган.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам:

– Ата-ананы тыңламау, – дигән.

Сорау бирүче, болардан соң нинди гөнаһлар, дигән.

Расүли Әкрам:

– Ялган ант, – дип җавап кайтарган.

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребезнең түбәндәге сүзләрен китерә:

«Ата-анасын олыламаучы һәм тәкъдирне кире кагучы җәннәткә кермәс»[3].

Бер кеше Расүлебез галәйһиссәламнән: «Йә, Аллаһы Илчесе! Әгәр мин биш вакыт намаз укысам, Рамазан аенда ураза тотсам, зәкят түләсәм, Аллаһы йортын – Бәйтуллаһны зиярат кылсам, син миңа нәрсә эшләргә

1 Мөслим Китап-Әл-Бирр, 2548;Ән-Нәсаи, 5/61; Ибне Мәҗе, 3658.

2 Ән-Нәсаи, Китап-Әл-Әшрибе, 8/318; Әхмәд бине Хәнбәл 3/314.

3 Әхмәд бине Хәнбәл, 2/441.

әмер итәрсең?» – дип сораган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Әлеге шартларны үтәүче һәм ата-анасын хөрмәтләүче – пәйгамбәрләр, әүлиялар һәм шәһитләр белән булачак» , – дип җавап биргән.

Аллаһының Илчесе болай дигән:

«Аллаһы Тәгалә гөнаһлар өчен җәза бирүне Кыямәт көненә хәтле кичектерер. Әмма ата-ананы хөрмәтләмәгән өчен җәзаны тиз арада, ашыгыч рәвештә бирәдер»[1].

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе: «Бер генә бала да атасына булган рәхмәтен җиткереп бетерә алмый. Бары тик әгәр ул аны әсирлектә табып, коткарса гына рәхмәтен әйтеп бетергән булып санала» [2], – дип әйткән.

Расүлебез галәйһиссәлам: «Ата-анасын олыламаучыны Аллаһы ләгънәт кылсын» [3], – дигән.

Шулай ук Пәйгамбәребез: «Апаң (әниеңнең кыз туганы) синең өчен әниең кебек» [4], – дигән.

Кәгъб болай дигән:

«Аллаһы белән ант итәм: әгәр кеше ата-анасына каршы барса, Аллаһы аны юкка чыгарырга һәм җәзага тартырга ашыгыр. Ә ата-анасына яхшы мөнәсәбәттә булучының Аллаһы гомерен озынайтыр һәм яхшы гамәлләрен арттырыр».

---

1 Хәким, Мүстәдрәк, Китап-Әл-Бирр вәс-Силә, 4/156.

2 Мөслим, Китап-Әл-Гыйтк, 1510; Әбү Давыд, Китап-Әл-Әдәп, 5137; Тирмизи, Китап-Әл-Бирр Вәс-Силә, 1907.

3 Хәким, Мүстәдрәк, 4/153.

4 Тирмизи, Китап-Әл-Бирр вәс-Силә, 1905.

## Риба

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَذَرُوا مَا بَقِيَ مِنَ الرِّبَا إِن كُنتُم مُّؤْمِنِينَ
﴿٢٧٨﴾ فَإِن لَّمْ تَفْعَلُوا فَأْذَنُوا بِحَرْبٍ مِّنَ اللَّهِ وَرَسُولِهِ ۖ وَإِن تُبْتُمْ فَلَكُمْ
رُءُوسُ أَمْوَالِكُمْ لَا تَظْلِمُونَ وَلَا تُظْلَمُونَ ﴿٢٧٩﴾

**«Ий мөэминнәр, Аллаһыдан куркыгыз, Аның хөкемнәрен бозудан сакланыгыз! Алырга сөйләшкән рибаларыгыз алынмый калган булса, рибаны харам кылган аять килгәннән соң, ул сөйләшкән рибаларыгызны алмагыз, Аллаһыга гөнаһкяр булудан сакланыгыз! Әгәр Коръән белән гамәл кылучы хак мөэмин булсагыз. Әгәр риба белән мал алудан туктамасагыз, ул вакытта яхшы белегез! Аллаһының һәм Расүлнең сезгә каршы сугышуларын үзегезгә лязем иткән буласыз. Арттырып алу өчен бурычка бирүчеләр әгәр тәүбә итсәгез, бурычка биргән малыгыз сезнеке, биргәнегез хәтле генә алыгыз. Бурычка биргән кеше арттырып алу белән золым итмәсен һәм бурычны киметеп бирү белән бурычка бирүчегә дә золым ителмәсен».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:278-279

الَّذِينَ يَأْكُلُونَ الرِّبَا لَا يَقُومُونَ إِلَّا كَمَا يَقُومُ الَّذِي يَتَخَبَّطُهُ الشَّيْطَانُ مِنَ
الْمَسِّ ۚ ذَٰلِكَ بِأَنَّهُمْ قَالُوا إِنَّمَا الْبَيْعُ مِثْلُ الرِّبَا ۗ وَأَحَلَّ اللَّهُ الْبَيْعَ وَحَرَّمَ الرِّبَا ۚ
فَمَن جَاءَهُ مَوْعِظَةٌ مِّن رَّبِّهِ فَانتَهَىٰ فَلَهُ مَا سَلَفَ وَأَمْرُهُ إِلَى اللَّهِ ۖ وَمَنْ عَادَ
فَأُولَٰئِكَ أَصْحَابُ النَّارِ ۖ هُمْ فِيهَا خَالِدُونَ ﴿٢٧٥﴾

**«Риба ашаучылар, ягъни бурычка биреп торган өчен арттырып алучылар, каберләреннән, шәйтан буып ташлаган кеше кеби, бик яман сурәттә кубарлар. Бу газаб аларга тиешле булды, риба сәүдә кебек хәләл дигәннәре өчен. Аллаһы сәүдә эшләрен хәләл итте, риба эшләрен харам кылды. Берәү, рибаның харам икәнлеге белән Раббысыннан вәгазь килгәннән соң риба алудан тыелса, вәгазь килмәс борын алган рибасы үзенә хәләлдер. Вәгазьгә хәтле риба алучыларның эше Аллаһыга тапшырылыр. Бу аять иңгәннән соң да рибаны хәләл санап, алуларын дәвам итсәләр, алар ут әһелләре. Алар анда мәңге калырлар.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:275

Күргәнебезчә, югарыда искә алынган аятьләр һаман да процентлар белән яшәүчеләргә кисәтү һәм җәһәннәм белән куркыту булып тора. Пәйгамбәребез түбәндәге гөнаһлардан сакланырга кушкан:

– Аллаһыга ширек кылу;

– сихер;

– процентлар белән яшәү (риба);

– ятим малын ашау;

–яу кырыннан качу;

–гаепсез мөслимәгә яла ягу[1].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Аллаһы риба белән шөгыльләнүчеләрне һәм алардан акча алучыларны ләгънәт кыла»[2].

Тирмизи хәдисләр җыентыгында бу хәдиснең дәвамы бар: «...ялганчыны һәм ялган шаһитлык кылучыны»[3].

---

1 Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Мөслим, Китап-Әл-Мусакат, 1547.

3 Тирмизи, Китап-Әл-Буйгу, 1267.

Əн-Нəсаи Расүлебез саллəллаһу галəйһи вə сəлләмнең түбəндəге хəдисен китерə: «Аллаһы Тəгалə риба белəн шөгыльлəнүчене, риба белəн шөгыльлəнүчедəн акча алучыны һəм боларны язып баручыны лəгънəт кылды».

*Имам Əз-Зəһəбинең «Əл-Кəбаир» китабыннан»*

# Әдәби сәхифә

# Күгәрчен оя корганда

Нургөл соңгы вакытларда Райнурның бик еш кына тамак төбен кырып йөрүенә игътибар итә башлады. Көннәрдән беркөнне түзмәде, үзенә дә әйтте.

— Бугаз төбе кычытып китә. Тамак кырганга да бәйләнмә әле, хатын, – дип ире аның сүзен уенга борды.

Нургөл аның бу гадәтенә күнегергә мәҗбүр булды. Дөресрәге, балалар җитешкән саен тормыш мәшәкатьләре дә арта. Башта Гөлназ кияүгә чыкты. Икенче елны Илназ өйләнде.

Өч бүлмәле йортта ир белән хатын гына торып калды. Үз-үзләрен: “Һәркемнең үз гаилә учагы булырга тиеш. Яраткан иренә һәр хатын-кызның ашны үзе пешереп ашатасы килә. Кем белән гаилә корганнар, гомер азагына кадәр шуның белән яшәсеннәр”, – кебек сүзләр белән юаттылар.

Кичләрен икесе дә эштән арып-талып кайтып, диванда бер-берсенең тән җылысын тоеп утыралар. Нургөл иплəп кенə мең дә беренче кабат бер үк сүзләрне кабатлый:

— Райнур, сөеклем, үтенеп сорыйм, барыйк инде хастаханәгә. Болай гел тамак төбе кырып йөрү дөрес хәл түгелдер. Чәчләрең ап-ак булды.

— Ирләрнең чәче илле биштә чалара инде, егет чаклар күптән узды. Тамак кыру нервалар какшаганнан, – дип җавап кайтарды.

— Үзең өчен түгел, алайса, әйдә, минем күңелем тынычлыгы өчен бар. Тәнзилә Нәбиевна дигән бик яхшы психотерапевтның адресын бирделәр, бөтен кешенең чирен күзенә карап әйтеп бирә ди, күренеп кайтыйк, – дип ялварды Нургөл.

Райнур ризалашты. Нургөл табибка телефон аша шалтыратып, төштән соң сәгать икегә чиратка язылды. Табиб эшли торган поликлини-

ка Камал театры янында булып чыкты. Тәнзилә Нәбиевна аларны якты йөз белән каршы алды:

— Әйдәгез, бергәләп яшел чәй эчеп алыйк, ул башны сафландырып җибәрә, – дип киеренкелекне йомшартып җибәрде. Аннары кулындагы приборын Райнурга таба каратып сөйли башлады.

— Кайгырганга карап кына тәкъдир үзгәрми, язмышыңа язылган булмый калмый. Әгәр гөнаһ кылсаң – тәүбә ит, ялгышлык эшләсәң – гафу үтен, хаталансаң – төзәл. Рәхмәт киң, ишек ачык, тәүбә кабул булыр. Дөньяда яшәгәндә төрлесе була: күңел төшенкелегенә биреләсең, олы кайгылар кичерәсең, мин фәкыйрь яки авыру дип уфтанасың. Әмма җирдә яшәүнең Ходай каршында сынау тотуыбыз, игелекле кеше булып калуыбызга имтихан икәнлеген онытмаска кирәк. Күрәм, сезнең күңелегез тыныч түгел, кайгырасыз. Тормыш шулай корылган: кемдер сызланудан зарлана, ә кайберәүләрнең гомерләре ятакта уза. Нинди генә хәлдә булсаң да, изгелек кылудан туктама, чөнки кеше бәхетенә юл шулдыр. Кайгырма, кайгы дошманны сөендерә, дустыңның күңелен төшерә, синнән көнләшүчеләргә шатлык өсти һәм хак булган нәрсәләрне сиңа үзгәртеп күрсәтә. Артыгын борчылырга ярамый, чөнки һәркемнең ике яше бар: берсе паспорт буенча билгеләнә, икенчесе – биологик яше. Сез яшь кеше түгел, – диде Райнурга төбәлгән кулындагы приборына карап.

— Ничек инде, доктор, миңа әле илле биш кенә яшь бит.

— Әйтәм бит, паспортындагы яшең буенча шулай, сезнең биологик яшегез сиксәннән узып бара. Муеныгыздагы шешегез нерв системагызның тузуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Райнур белән Нургөл бер мәлгә югалып калды. Телләрен чак-көч тибрәтеп:

— Зыянлы шешме ул, дәвалап була торганмы? – дип сорадылар.

— Анысын онкологлар әйтер.

— Начар чир дип әйтергә теләмисездер бит, доктор?

— Мондый авырулар күп очракта эчке халәтен дөрес аңлап яши белмәгән кешеләрдә барлыкка килә. Хөсетле, мәкерле кешеләр белән көрәшеп яшәү дә чир булып урнаша. Сез җитәкче булып эшлисезме?

Райнур “әйе” дигәнне аңлатып башын какты.

Доктор яныннан чыккач:

– Әйдә, баштагы авыр уйлардан да котылырбыз,

театрга керик әле, – дип, Нургөлне култыгыннан алды. Алар әкрен генә театр кассасына килделәр.

– Иң яхшы урыннарга ике билет бирегез әле, – диде Райнур.

– Кайсы спектакльгә?

– Менә хәзер башлана торганына, – дип, кесәсеннән акчасын чыгарып, кассирга сузды.

– Билетлар юк бит, абый.

– Тап, сеңлем, бәлки минем театрга соңгы килүем булыр.

Кассир аңа гаҗәпләнеп карап куйды да ике билет сузды.

...Спектакль башланды. Нургөл артистларның тавышларын гына ишетте. Ул күз чите белән иренең һәр хәрәкәтен күзәтте. Райнур әле кулының учы, әле бармаклары белән муенын сыпырып карый. Алар ничек кирәк алай, спектакльнең ахырына кадәр утырдылар. Башка вакыт булса, театр ишегеннән чыгуга, фикер алыша башларлар иде. Бүген әллә ничек, икесе дә үзләрен артык сүз сөйләшүдән тыеп торалар. Ир белән хатын керфеккә-керфек какмый төн уздырды.

Иртән онкология хастаханәсенә килделәр. Бәхеткә каршы, чиратта кеше күп түгел иде. Райнурны табиб карады да кан анализлары тапшырырга кушты. – Соңарып килгәнсез, химия белән дәвалап карарбыз, – диде. Табиб сүзләре Райнурның өстенә салкын су сипкәндәй тәэсир итте.

— Доктор, гафу итегез, безнең бу айда ашыгыч рәвештә тапшырасы обьектларыбыз бар. Мин хастаханәдә ятып дәвалана алмыйм, йөреп кенә алып булмыймы?

– Булмый, сез чирегезне аздыргансыз. Үзегезнең тән авырлыгыгызны югалта баруыгызны сизмисезме?

– Эш күп бит, доктор. Шуңа ябыгам дип уйлыйм.

– Хикмәт бөтенләй башкада, сезгә бүгеннән дәвалана башларга кирәк, Хәкимов, – дип үгетли торгач, Райнур ризалашты. Нургөл ирен палатага озатып куйды.

– Хәзер кирәк-яраклар белән ашарга алып киләм, – дип, урамга атылып чыкты да хастаханә каршындагы эскәмиягә утырып кычкырып елап җибәрде.

– Нургөл ханым,– дигән тавышка башын күтәрде. Каршында иренең шоферы басып тора.

– Утырыгыз, кайтарып куям.

– Рәхмәт, – дип арткы утыргычка узды. Башын уйлатырга тырышып карый, булдыра алмый. Әйтерсең лә, күсәк белән сугып аңгырайттылар. Үзенең җаны белән бер күргән Райнурының онкология хастаханәсендә химия белән дәвалануы хатынның аңын томалады. Өй каршыларына кайтып җиткәч, машинадан үз гәүдәсен чак-көч сөйрәп алды. Бөтен тәненә авыр тимер аскан кебек тоелды.

Өйгә кергәч, кухняның тәрәзә форточкасын ачты. Аннан ургылып салкын һава керде. Нургөл телефоннан шалтыратып, балаларына хәбәр итте. Онкология хастаханәсендә дип әйтергә теле әйләнмәде, баргач, күрерләр дип уйлады. Бер сәгать дигәндә, Гөлназ белән Илназ кайтып җитте. Алар килгәндә, Нургөл хастаханәгә алып барасы әйберләрне төйнәп куйган иде. Газ өстендә пилмән пешә. Балаларының йөрәген артык авырттырмый торган итеп ничек әйтәсе? Ул сүзләр эзләгәндә, улы белән кызы аны сорауларга күмделәр. Теленә килгән беренче сүз:

– Әтиегез җитди авырый, балалар. Объектларны төзеп тапшыру срогына сыешырга кирәк дип ашкынып йөри-йөри саулыгын кайгыртырга вакыты булмады. Менә хастаханәдә ятып, үзен ремонтлап алырга кирәк

дип уйлады. Әйдәгез, янына барыйк, әтиегезгә бирешергә юл куймыйк. Ничек булдыра алабыз, шулай ярдәм итик, – диде.

Машина онкология хастаханәсе каршында туктагач, Гөлназ белән Илназның йөзләре үзгәрде, әмма кайтарып сорау бирмәделәр, эчтән генә тындылар.

Палатага килеп кергәч, Гөлназның күзеннән энҗе бөртекләре тәгәрәшә башлады.

– Зинһар өчен, елый күрмәгез. Авыртмас сөяк булмас, менә күрерсез, ун көннән чыгам мин, – диде әтиләре.

– Син арыдың, кадерлем. Кеше ат түгел бит. Күп җиксәң, хәтта ат та йөгенә. Сиңа ял кирәк, кадерлем. Моннан чыккач, санаторийга барырсың, – дип алып килгән әйберләрне бушатты.

– Ярар, – дип Райнур баш какты.

Аларның палатадан чыгуларын ишек төбендә табиб көтеп алды. Ул җайлап кына, Райнурның авыруының җитди булуын, барысына да әзер торырга кирәклеген аңлатты. Табибның бу сүзеннән соң аяклары хәлсезләнеп, ава башлаган әниләрен, балалары тотып калды.

– Нургөл Солтановна, сез – көчле хатын-кыз, һәр укучыны тигез күреп укыткан чын укытучы. Мин көчемнән килгәннең барысын да эшләргә әзер, – диде табиб.

– Мин сезне укыттыммы әллә, доктор?

– Әйе, мин – Әнис Җамалиев. Хатыным Балыклы авылы кызы Гөлйөзем, ул да сезнең укучыгыз.

Әлеге җавап Нургөлнең күңеленә нур булып агылды. Күзен тутырып Әнискә төбәлде. Сагыш тулы күңелгә укучылары өчен куану хисе уралды. Әнис аны иңеннән кочып, ишек төбенә кадәр озатып куйды.

...Нургөл иртә-кич әнисенең дини китапларын актарды, укыды, догалар өйрәнде. Аллаһыдан ирен алмавын сорап ялварды. Сәҗдә кылып сорасаң, кабул була дип укыды да, намаз тәртипләрен өйрәнеп, биш ва-

кыт намазын укый башлады, башына яулык япты. Барысын да эшләргә риза, тик аның Райнуры гына янәшәсендә булсын. Ансыз тормышны ул төннәрен күктәге айсыз, көннәрен кояшсыз күз алдына китерә.

Тыштан тыныч булып күренергә тырышса да, Райнур үзенә үлем якынлашканын аңлады. Палатадашы язучы Галим абыйдан:

– Сез миңа үз-үземне үлемгә әзерләргә ярдәм итә торган берәр төрле китап бирә алмыйсызмы? – диде.

– Монда барысы да аңлаешлы итеп язылган, энекәш, – дип мөгаллим аңа ручка белән кулдан язылган дәфтәр сузды. «Кеше дөньялыкта яшәгәндә байлык җыя, мал туплый. Кайберәүләр хәтта Ахирәткә барасыларын да онытып яшиләр. Ә ул көн һәркемгә килә. Мәрхүмне соңгы юлга туганнары, дуслары озата бара. Гүргә иңдереп, каберенә туфрак салгач, алар кайтып китә. Кеше дөньялыкта яшәгәндә кылган яхшы һәм начар гамәлләре белән берүзе калып, Аллаһы каршында җавап тота. «Бәндәләр шул чакта тормышның мәгънәсен аңлап яшәмәүләренә бик үкенерләр» диелгән китапларда. Менә болар барысы да безнең дини кануннарны белмәвебездән килә. Чөнки кешеләр дин тоту, динле булу кебек сүзләрдән ни өчендер сагаеп калалар, шомланалар төсле. Шуңамы, мәктәптә дин белеме укытылмый, Ислам мәдәнияте өйрәтелми.

Югыйсә, Ислам өйрәтмәләре үзе бер университет бит. Динле булуны иманлы булу дип аңламыйбызмы? Дин белән иман сүзе янәшә тора. Ә иман әхлакны, намусны, ышанычны, тугрылыкны, вәгъдәле булуны белдерә. Бездә «вәгъдә – иман», дигән гыйбрәтле төшенчә бар. Ә вәгъдәсез кешене имансыз кешегә тиңләгәннәр. Фәнис Ярулинның Ринат Галиевка багышланган бу турыда хәтта шигыре дә бар:

Яманлыкны күрми башлар идек,
Әзме аңа күнегеп беткәннәр —
Ярый әле табылып тора җирдә
Күңелендә иман йөрткәннәр, – дип яза ул.

Шулай булгач, динле һәм иманлы, ягъни вәгъдәле, ихлас дигән сүз. Рәхимле һәм намуслы булудан куркырга кирәкми. Иманы нык булган кеше усаллыктан, рухи түбәнлектән, кыргыйлыктан, әхлаксыз гамәлләр эшләүдән ерак тора. Ислам галиме Сәид Нурсиның бик гыйбрәтле мондый сүзләре бар: «Вөжданның зыялыгы дин гыйлемнәре белән, ә акылның нуры фән гыйлемнәре белән яктыртылыр. Икесенең бергә берләшүеннән акылда һәм күңелдә хакыйкать барлыкка килер. Әгәр дин гыйлеме үзе генә укытылса, фанатизм барлыкка килә, фән гыйлеме генә укытылса, иман хакыйкатьләреннән шикләнү һәм бик күп начарлыклар туа. Киләчәктә уку йортларында дин һәм фән гыйлемнәре бергә укытылсын», – дигән. Мондагы сүзләрнең хаклыгын бүгенге тормышыбыз дәлилләп, раслап тора. Бүгенге әхлаксызлык, бозыклык, рәхимсез мөнәсәбәт, фахишәлек, исереклек иман хакыйкатьләренә шикләнеп караудан, ышанмаудан килә. Ә ышаныч юлы, таяныр терәк – Коръән кушканча яшәү. Яшьләребез шушы юлга чыга алмыйча, мәгънәле һәм матур тормышка өметләрен югалта барып, наркоманлык, бозыклык юлына китә. Чөнки начар нәрсә тизрәк кабул ителә. Мәктәптә балаларга түбән сыйныфтан ук ислам әхлагы өйрәтелсә, аларның рухлары нык булыр, күңелләренә бозык хисләр салына алмас иде.

Укытучыларыбызга файдаланыр өчен әзер китап та бар. Халкыбызны бертуктаусыз иманга, гыйлемгә өндәп яшәгән галимнәребез арасында, фикерләренең тирәнлеге, фәлсәфилеге белән сокландырган, иман юлында нык торып, милләтебезгә хезмәт иткән олуг остазыбыз Риза Фәхретдиннең «Җәвамигуль кәлим шәрхе» китабы, балаларыбызга әхлак тәрбиясе бирүдә дә ярдәмлек безнең өчен. Татар дөньясында тиңе булмаган, рухи хәзинә булып саналган әлеге китап 1917 елдан бүгенге көнгә кадәр гарәп илләре уку йортларында дәреслек итеп укытыла. Ниһаять, 1995нче елда ул кириллица хәрефләре белән татар телендә дә басылып чыкты. Бу гаҗәеп хезмәтендә күренекле философ Расүлебезнең хакыйкый

хәдисләрен тирән һәм оста итеп шәрехләп бирә. Китапны пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безнең өчен калдырган дөрес яшәү кагыйдәләре дип тә аңларга була. Шушы китабында Р.Фәхретдин педагогик, иҗтимагый, әхлакый мәсьәләләрне күтәрә. Укучының яшәү мәгънәсе турындагы фикерләрен тирәнәйтә, тормыш авырлыкларын җиңеләйтергә, бозык теләкләрне юкка чыгарырга, төшенке күңелләргә шатлык китерергә, рухны сафландырырга ярдәм итә. Балаларыбызны тәүфыйкълы, әдәпле һәм мәрхәмәтле итеп күрергә теләсәк, бу китап белән һәрберебез танышырга, аны укып өйрәнергә тиешбез.

Бу шулкадәр зур көчкә ия китап ки, андагы фикерне аңыбызга урнаштыра алсак, без бәхетлерәк, сәламәтрәк яшәрбез. Харам хисләр күңелебездән китәр, бер-беребезгә мөнәсәбәтебез җылыныр, сабырлыгыбыз артыр, һәркем уйланыр. Кемнәрдер буш сүз сөйләп гомер уздыруларын аңлар һәм башка мәгънәле фикерләр белән акылын баетыр. Китаптагы кайбер хәдисләр белән таныштырып китәргә дә кирәктер.

Икейөзлелек галәмәте өчтер: икейөзле кеше сүз сөйләсә – ялганлар, вәгъдә бирсә сүзендә тормас, үзенә тапшырылган әманәткә хыянәт итәр. Ялган сөйләү күңел бозыклыгыннан килә. Кешеләр аңа күбрәк яшь вакытларында өйрәнәләр. Соңыннан күңелләрендә гадәт булып урнашып кала (бу хәдис телне яшьтән үк ялганнан сакларга өйрәтә).

Иң кечкенә бер изгелекне дә кадерсез санама вә игътибарсыз калдырма. Суга килүченең чиләгенә су алып салуың да бер изгелектер (изгелекнең кадерен югалтмаска чакыра).

Дустыңны сөюеңне саклык белән алып бар, бәлки ул беркөн сиңа дошман булыр; дошманыңны дошман күрүеңне дә саклык белән алып бар, бәлки ул беркөн сиңа дус булыр.

Арттыру белән мактаучыларның йөзләренә туфрак сибегез (чөнки артык макталган кеше ул бик тиз зураеп китә).

Яхшы эшләрең сине шатландырса, бозык эшләрең кайгыга салса, син чын адәмсең (уйлап карасаң, бик тирән мәгънә, әхлак-әдәп ята монда).

Ахмак кеше белән мөнәсәбәт ясама. «Ахмак дуска караганда, акыллы дошман яхшырак» дигән сүз күп тәҗрибәләрдән соң әйтелгән. Ахмактан файда көтү аяз күктән яңгыр көтү кебек мәгънәсез бер эштер.

Адәмнәрнең иманы камил булганы – холыклары гүзәл булганнарыдыр. Гүзәл холыклы кеше үз гаиләсенә дә, башкаларга да мөмкин кадәр изгелек кыла.

«Узган гомер турында уйланып, артка – үткәннәргә әйләнеп карыйсың да, аның инде кире әйләнеп кайтмаячагына тагын бер кат инанып, бераз гына уфтаныпта куясың. Ул, әйтерсең лә, бер мизгел кебек кенә үтеп киткән. Әйе, әгәр кеше үлемсез булса, бәлки ул вакытны да исәпләмәс, узган гомерен дә җәлләмәс иде. Ләкин барыбыз да, кайчан да булса үләчәк, ягъни мәңгелек дөньяга күчәчәк бит. Инде кайбер вафат булган кешеләрне искә алып, үзебезгә үзебез бәя бирәбез: «Әнә теге кеше кыска гына гомер эчендә нинди шәхескә әверелде һәм калган буынга онытылмаслык мирас калдырды... «Димәк, үлем безне һәрбер минутны, сәгатьне, көнне бушка уздырмаска да өйрәтә. Кеше гомере буе хыялланып, матур уйлар белән янып яшәргә тиештер ул. «Хыялсыз кеше – сүнгән кеше», – дип тикмәгә генә әйтмиләр бит. Шул уй-хыялларны тормышка ашыру өчен көрәшә белергә дә кирәк. Төшенкелеккә бирелеп, миннән барыбер булмый, дип тормышның кызыгын бетерү өчен күп кирәк микән? Язмыш дигәне дә адәм баласын төрлечә сыный. Әнә, мисал өчен танылган язучыбыз Фәнис Яруллин да бәхетсез очрак нәтиҗәсендә, ять-яшь килеш урын өстенә егылган. Әмма ничек кенә авыр булса да, рухын, яшәү дәртен сүндермәгән, ул үзендә нииндидер могҗизалы көч, сәләт таба алган. Ярым хәрәкәтсез хәлдә ятып та, күпме әсәр, безнең өчен тиңсез хәзинә иҗат иткән. Ә бит бу тормышта юк кына сәбәпләрдән дә төшенкелеккә бирелеп, үз-үзләренә кул салучылар да бар. Аларның күпчелеге – яшьләр. Аллаһы

ихтыяры белән дөньяга килгәнсең икән, дөрес юлны сайлап, яшәргә дә, яшәргә бит, югыйсә. Әлбәттә, иман китергән, Ислам кагыйдәләрен вә хөкемнәрен яхшы аңлаган бәндәләр бу хаталыклардан ерак торырлар. Дин беркайчан да юньсезгә өйрәтми. Дөрес, кеше аңа бик авырлык белән тартыла. Ләкин бер аңлагач, ул инде аңа гомере буе тугры булып кала. Әйе, безнең һәр үткән көнебез, аебыз, елыбыз – үлемгә таба бер адымыбыз ул. Әмма әҗәл артында җәннәт белән җәһәннәм тора. Бер адым атлаган саен, аларның кайсына таба якынаябыз икән соң? Яхшы гамәлләр кылып яшәгән кешеләрнең күңелләре саф, ниятләре изге була. Андыйлар, әлбәттә, җәннәт бакчаларында хозурланырлар. Ә инде Аллаһы тарафыннан бүләк итеп бирелгән гомерләрен заяга үткәргән, күңелләрен харамга салган кешеләр Ахирәт тормышларында мең төрле газапка дучар ителерләр.

Ураза тоту, намаз уку – ул бер бәхет, бер сәгадәт, Аллаһының безгә биргән бүләге. Аллаһы Раббыбыз кар- шысындагы вазифаларыбызны үтәүчеләрдән булып, гыйбадәтебезне күбрәк кылыйк, үткән гомеребездәге хилаф эшләребезгә тәүбә итик, һәм ул үзенең әҗер-савапларын безгә ирештерер, үлгәннән соң, шушы гыйбадәтләребез өчен, җәннәте белән сөендерер».

Эш белән алданып яшәп, ахирәткә күчәсемне уйлап та караганым булмады. Сез моны китап итеп чыгарыгыз, минем кебек кешеләргә ярдәм итәр өчен..., – диде Райнур, дәфтәрне язучыга биргәндә...

*Гөлсинә Галимуллинаның*

*«Күгәрчен оя корганда» китабыннан өзек*